9. *Пуускин А.С.* Ырыа хоһоон [тылб.: П. А. Ойуунускай уо. д. а.; киирии тыл авт. С. Батаакап]. – Москуба; Дьокуускай: Судаарыстыба Саха сиринээҕи бэчээттиир суута, 1937. – 103 с.

10. *Пуускин А.С* Талыллыбыт лирика / И.Е. Слепцов тылбааһа. – Якутскай: Госиздат, 1940. – 61 с. (*Пушкин А.С.* Избранная лирика / пер. И.Е. Слепцова).

11. *Пэрруо С.* Остуоруйалар. М. Ханаайап тылб. – Москуба; Лиэнингирээт: ЫБСЛКС КК, оҽо литэрэтиирэтин пэчээтэ, 1937. – 32 с. (*Перро Ш.* Сказки / пер. Н. Канаева).

12. *Распэ Р.* Мүнхааүсиэн мүччүргэннээх сырыылара; [К. Чуковскай батыһыннаран кэпсээтэ; П.В. Заболоцкай тылб.]; Густаап Дориэ урусуйдара. – Москуба; Дьокуускай: Судаарыстыба Саха сиринээҕи бэчээттиир суута, 1938. – 102 с. (*Распе Р.* Приключения Мюнхаузена / в пересказе К. Чуковского / пер. П.В. Заболоцкого. – Москуба; Якутск: ЯКГИЗ, 1938).

13. Сахалыы бастакы хаһыаттар, сурунаал: «Саха дойдута» (1907–1908), «Саха олоҕо» (1908–1909), «Саха саҥата» (1912–1913); [сост.: Н.В. Бурцева и др.]. – Якутск, 2017. – 367 с. (У истоков якутской печати – газеты «Якутский край» (1907–1908), «Якутская жизнь» (1908–1909), журнал «Голос якута» (1912–1913)).

**Ф.И. Габидуллина**
Казан федераль университетының Алабуга институты,
Алабуга, Татарстан Республикасы

## ХХ ЙӨЗ АХЫРЫ ПОЭМАЛАРЫНДА ТЕМА-МОТИВЛАР ТӨРЛЕЛЕГЕ

**Ф.И. Габидуллина**
Елабужский институт (филиал) Казанского федерального университета,
Елабуга, Республика Татарстан

## РАЗНООБРАЗИЕ ТЕМ И МОТИВОВ В ПОЭМАХ КОНЦА ХХ ВЕКА

**Аннотация.** Статья посвящена изучению поэм конца XX в. в аспекте многообразия представленных в них тем и мотивов. На примере поэм, написанных в конце прошлого века, выявляются интересующие авторов жизненный материал, проблематика и поэтика произведений, определяются структуры поэм,

их идейно-эстетические особенности, нравственные и философские размышления авторов.

**Ключевые слова:** татарская литература, поэма, тема, мотив, проблема, идея.

**Abstract.** The article is devoted to the study of poems of the late twentieth century in the aspect of the variety of themes and motifs. On the example of poems written at the end of the century, the authors are interested in the vital material, problems and poetics of the works. The structures of the poems, their ideological and aesthetic features, moral and philosophical reflections of the authors are revealed.

**Keywords:** Tatar literature, poem, theme, motive, problem, idea.

XX гасыр ахырында әдәбиятның үсеше илдәге сәяси, иҗтимагый, мәдәни шартлар белән тыгыз бәйлелектә була. 1980 еллар уртасында башланып киткән үзгәртеп корулар процессына нисбәтле, илдә демократик үзгәрешләр башлана. Шуның нигезендә үсеп киткән хәбәрдарлык, фикер төрлелеге, цензура бетерелү һ. б. социалистик системаның нигезләрен какшата, экренләп капитал мөнәсәбәтләргә юл ачыла. Шундый шартларда, бу чорның иң зур вакыйгасы буларак, СССР дәүләте таркала, күп халыклар дәүләтчелек яулап ала. Татарстанда милли хәрәкәтнең кискен үсеше күзәтелеп, республика шактый зур мөстәкыйльлек яулап алуга ирешә. Әлеге катлаулы вакыйгалар татар сүз сәнгатендә чыгылыш таба, аның сан һәм сыйфат үзгәрешенә этәргеч бирә [Закирзянов, 2019: 80].

XX гасыр ахыры татар поэзиясендә Г. Афзал, Ә. Баянов, И. Юзеев, Рәшит Әхмәтҗанов, Ә. Рәшитов, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Ф. Яруллин, Х. Әюпов, К. Сибгатуллин, З. Мансуров, Р. Зәйдулла, Г. Морат һ. б. актив иҗат итә. Алар янәшәсендә кешенең рухи матурлыгына, мөлаем хис-кичерешләренә, нечкә тойгыларына йөз тотып Л. Шагыйрьҗан, Э. Мөэминова, Н. Сафина, Р. Вәлиева, К. Булатова, Б. Рәхимова, Ф. Зыятдинова, Ф. Тарханова, Э. Шәрифуллина, А. Минһаҗева һ. б. шагыйрәләрнең ихласлык бөркелеп торган иҗаты балкый. Татар шигърияте үзенең традицияләренә тугры калып, реалистик сурәтлелекне, заман алып килгән үзгәрешләрне төрле планда чагылдыруны дәвам итә. Бу юнәлештә Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Л. Шагыйрьҗан, З. Мансуров, А. Хәлим, Р. Зәйдулла һ. б. шигырь-поэмалары языла. Шул ук вакытта кеше яшәешенең рухи ягына игътибар итеп, күңел дөньясын, хис-кичерешләр байлыгын романтик төсмердә чагылдыруның уңышлы үрнәкләре пәйда була. И. Юзиев, Р. Гаташ, Ә. Рәшит, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Аймәт, Р. Низами һ.б. иҗаты алымчаралар, сурәтләр муллыгы белән аерылып тора, хыял дөньясы белән бәйле күренешләр киң чагылыш таба.

Әлеге чор татар шигъриятендәге эзләнүләр җәмгыятьнең үзгәреше, милләт язмышы белән аерылгысыз бәйле. Т. Галиуллин язганча, «90 еллар башында ил

тормышында, милләтләр язмышында уңай якка үзгәрешләр, ягъни «икенче җылыныш» әдәбият үсешенә өстәмә көч, яңарак юнәлеш бирә; киләчәккә өмет, ышаныч чаткылары уяна, илдәге милли һәм рухи күтәрелеш шигырьне әдәбиятның алгы сафына алып чыга» [Галиуллин, 2008: 124]. Шигърияттәге үзгәрешләр әдипләр мөрәҗәгать иткән юнәлеш-агымнарда аеруча тулы чагылыш таба. XX гасыр ахырында, традицияләр дәвамчанлыгы белән бергә, Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятларындагы яңа, кызыклы әдәби-эстетик казанышлар килеп кушыла. Бу исә XX йөз башы поэзиясендә күзәтелгән алым-чараларның, сәнгати табышларның әйләнеп кайтуына юл ача. Шуның белән бергә, чор үзенчәлеге булырак, модернистик алымнарның яңадан-яңа төрләре мәйданга чыга, әдәби сурәтлелекне баетып җибәрә. Шигърияттә импрессионистик, экспрессионистик, гыйсъянчылык алымнарына таяну «иҗтимагый юнәлешле тәнкыйтьне көчәйтүгә хезмәт итә» [Заһидуллина, 2011: 30]. Әлеге төр эзләнүләр аеруча Р. Гаташ, И. Иксанова, Л. Шагыйрьҗан, Р. Зәйдулла, Ш. Анак һ. б. иҗатында урын ала.

Бу чор шигъриятендә поэма жанры үзенең активлыгын, нигездә, саклый. Үзгәрешләр, беренче чиратта, тема-мотивлар төрлелегендә, байлыгында чагыла. Бу чор лиро-эпик жанрда активлашып киткән темаларның берсе – олы шәхесләрнең әдәби образларын чагылдыру белән бәйле. Әлеге шәхесләр яшәешнең төрле өлкәләрендә хезмәт итеп, онытылмас эшләр калдырып киткәннәр. Аларның зур бер катламын әдәбият-сәнгать өлкәсенә хезмәт итүчеләр алып тора. Бу еллар шигъриятенең үсеш дәрәҗәсен билгеләгән поэмалар буларак Р. Харисның «Нәҗиб Җиһанов», «Сәйдәш яры» һ. б. дөнья күрә. Танылган сәнгать әһелләре образына мөрәҗәгать итүнең сәбәбен Т. Галиуллин болай аңлатып үтә: «Гомерләрен, иҗатларын халыкка, аның башка милләтләр белән тигез яшәү хыялына багышлаган олуг җаннарыбыз безнең көннәр рухына якын; гасыр аша сүз осталарына кулларын, фатихаларын бирәләр, сынмаска өндиләр, көрәшкә рухландыралар» [Галиуллин, 2008: 137].

Ә инде тормышларын ил-халык мәнфәгатенә багышлап, шунда башларын салган шәхесләребез һәр татарның йөрәгендә булып, милли горурлык хисе уята. Алар арасында Идегәй, Кол Шәриф, Сөембикә, Батырша, Сәет батыр, Мәрҗани кебекләр бар. Тарихи тематиканы уңышлы үзләштереп, билгеле шәхесләрнең әдәби образларын тудырган әдипләрнең берсе – Ә. Рәшит. Аның «Сөембикә», «Колшәриф», «Мөхәммәдъяр» поэмалары укучыларда кызыксыну уятып, киң яңгыраш ала. Шагыйрь укучысын Казан ханлыгы чорына алып китә. Шул дәвер тарихына фаҗигале язмышлары белән кереп калган өч шәхес образын уңышлы алым-чараларда мәйданга чыгара. Әлеге әсәрләр аерым поэмалар буларак урын алсалар да, гомум пафосы, уртак язмышлары аша һәм автор образына нисбәтле алар бербөтенгә оеша.

Мондый поэмалар арасында Э. Шәрифуллинаның «Каюм коесы» үзгә урын алып тора. Шагыйрә үзенең якташы булган атаклы мәгърифәтченең әдәби образын торгыза. Сюжетка нигез итеп алынган Каюм коесы, символик мәгънә алып, Каюм бабаның халыкка калдырган хезмәтләре рәвешендә, татар дөньясына мәгърифәт уты алып килүен аңлата. Коеның суы мәңгелек булып, халык яшәешенә нигез булган кебек, Каюм баба калдырган традиция, аның хезмәтләре дә гасырлар дәвамында халыкның белемгә омтылышын сугарып килә. Шагыйрәнең укучыга җиткерергә теләгән төп фикере әнә шул.

Г. Тукай иҗаты гасыр дәвамында татар әдипләренә көч-илһам чыганагы булып тора. Ул XX гасыр ахыры шигъриятендә Ә. Мәхмүдовның «Көзге җилләр» поэмасында шактый уңышлы чагылыш таба. Тукай иҗаты һәм шәхесе шактый тулы өйрәнелсә дә, автор бөек шагыйрьнең соңгы көннәрен сурәтләү объекты итеп ала. Поэманы, бер яктан, әлеге шәхесне югалту ачысы иңләп үтсә, икенче яктан, Тукайны нигә саклап кала алмау, аңа ярдәм итү мөмкинлеге турындагы уйлар да калкып чыга. Иң мөһиме, автор Тукайны халык улы буларак сурәтли, әлеге шәхеснең туган халкына Аллаһы тарафыннан җибәрелүен һәм, үз максатын үтәп, яшьли вафат булуын билгеләп үтә.

Бөтен иҗат гомерендә поэма жанрын үстерүгә гаять зур өлеш керткән Ренат Харис бу чорда да актив иҗат итә. Аның каләменнән «Михаил Худяков», «Идегәй» кебек билгеле шәхесләргә багышланган әсәрләр төшә. Беренчесе татар халкын яклап чыгучы, аның объектив тарихын язуга зур өлеш кертүче тарихчыга багышланган. Кызганыч ки, башка милләт вәкиленең икенче бер халык тарихын шулай тирәнтен өйрәнүе, халкын яратуы, ана хезмәт итүе шактый сирәк очрый. М. Худяков безгә шуның белән дә бик якын. Р. Харис әлеге чын мәгънәсендә кыю шәхеснең үзенчәлекле образын тудыра, аның хезмәтләре алдында баш ия. Тарихта яхшы билгеле Идегәй турында әсәрләребез бар, автор исә әлеге шәхес аша татар халкының таркаулыгы, аны берләштерү идеясе белән чыга. Идегәй һәм Туктамыш хан тарихы олы бер гыйбрәт, андый хәлләр кабатланмасын дигән фикер әсәрдә әйдәп бара.

Р. Харисның «Чехов базары» һәм «Исемсезләр» әсәрләре чор әдәбиятының җитди бер вакыйгасы буларак яңгыраш ала. Беренче әсәрдә автор Чехов базары метафорасы аша безнең җәмгыятькә бәя бирә. Монда берәү алдап, икенчесе алданып кына калмый, бәлки илдәге буталчыклык, милли мәсьәләләрнең хәл ителмәве, гаделсезлекләр дә тулы чагыла. «Исемсезләр»дә Р. Харис үз чорының героен эзли. Гаять күп тармаклы, төрле дәверләрне иңләп алган вакаыйгалар катламы аша татар язмышының тирән катламнарын ача. Автор чор героен таба алмый, шуңа да шигъри романны сызлану фәлсәфәсе иңләп үтә.

Шагыйрьнең «Өч үбешү» эротик поэмасы да татар шигъриятен баетып, төрләндереп җибәрә. Автор яратышуның серле мизгелләренә үтеп, кешегә бирелгән ярату хисенең төсмерләрен ача, әлеге хиская мәдхия укый.

Гасыр ахыры татар әдәбияты өстенле рәвештә милли идея белән сугарылган. Үзенчәлеге шунда, авторлар аны аерым шәхесләрнең яшәү рәвеше, халкына хезмәт итү чагылышы аша күрсәтә. Милли идея эстетик идеал буларак сурәтләнгән поэмаларның берсе булып Р. Низаминың «Ике мөһаҗир» поэмасы тора. Автор XX йөз башының иң талантлы әдибе, гомерен татар халкы мәнфәгатенә багышлаган Гаяз Исхакый тормышын сурәтләүгә алына. Поэмада инкыйлабларның катлаулы чоры калкып чыга. Р. Низами «татар халкының үткәнен, хәзергесен, үзеннән генә тормаган сәбәпләргә бәйле киләчәген йөрәге аша уздыра, сызлана, әрни» [Галиуллин, 2008: 153] һәм укучыны шулар турында уйланырга этәрә.

Иҗаты милли яшәеш идеяләре белән сугарылган Р. Зәйдулла әсәрләре иҗтимагый яңгырашлы булулары, фикер ачыклыгы, мәгънә тирәнлеге белән аерылып тора. Хис-фикерне үтемле, эмоциональ тәэсирле чаралар белән укучыга җиткерүдә җитди казанышларга ирешә. Лиро-эпик жанрда сирәк иҗат итсә дә, әдипнең «Койрыклы йолдыз» поэмасы зур яңгыраш ала. Шагыйрь татарның билгеле шагыйре Хәсән Туфанның әдәби образын тудыра. Үзәктә атаклы шагыйрь тормышы һәм иҗаты турында уйланулар тора. Автор аны чор рухы, иҗтимагый вакыйгалар белән тыгыз бәйләнештә ача. Икенче катлам буларак татар халкының якындагы тарихы да күз алдына бастырыла.

Халкыбызның үткән тарихына игътибар артып, әсәрләрдә аның үзенчәлекле, гыйбрәтле сәхифәләре урын ала. Әнә шундый поэмаларның берсе булып З. Мансуровның «Ике еглау»ы тора. Автор үткән тарихның татар һәм рус халыкларына караган тарихи сәхифәләрен аерып ала. Аның игътибар үзәгендә кыпчакларга яу вакыйтында әсирлеккә төшкән ирен кайгыртып елаучы Ярославна һәм иленең иминлеге өчен рус дәүләтенә биреп җибәрелгән Сөембикә елау-сыкрануы тора. Шул вакыйгаларга бәйле поэмада уңышлы гомумиләштерүләр ясала.

Гомумән, бу чорда поэма жанры яңа үсеш юлларын билгеләп, яңа тема-мотивлар аша яшәешнең җитди проблемаларын сурәтләү предметы итеп ала, уңышлы тәҗрибәләр ясый, киләчәктә үсү мөмкинлекләрен барлый.

## Әдәбият

1. *Галиуллин Т.Н.* Йөзеп бара әдәбият-кораб... // Әдәбият – хәтер хәзинәсе. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 145–156.

2. *Галиуллин Т.Н.* Шаулый еллар заман җилләрендә... ( 1980–2000 еллар шигърияте) // Әдәбият – хәтер хәзинәсе. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 124.

3. *Закирзянов А.М.* Современное татарское литературоведение: достижения, проблемы и перспективы развития // Национальные литературы на современном

этапе: научные концепции и гипотезы: сборник статей круглого стола, посвященного 80-летию создания Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ (Казань, 11 сентября 2019 г.). – Казань: ИЯЛИ, 2019. – Вып. 1. – С. 80–88.

4. *Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М.* 1960–2000 елларда татар әдәбияты // XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2011. – Т. 2. – 198 б.

**Г.Р. Гайнуллина**
Казан федераль университеты,
Казан, Татарстан Республикасы

# ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН ҺӘМ ЯЗУЧЫ ӘМИРХАН ЕНИКИ ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА ЗЫЯЛЫЛЫК МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАШ

**Г.Р. Гайнуллина**
Казанский федеральный университет,
Казань, Республика Татарстан

# ВОПРОСЫ ИНТЕЛЛИГЕНТНОСТИ В ПУБЛИЦИСТИКЕ ЛИТЕРАТУРОВЕДА ФОАТА ГАЛИМУЛЛИНА И ПИСАТЕЛЯ АМИРХАНА ЕНИКИ

**Аннотация.** Публицистику современников литературоведа Ф. Галимуллина и писателя А. Еники целесообразно рассмотреть в сравнительном аспекте. В статье затрагивается тема отношения писателя и ученого к вопросу интеллигентности, народности творца. Делается вывод о том, что не раз затрагивая данную проблему в своих статьях, воспоминаниях о соотечественниках, служивших во благо народа, писатель и ученый зачастую сходятся во мнениях.

**Ключевые слова**: Ф.Галимуллин, А.Еники, публицистика, интеллигентность.

**Abstract.** Publicism of the contemporaries of the literary critic F. Galimullin and the writer A. Eniki should be considered in a comparative aspect. The article deals with the relationship of the writer and the scientist to the question of intelligence, the nationality of the creator. It is concluded that the writer and the scientist often have similar opinions in their articles and memoirs about compatriots who served for the benefit of the people.

**Keywords:** F. Galimullin, A. Eniki, journalism, intelligence.

Әдәби-мәдәни барышның катлаулы чорларында әдәбиятны киңкырлы, тирән бәяли алган мәгълүм зыялылар арасында киң җәмәгатьчелектә үткер сүзе, кыю фикере белән танылу алганнары күп түгел. Әдәбият гыйльмиятендә профессор Фоат Галимуллинны, язучылар даирәсендә Әмирхан Еникине зыялы, кыю, хөр фикерле, шул ук вакытта тыйнак табигатьле бер чордарак яшәгән шәхесләр дип янәшә кую бик гадел, дип саныйбыз.

Әмирхан Еники иҗатын өйрәнеп, Фоат Галимуллин дистәгә якын фәнни-публицистик мәкалә бастыра. Әдәбият галиме үзенең язмаларында Ә. Еникинең катлаулы, шул ук вакыта озак-озын иҗат гомерендә зыялылык ызаныннан китмәвенә соклана: «Әмирхан Еникинең тулаем иҗаты, үз-үзен тотышы, ныклы кыйбласы, халыктагы абруе турында төптән уйланганда, аның үз җилкәсендә заман җаваплылыгы өчен авыр йөкне баһадирларча кыюлык һәм ил агаларына хас түземлек белән алып баруында» [Галимуллин: 3]. Галим әдип иҗатының төп үзенчәлеген түбәндәгечә беркетеп куя: «Ул әдәби иҗатта үзе аңлаганны, күңеленә хуш булганны гына сурәтләде. Белеп, ышанып язды» [Галимуллин: 3]. Димәк, әдәбият галиме карашынча, халык язмыгшы өчен җаваплы зыялы иң тәүдә җаваплы, нык ихтыярлы, ышанычлы булырга тиеш. Фоат Галимуллинның зыялылык мәсьәләсендә карашлары Әмирхан Еники фикерләре белән аваздаш булу гайре табигый түгел.

Милләтебезнең иң затлы сыйфатларын күңелендә кадерләп саклаган зыялы әдип Әмирхан Еники үзенең мәкалә, очерк, истәлекләрендә зыялылык мәсьәләсенә шулай ук кайта-кайта туктала. Соңгы мәкаләләр җыентыгында тәкъдим ителгән “Куприн белән кардәш мин мәкаләсендә» әдип болай яза: «Мин борынгы зыялыларны күреп калган кеше. Мәсәлән, Җамал Вәлидине күргәнем бар минем. Гали Рәхимне, Фатих Әмирханны аз гына күрергә туры килде. Аеруча миңа якын кешеләр – Сәгыйть һәм Шәриф Сүнчәләйләр. Алар бик зыялылар иде. Хәзерге зыялылардан бик нык аерылалар. Аларның бөтен нәрсәләрендә – үз-үзләрен тотуларында булсын, сөйләшүләрендә булсын, нindидер бер мәдәнилек сизелеп тора иде. Бик чиста, пөхтә киенәләр. Зыялы кешенең тышкы кыяфәте генә түгел, күңеле дә матур булырга тиеш бит әле. Зыялылар мәсьәләсе ул иң элек рухи тәрбия белән бәйләнгән. Зур галим дә, язучы да булырга мөмкин, әмма аларның һәрберсе зыялы дигән сүз түгел әле. Гади кешеләр арасында да җитәрлек ул интеллигентлар» [Еники: 194]. Зыялылар рәтенә Ә. Еники, Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Фәйзи, Миркасыйм Госманов кебек олпат шәхесләрне кертә. Ә. Фәйзи турында әдипне шактый югары фикердә булуы сизелеп тора: «Бик белемле, бик мәдәни, гимназия тәрбиясе алган. Үзен тотышында, кешегә мөнәсәбәтендә зыялы булуы сизелеп тора иде»

[Еники: 194]. «Хәтердәге төеннәр» исемле җыентыгында «Чын кеше, чын иҗатчы» (1960) дип исемләнгән мәкаләсендә Ә. Фәйзи шәхесенә бәйле зыялылык мәсьәләсен язучы шәхесенә бәйләп күтәрә: «Шактый сыналган бер нәрсә бар: тормыштагы тере язучы үзе һәм әсәрләре аша укучы хыялында туган аның образы күп кенә очракта ни өчендер туры килеп бетмиләр. Образ үзенең асылыннан яхшырак булып чыга (хәер, киресенчә дә булырга мөмкин). Менә мин үзем Фәйзидә әнә шул «туры килеп бетмәүне» күрми идем. Фәйзи өчен әдәби иҗат хәят иде. Шуның белән яши, шуның белән сулый иде ул. Язучының сафлыгы, гаделлеге, һәр төрле фани исәп-хисаплардан өстен торуы, үзе инанганга тугрылыклы булып калуы – аның өчен язылмаган кануннар иде» [Еники: 110].

«Хәтердәге төеннәр» җыентыгында тупланган мәкаләләрендә Ә. Еники татар зыялылары Н. Исәнбәт, Ф. Хөсни, К. Тинчурин, С. Сәйдәшев һ. б. Замандашлары белән бәйле истәлекләре белән бүлешә. Зыялылык мәсьәләсен әдип халык күңеленә юл салу җәһәтеннән кузгата. Н. Исәнбәтне әдип «саф вөждан, чын гаделлек, искиткеч зур тырышлык, батырлык иясе» [Еники: 3] дип бәяли. Шакир Шамилскийга бәйле фикерләре дә зыялылык турында сүз кузгатканда игътибарга лаек: «Чөнки артистлык аның өчен бары кәсеп кенә булмады, артист дип аталу аның өчен сәнгать кешесе, зур культура иясе булу дигән сүз иде» [Еники: 65]. Әдип чын талант ияләренә гадилек, тыйнаклык, затлылык, әдәп хас дип саный: «Шул ук вакытта аның бөтен торышыннан затлылык, культура, әдәп сизелеп тора. Ул бик пөхтә киенеп йөри, хәрәкәтләре аның салмак-нәфис, сөйләшүе, үз дәрәҗәсен яхшы белгәнлектән, беркадәр генә горур, әмма масаюсыз, ачык күңелдән» [Еники: 66]. Халыкның тирән мәхәббәтен яулау өчен «көч һәм гүзәллекне җыйган» булу тиеш, дип билгеләп үтә язучы.

Ә. Еники татар музыка сәнгатенең беренче профессиональ композиторы С. Сәйдәшев иҗатына аеруча игътибарлы, һәм публицистикасында, һәм әдәби иҗатында аның эчке дөньясына кайта-кайта мөрәҗәгать итә. Ә. Еники болай яза: «Сәйдәш шәһәр баласы, үз заманының алдынгы татар зыялылары арасында үсеп җитешә, шәһәр культурасы белән сугарыла. Салих Сәйдәш бөтен килеш-килбәте белән бик пөхтә, чибәр, нәфис бер кеше иде. Һәм музыкасы да аның якты, нәфис... һәм күтәренке-дәртле дә иде» [Еники: 76]. Композиторның эчке зыялылыгы турында сөйләгәндә әдип бер вакыйгага туктала: «Бер заман газетада нинддер уңай белән бүләкләнгән сәнгать әһелләренең исемлеге басылып чыга. Вакыйганы сөйләүче – шагыйрь – шул газетаны сатып алып, урамда карый-карый бара. Аңа Сәйдәш очрый. Туктыйлар, исәнләшәләр. Шагыйрь газетаны күрсәтеп әйтә: менә монда ни өчендер синең исемең юк, ди. Шуңа каршы Салих тыныч кына: «Ник булмасын, минем Салих Сәйдәш дигән исемем бар», – дип җавап бирә» [Еники: 80].

Зыялылык мәсьәләсен әдип, аңлашыла ки, язучы буларак күтәрә, бәяли, иҗат кешесенә хас булган сыйфатларга аерыбрак туктала. Шул ук вакытта әдипне «чын кеше булу» мәсъәләсе гел борчып торганлыгы, уйланырга мәҗбүр иткәнлеге сизелә: «...Белгеч яки галим булу, хәтта язучы булу авыр түгел, әмма чын кеше булу – шактый читен эш. Талантың һәм көчле теләгең булып инде әдәбиятка килгәнсең икән, дан-дәрәҗәң турында уйламый тор, күбрәк укучың турында уйла, борчыл. Син аңа белгәнеңне, ышанганыңны яз, ул да сиңа ышансын. Әдәби осталыгыңны камилләштерү турында көн-төн кайгырт, эзлән, тырыш. Таләпчәнлек, тагын бер мәртәбә таләпчәнлек» [Еники: 33].

Инде килеп, үзенә кагылышлы әдип болай фикер йөртә: «Беләсезме, мин үземне классик язучы, олы язучы итеп тоймадым да, ул хакта уйламадым да диярлек. Шулай да миндә ышаныч бар. Мин алай тиз онытыла торган язучылардын булмам дип уйлыйм» [Еники: 197].

Әдәбият галиме Фоат Галимуллинның тагын бер фикерен ассызыклау урынлы булыр: «Без Әмирхан Еникине милләт хадиме, сәясәтче дип тә атыйбыз. Аның «Татар мәсьәләсе», «Кояш баер алдыннан» хезмәтләре Гаяз Исхакыйның мәгълүм «Идел-Урал» дигән хезмәтенең дәвамы буларак каралырга мөмкин. Боларның һәммәсе Әмирхан Еникине һәм шәхес, һәм әдип, һәм фикер иясе буларак халкыбызның горурлыгы дип расларга мөмкинлек бирә» [Галимуллин: 3].

Шул рәвешле, зыялылык мәсьәләсендә професссор Ф. Галимуллин һәм язучы Ә. Еники фикерләрендә аваздашлык күрәбез. Татарның олпат галиме һәм бөек язучысы халык күңелен бик нечкә сизү, талантыңны дөрес юнәлешкә бора белүне иҗат кешесенә хас зыялылык, әдәп, дип даими рәвештә кабатлап һәм үз иҗатлары, гамәлләре белән раслап киләләр.

**Әдәбият**


1. *Галимуллин Ф.Г.* Әдәбияттагы морзабыз // Ватаным Татарстан. – 2019. – № 32. – Б. 3.

2. *Еники Ә.* Хәтердәге төеннәр: мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1983. – 224 б.

3. *Еники Ә.* Биектән карап торасым килә... Заманым һәм замандашларым турында. – Казан: Мәгариф, 2009. – 215 б.

**Т.Н. Галиуллин**
Казан федераль университеты,
Казан, Татарстан Республикасы

# ФИКЕРДӘШ

**Т.Н. Галиуллин**
Казанский федеральный университет,
Казань, Республика Татарстан

# ЕДИНОМЫШЛЕННИК

**Аннотация.** В статье дается обзор научно-педагогической деятельности ученого-литературоведа, критика Ф.Г. Галимуллина. Анализируются основные труды ученого-литературоведа, дается оценка педагогической деятельности профессора университета.

**Ключевые слова:** Ф.Г. Галимуллин, педагог, ученый-литературовед.

**Abstract.** The article provides an overview of the scientific and pedagogical activities of the literary scholar, critic F.G. Galimullin. The main works of the literary scholar are analyzed, and the pedagogical activity of the university professor is evaluated.

**Keywords:** F.G. Galimullin, teacher, a literary scholar.

Күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче, укытучы-педагог, Казан дәүләт федераль университетының профессоры Фоат Галимуллин хәзергәчә студентлар, аспирантлар, хезмәттәшләре белән аралашып, әвәрә килеп, еллар басымына баш бирмичә эшли, яши белүче шәхесләребезнең берсе. Ул үзенә охшаган кеше, аны үзгәртеп тә, алыштырып та булмый. Гәүдәсен туры тотып, һәр адымының кадерен, бәясен белеп, чираттагы лекциясенә кергәнен сокланып карап торганда, Фоатның нинди катлаулы да, бәрәкәтле дә тормыш юлы узганын күз алдына китерүе дә кыен. Аның 1941 ел баласы икәнен, әтисе Галимулланың Ватан сугышында вафат булуын, әнисе карамагында калган үсмернең яшьли колхозда ат җигеп төрле эшләр башкаруын, тракторчы ярдәмчесе булуын, урта белемне дә армиядә хезмәт иткәндә алуын белгәч, табигате белән олы җанлы, киң колачлы шәхес булып кала алуының серләренә төшенгәндәй буласың. Аның «беренче укытучысы» ачы язмыш үзе булган.

Ә нәселдән килгән сәләтне, иҗади рухны тормыш авырлыгы да, башка кыенлыклар да сындыра алмый икән. Гаскәри хезмәтен тутырып кайтуын туган ягында аны күтәреп алгандай булалар. Ул әүвәл клуб мөдире, җырчы, Кукмара

район мәгариф йортының сәнгать җитәкчесе, райком аппараты хезмәткәре... Рәхәтләнеп типтереп яшә шунда. Күңеле һаман нидер эзли һәм, ниһаять, аның эчке халәтенә муафыйкъ шөгыле табыла. 1967 елда радио дикторларына уздырылган конкурста җиңеп чыга һәм озак еллар дәвамында Фоатның бай тембрлы, куе, җылы тавышы телебезнең сыгылмалы байлыгы белән халкыбызның колагын иркәли, рухын баета. Телевидение, кесә телефоннары, интернет челтәре, башка элемтә чаралары әле уянып кына килгәндә, дөнья, ил хәлләре турындагы хәбәрләрне һәр өйдә, урамда багана башында артист Боярскийның кара эшләпәсен хәтерләтеп эленеп торган радиоалгычтан ала идек. Ул радио дикторлары заманасы иде. Аларның соңгы хәбәрләрне, яңалыкларны тыңларга чакырган тавышлары һаман да колакта чыңлап торгандай. Эльс Гаделев, Рим Кәримов, татар «Левитаны» кушаматлы Фоат Галимуллиннар белән таныш булу, исәнләшү зур мәртәбә санала. Ч. Әхмәтова «Диктор ул дәүләт тавышы» (1996) дип язуы белән хаклы иде. Мәрьям Арсланова, Камал Саттарова кебек атаклы хатын-кыз дикторларыбыз турында әйтеп тә тормыйм.

Радиода эшләү дәверендә тормышы җайлы гына барса да, Фоатның рухи ихтыяҗлары арта килә, укуын дәвам итәргә кирәклекне вакытында аңлый. Ул, Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап, шунда укытырга калдырыла. Башкортстан университетында аспирантура үтеп, татар прозасына багышланган кандидатлык диссертациясен яклагач сәләтле егетне бигрәк тә тынычта калдырмыйлар, әүвәл туган институтының тарих–филология факультетының декан урынбасары, соңрак деканы итеп сайлап куялар (1977–1992).

Аның каләменнән төшкән нәзакатьле тәнкыйть мәкаләләре, «Инешләр Иделгә кушыла» (1985) китабы белән таныш булсам да, киләчәктә аның белән хезмәттәшләр, хәтта дуслар булып китүебезне һәм, бигрәк тә уземнең язмышымда мөһим роль уйнаячагын күз алдыма да китерә алмый идем. 1986 елда Алабугадан Казанга әйләнеп кайткач, мине ул вакыттагы КДПИ ректоры Рузаль Юсупов тарих-филология факультеты карамагындагы рус әдәбияты кафедрасына тәгаенләде. Нәкъ менә шунда Фоат Галимуллин белән якыннан танышып, хәзергәчә җилкәгә җилкә терәп, хәлебездән килгәнчә туган телебезгә, әдәбиятыбызга хезмәт итеп яшибез.

1986–1988 елларда Фоат Галимулла улының мәрхәмәтле карашын, җылы мөнәсәбәтен тоеп эшләргә насыйп булды. Ул үзе һәм аның ярдәмчеләре, хәзер икесе дә мәңгелеккә күчкән шагыйрь-тәнкыйтьчеләр Әмир Мәхмүдов белән Хәнәфи Бәдигый, кафедра мөдире Ефим Бушканец миңа иң яхшы аудиторияләрны биреп, теләгән сәгатьләрне куеп, тәнәфес вакытында чәй белән сыйлап күңелемне күрделәр. Мин барысына да рәхмәтле, (вафат булганнарга дога булып барсын), чөнки изгелекнең кадерен вакыт сынавын узгач кына тиешенчә бәяли

аласың икән. Мине Казан дәүләт университетына күчергәч тә Ф. Галимуллин белән алдагы елларда да яхшы мөнәсәбәтебезне саклый алдык. Ул 1999 елда татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеы каршында оешып, мин 25 ел дәвамында җитәкчелек иткән яклау шурасында «1920–1930 еллар татар әдәбиятында эстетика һәм социолгизмның үзара мөнәсәбәте» дигән сәяси яктан шактый катлаулы мәүзугка докторлык диссертациясен уңышлы яклады һәм тиз арада профессорлык дәрәҗәсен дә алды.

Үткән гасыр ахырында, бигрәк тә яңа гасыр башында Фоат Галимуллин татар әдәбият белеменең, тәнкыйтенең әйдәп баручы шәхесләренең берсе буларак күтәрелде. Аның берсен-берсе тулыландырып, әдәбиятыбызның, бигрәк тә проза жанрының үсешен яңачарак бәяләгән «Офыкларны алдан күреп» (1995), «Эстетика һәм социологизм» (1998), «Әле без туганчы... 1920–1930 еллар әдәби хәрәкәтенә бер караш» (2001), «Табигыйлеккә хилафлык» (2004), «Эзләнү вакыты» (2005) кебек матбугатта уңвй бәяләрен алган фәнни-тәнкыйди хезмәтләрен, йөзләгән мәкаләләрен вакытлы матбугатта бастыра. Сөендергәне шул: мин 20–30 еллар шигърияатен, ул проза үсешен өйрәнеп, уртак нәзари һәм гамәли нәтиҗәләргә килгәнбез икән.

Алдагы елларда Фоат Галимуллинны язмыш төрле яклап «бөтереп» ала, әйтерсең лә, аның киеренке фәнни эзләнүләреннән бераз котылуын көтеп кенә торганнар. Язучыларның XIII–XIV корылтайларында (1999, 2004) аны Татарстан Язучылар берлегенең рәисе итеп һәм шул ук чорда (1999, 2002) диярлек Татарстан республикасы Дәүләт советы депутаты итеп сайлыйлар. Шөһрәткә омтылмыйча, нәфесеңне тыебырак яши белсәң, сине онытмыйлар икән. Ходай яраткан колына чыгарып куяр юлына дигән мәкальнең тирән эчтәлекле булуына ышанмый хәлең юк. Ибраһим Гази, Гариф Ахунов, Ринат Мөхәммәдиев, Фоат Галимуллиннар рәислек иткән чорда Язучылар берлегенең җәмгыятьтә абруе зур һәм аның белән санашалар иде. В.В. Путин әйтмешли, вак-төяк «журналюгалар» аның эшенә тыкшына, бинасын күпсенә алмыйлар иде. Әдәбият йомгакларына, бигрәк тә рәис һәи идарә сайлау җыелышларына обкомның беренче сәркатибе Ф. Табеев үзе килә алмаса, идеология буенча сәркатипләре катнаша һәм чыгыш ясый иде. Бу традицияне, каләм ияләренә игътибарны президент М. Шәймиев тә сакларга тырышты. Мәсьәлән, ул 1999 елда узган җыелышта утырды да, сайлау алдыннан гына, «мин бу өлештә катнашмыйм, сезгә ышанам», дип чыгып та китте.

Ике мөддәт рәис вазыйфаларын үтәгәннән соң, Мәскәүгә күчеп, «Татарские края» газетасына нигез салып, хәзергәчә аның баш мөхәррире Р. Мөхәммәдиевне алыштырган Фоат өлкәннәрне хөрмәт итеп, яшЬләр сүзенә колак салып, иҗатка килүчеләргә ярдәм итеп яшәү кебек традициягә турылыклы кала. Язучылар оешмасы, кырмыска түмгәге кебек, таяк тыгып, болгатуны көтеп

кенә тора. Нәкъ АКШның президенты шикелле, ике мөддәттән дә артык ул урындыкны били алган кеше юк. Еш кына рәисне беренче дүрт елдан соң ук алыштыралар. Фоат Галимуллинга түземлелеге, тыныч холкы, белеме һәм дипломатия нигезләрен яхшы үзләштерүе ярдәм итә.

Хәтерләвемчә, аны тәнкыйть итсәләр дә, каударланып җавап бирми, бәлки ул хаклыдыр дип, фикерне аңы аша уздыргач кына, үз мөнәсәбәтен белдерә. Идарә әгъзаларының уенын-чынын бергә кушып, ул үзенең илһамлы сүзе, ихласи тавышы, мантыйгы белән теләсә нинди ниятен, теләген уздыра ала иде, вакыты белән нинди мәсьәлә каралганын да аңышып җитмичә, аның тигез баритонына буйсынып «оеп утыра» идек, диләр.

Ул Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф.Бурнаш, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, И. Салахов, М. Хәбибуллин һәм башка күп язучыларның иҗатына багышланган йөзләгән (аларны санау, барлау үзе бер зур хезмәт булыр иде) җитди мәкаләләрен бастыра. Шулар белән беррәттән ул мәктәп һәм югары уку йортлары өчен фәнни-методик хезмәтләр яза, программалар, дәреслекләр төзүдә катнаша. Аның киң колачлы, эрудицияле, телнең тәмен тоеп яшәүче шәхес икәнен сәнгатьле сөйләм һәм укуга багышланган хезмәтләре раслап торалар. «Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү», «Әдәби иҗатта осталык мәсьәләләре», «Әдәби бәйләнешләр» шул юнәлештәге иҗат «җимешләре». Бу өлкәгә үзе сәхнә тотып, җырлау, сөйләү сәләтенә ия булмаган кеше керә алмый. Язучылар берлеге рәислеген М. Мирзага тапшыргач, ул укыту һәм фәнни эзләнүләргә башы-аягы белән кереп чума.

Фоат Галимуллинның 2017 елда Татарстан китап нәшрияты укучыларга тәкъдим иткән «Рухи хәзинәләр гасыры» исемле хезмәте XX гасыр һәм яңа йөзъеллык башы сүз сәнгатебезнең барлык жанрларын да иңләп, үсешебез эволюциясен яңачарак бәйләве белән хәзерге әдәбият белеменең казанышы буларак бәяләнергә лаеклы. 398 биттән торган фәнни-гамәли хезмәтнең нәзари һәм методологик нигезе түбәндәге юлларда шактый тулы чагыла. «Татар әдәбияты – илебездәге зур традицияле, нык үскән, хәзер дә төрле юнәлешләрдә даими алга баручы сүз сәнгатьләреннән берсе... Сүз сәнгатебезнең тарихын җентекли башласаң, аны һәрвакыт төрле чорларның чын шәхесләре үз җилкәләрендә күтәреп килгәннәр» (Б. 258–259).

Китапның тирәнтен уйланылган композициясе сокландыра. Без теге яки бу кешенең эшенә, гамәленә бәя биргәндә, аның ыру-нәселенә, тамырларына, ягъни килеп чыгышына игътибар итәбез. Менә шул «тамырлар» системасын автор үзәк өлге итеп ала. Китапның дүрт бүлегенә дә шул сүз-төшенчә юл ярып, якты нур сирпеп бара кебек. Менә алар: «Рухи тамырлардан шифа алып», «Тамырлар ныгысын дисәң», «Тамырның затлы тармаклары», «Аһәңле шигъри тамырлар».

Сүз сәнгатебезнең тарихы, үсеш үзенчәлекләре, чорлары белән таныш булмаган кешедә исемнәре буенча һәр бүленешнең эчтәлеге турында күзаллау тудыра алыр. Әдәбиятыбыз үсешенең һәр чоры: егерменче гасыр башы (1901–1917), сталинизм хакимлек иткән (1920–1960), җепшеклелек (1960–1990), демократик (1990–2005) һәм хәзерге исеме табылмаган чорлар, төп фикерләү, өслүб юнәлешләре, аерым шәхесләр иҗатын күзаллау аша, экрандагы төсле, тасфирый-күргәзмәле рәвешә күз алдына бастырылалар.

Миңа, гомеремнең төп өлешен шигъриятне өйрәнүгә багышлаган галимгә, тәнкыйтьчегә аеруча аһәңле шигъри тамырлар өлеше күңелемә хуш килде. Тезмә жанрлар нәзариятен, тарихын өйрәнүче галимнәргә багышланган «Шигърият галиме», «Әдәбият гаме – яшәү мәгънәсе», «Шәхесләр һәм шагыйрьләр», «Мөгаллим шагыйрь» кебек бүлекләрне, турыдан-туры шагыйрьләр иҗатына: Ф. Кәримгә («Озын рухи гомер»), Ш. Маннурга («Биреп барлык йөрәк җылысын»), Р. Миннуллинга («Дөнья гаменә иңне куеп»), С. Сөләймановага («Еракларга әйди көмеш кыңгырау»), арабызда яшәп иҗат иткән, әле хәзер дә яңадан яңа әсәрләре белән шатландырып яшәгән Р. Вәлиев («Йә дөньямны, йә үземне үзгәртәм»), Р. Вәлиева («Сүз сәнгатебезнең матур бер бизәге»), Ф. Солтан («Җир йөзендә җыр тынмасын»), Р. Ахунҗановаларның («Бисмиллалы иҗат»), мирасларына, иҗатларына багышланган бүлекләрне, күбесе турында үзем дә каләм тибрәткән кеше буларак, сөенеп тә, хәтта, мишәрең әйтмешли, берцәк көнләшеп тә укыдым. Фоатның язганнарын кат-кат укый-укый бер нәрсәгә инандым, ул йөрәк тибеше, җаны, бөтен булмышы белән нәфис сүз остасы – шагыйрь икән ләбаса. Кул тамгасы белән бүләк иткән әлеге китабында миңа да ул мөрәҗәгатен тезмәгә салган. Шуның беренче куплетын гына китерәм.

Бергә булдык узган йөздә,  
Бусында да янәшә.  
Зур теләгем Тәлгат кордаш:  
Вакытны узып яшә.

Каләм тота белгән кешегә затлы әсәр, лаеклы хезмәт турында мәкалә язу әлләни авыр шөгыль түгел, вакытың гына булсын. Иҗатчының эчке ялкынын, рухын чагылдырган мәкаләгә исем табуыкыенрак. Кече күңелле олы галим, Кайда син үз кеше кебегерәк исемнәрне кумакчы идем, елгырырак тәнкыйтьчеләр нәкъ шул атамадагы мәкаләрен бастырып өлгергәннәр. Ул миңа «кордаш» ди икән, мин аңа «фикердәш» дип җавап бирәм. Туган көнең белән, Фикерәш һәм Фоат дус!

**А.Ф. Ганиева**
Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать итституты, Казан

# ФОАТ САДРИЕВ ХИКӘЯЛӘРЕ: ИДЕЯ, ПРОБЛЕМАТИКА, ГЕРОЙ

**А.Ф. Ганиева**
Институт языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ, Казань

# РАССКАЗЫ ФОАТА САДРИЕВА: ИДЕЯ, ПРОБЛЕМАТИКА, ГЕРОЙ

**Аннотация.** Герои Ф. Садриева – люди современности. Писатель в своих рассказах использует широкие возможности реалистического метода: психологические состояния героев изображаются в неразрывной связи с общественной жизнью, автор критикует общественные порядки, противоречащие свободе и счастью личности. В произведениях всесторонне освещается окружающая среда героя. Это рассматривается в контексте личного счастья героя (любовь, семейные отношения), общественной жизни (человек и общество), природной сущности (человек и природа, родная земля, татарская деревня).

**Ключевые слова:** татарская проза, герой, проблема, жанр, рассказ, Фоат Садриев.

**Abstract.** Heroes of F. Sadriev – people of our time. The writer uses the broad possibilities of the realistic method in his stories: the psychological states of the characters are depicted in an indissoluble connection with public life, the author criticizes social orders that contradict the freedom and happiness of the individual. The works comprehensively cover the environment of the hero. This is considered in the context of the hero's personal happiness (love, family relations), social life (man and society), natural essence (man and nature, native land, Tatar village).

**Keywords:** Tatar prose, hero, problem, genre, story, Foat Sadriev.

Фоат Садриев – сиксәненче еллардан алып, бүгенге көнгә кадәр татар сүз сәнгатен баетуга саллы өлеш керткән мәшһүр иҗат әһелләренең берсе. Традицион реализм мөмкинлекләреннән иркен файдаланып язылган хикәяләрендә ул халыкны борчыган проблемаларны үзәккә куя. Аның прозасы лирик-фәлсәфи тирәнлеге, теленең һәм сурәт чараларының халыкчанлыгы, эмоциональлеге белән аерылып тора. Ф. Садриевның гаделлекне тормыш маягы иткән милли геройларын укучы аеруча да яратып кабул итте.

Социалистик реализм рухында иҗат ителгән беренче хикәяләрендә үк замандашының күңел тибрәнешләрен җәмгыятьтәге каршылыкларга мөнәсәбәттә сурәтли («Гадәти иртә», «Авыш басу икмәге»). Юмористик хикәяләренең күбесе («Ак эт бәласе кара эткә», «Мин ничек шигырь яза башладым», «Җан авазы», «Дөрес некролог» һ. б). оппозицион характерда булуы исә язучының иҗат принцыбын билгеләүче факторга әверелә.

Ф. Садрив иҗатының башлангыч чорыннан ук юмористиканы үз итә.Аны укучының күңеленә үтеп керерлек сүзләр таба белүче оста психолог дияргә мөмкин: кызганыч ситуация булса, ул елата, җитди фәлсәфи әсәр булса, тормыш-яшәеш турында уйландыра, көлкеле хәл турында язса, укучыны эче катканчы көлдерә.«Чебен», «Капитуляция», «Гыйбрәт», «Тормышның кендеге», «Гел сине генә уйлыйм», «Катык» кебек кечкенә юмористик хикәяләрендә ул тормыш-көнкүрештәге төрле кызыклы ситуацияләрне тасвирлый.

Ф. Садриев иҗтимагый тигезсезлекне кеше бәхетенә каршы күренеш буларак бәяли һәм бу турыда аеруча сызлану белән яза. «Печән», «Ишек» хикәяләре җәмгыятьтә барган социаль бүленешне өлкән буын вәкилләренең күңелләренә авыр кабул итүе турында. «Печән» хикәясендә бу авыл кешесенең табигатькә бәйле яшәү рәвеше, җитәкчеләрнең җавапсызлыгы, крестьянның мәшәкатьле тормышы аша тасвирланса, «Ишек» әсәрендә төп геройның кичерешләрендә, Матурлык һәм Ямьсезлек каршылыгында чагылыш таба. Эчтәлеген символик мәгънәле детальләр белән тулыландыру сәбәпле әлеге хикәя сәнгатилек ягыннан тагы да уңышлырак чыккан.

Көннәрдән бер көнне Нурулланың кызы Гөлшатны эшмәкәр Флорид фермадан сөт урлап тотылганы өчен эшеннән куа. Үз гомерендә беркемгә ялынмаган ир кызы хакына хуҗа каршына баш иеп барырга мәҗбүр була. Шунда Флоридның эш бүлмәсенә куелган ишекнең алыштырылганын күреп аптырый ул. Чөнки район хуҗалыкара төзелеш оешмасы җитәкчесе булып эшләгәндә элеккесен Нурулла үзе ясаткан була. Ишек, бусага әдәбият белемендә капмакаршы ике якка, пространствога бүлүче символ буларак карала. Әлеге хикәядә дә ул шул вазыйфасында килә: геройлар, аларның рухи дөньяларына карап, икегә аерыла. Бер якта әле кайчан гына Нурулла кулы астында эшләгәндә, ярты арба цемен белән тотылып, анда Нурулла ярдәме белән котылып калган, хәзер, колхоз җирләрен үзенә хосусыйлаштыргач, принципиальлек сылтавы белән кардәшен эшсез калдыручы Флорид, икенче якта намус кушканча гадел хезмәт белән яшәгән Нурулла, ничә ел буена фермада ял көннәре дә алмыйча (Флорид бирмәү сәбәпле) бил бөгеп эшләүче Гөлшат, гади хезмәт кешеләренең йөзендә күңел матурлыгы күрә белүче рәссам һ.б.Әсәрдә ишекләрнең берсе икенчесенә алыштырылуы, материалы, бизәлеше дә әһәмияткә ия. Беренче ишек агач, аны алмаштырганы тимердән эшләнгән. Агач та, металл да борынгы заманнарда

сакраль көчкә ия дип карала. Агач – табигыйлекне, җылылыкны белдерсә, металл – ясалмалыкны, салкынлыкны аңлата. Беренчесен Нурулла уку залы өчен, «олысын-кечесен китапханәгә тартып торырлык» булсын дип, Түбән Кама рәссамыннан эскиз ясатып, нәкышләп эшләтә. Әлеге бүлмәне Флорид үзенә эш кабинеты итеп үзгәртә. Уку залының офиска әверелүенә дә игътибар итү кирәк.

Ишекләргә бәйле бүленеш кешеләрнең матди байлыкка ия булу-булмау ягыннан гана түгел, рухи байлыкка – Матурлыкны күрә һәм бәяли белүләре ягыннан әһәмиятле. Элекке колхоз җирләрен бары үзенеке генә дип санаучы, пай җирләре өчен дә тиешенчә түләмәүче Флоридның матур, затлы кыяфәте тышкы кабык, ә үз сүзен «Коръән»нән сүрә укып дәлилләве, асылда, ясалмалык кына булып чыгуы аңлашыла. Шулай итеп, сәнгать дәрәҗәсенә җиткерелеп, бизәлеп эшләнгән агач ишекнең тимергә алышынуы заманнар үзгәреше, заманы кебек кырыс, салкын җитәкчеләр килүен аңлата. Автор төп герой сызланулары аша җәмгыятьтә барган иҗтимагый-икътисади үзгәрешләр кеше рухын кимсетелүгә дучар итүен, гаделсезлеккә әрнетелүен күрсәтә.

«Ялгышны төзәтү» хикәясе заман чиновнигы психологиясен ачкан әсәрләрнең берсе. Ф. Садриев район куллануычылар җәмгыятенең баш бухгалтеры Хәбир Бакиров һәм аның башкаладагы җитәкчесе Рамазан Афзаловның яшәү рәвешләрен, принципларын бер-берсенә каршы куя. Рамазан Харисович хезмәткәрен юбилее белән котларга кайткач, Бакировлар өенең, шулай ук үзләренең дә артык гадилеген күреп, аңа карата мөнәсәбәтен үзгәртә. Мөмкинлеге булып та, байлык тупламаган Бакиров белән ул икесе ике дөнья кешеләре булуын аңлый һәм бу башта түбәнсетеп карау кебек хис тудыра. Алга таба автор Афзаловны үзенең гаиләсе, яшәү рәвеше турында уйлануларга китерә. Җитәкче статусын сакламаган Бакировларның тормыштан тәм табып яшәүләре, оныкларының татарча сөйләшүе, эчкерсез үзара мөнәсәбәтләре Рамазан Харисовичның ачуына тия. Ул аларны үткән заманда калган кешеләр буларак бәяли. «Ә бүгенге тормыш дулкыны, бөтенесен җимереп, алга ыргыла. Ул рәхимсез дә, пычрак та, хәтта канлы да. Шуның уртасына баш-аягың белән чумсаң, хагына-нахагына карамыйча, ләменә кадәр актарсаң гына нидер табып, нәрсәгәдер ирешеп була. Бакировлар беркайчан да анда кермәгән һәм кермәячәк тә. Алар чиста калалар. Алар Афзаловлар пычракка бата-бата тапканны кулланучылар һәм «Сез гөнаһ кылдыгыз!» дип кычкыручылар гына. Җиңел, рәхәт яшәү бу, әмма башкалар хисабына. Менә шушы урында Афзалов үзен борчыган нәрсәнең үзәк тамырына килеп җиткәнен аңлады...» [Садриев, 2004: 353]. Рамазан Харисовичның әлеге уйланулары, үзенең «пычрануын» аңлау, күңеленнән Бакировның өстенлеген тануга китерә. Әмма әлеге хакыйкать белән килешәсе килмәү аны тагы да ярсыта, шуңа да ул карарын үзгәртеп, Бакировны пенсиягә озатырга була. Хикәядә кулланылган аерым деталь-күренешләр (Сылу белән булган күренеш,

күчтәнәч каз вакыйгасы һ. б.) җитәкче чиновник психологиясен, дөньяга карашын тирәнрәк ачуга ярдәм итүче үткен мисаллар булып тора.

Ф. Садриев яратып кулланган алымнарның берсе – чагыштыру. Күп очракта бу төп геройның антиподы аша башкарыла. Антипод – әсәр героена дөньяга карашы, холкы, яшәү рәвеше, зәвыгы белән капма-каршы сурәтләнгән сәнгати образ. Әлеге антипод фонында автор күрсәтергә теләгән сыйфатлар тагы да ачыграк чагыла. Ф. Садриевның антиподик образлары төрле әсәрләрендә очрарга мөмкин. Мисал өчен, «Гөлчәчәк» хикәясендәге Рәисә Әнисовна «Соңгы дәрес»тәге укытучы Наҗиянең капма-каршысы. Ике мөгаллимә дә чын күңелдән халыкка хезмәт итсәләр дә, үз балаларына, гаиләләренә мөнәсәбәттә аерылалар. Рәисә гаиләсен икенче планга калдырып ялгыша, шуңа үз балаларын тиешенчә тәрбияли алмый: кызы Сания бозык юлдан китә. Гомер азагы якынайганда ул үзенең салкын канлы булганлыгын, укучыларын да чын ихластан яратмавын, бары үз даны өчен яшәвен аңлый. Наҗия, киресенчә, үз балаларына да, укучыларына да бөтен җан җылысын биргән чын мөгаллимә буларак алга баса. «Соңгы дәрес» хикәясенең төп фикере Наҗиянең инде күптән мәктәп тәмамлаган укучысы Яруллин Дамирга бәйле ачыла. Малай авыр хәлле гаиләдә үсеп, беркемгә – хәтта әчкече әти-әнисенә кирәк булмаганда, Наҗия аны ялгыш юлга керүдән саклый. Дамир аркасында күп борчу-мәшәкатьләркүрергә туры килә аңа. Егет тормышта юлын таба: Себергә китеп, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый, үз бизнесын булдыра. Хикәя шул ноктада тәмамланырга да мөмкин булыр иде, әмма Ф. Садриев һәрвакыттагыча, тормыш турында фәлсәфи уйлануларга алып керә. Күптәнге укучы һәм карт мөгаллимә диалогы аша ул, берьяктан, укытучы һөнәренә ия булган кешене ана дәрәҗәсенә күтәрә (бу очракта хәтта өстенрәк тә куя), икенчедән, «кеше булу» гыйбарәсенең мәгънәсенә төшендерә. Тормышта байлыкка һәм дәрәҗәгә ирешү әле күрсәткеч түгел, намус, вөҗдан, бурычны түләү – менә кешене кеше итүче сыйфатлар. Наҗия «дәресе» Себердән апасын күрергә кайткан Дамирга гына түгел, башкаларга да сабак булып тора.

Ф. Садриевның прозасында игътибарсыз калдырырга мөмкин булмаган кызыклы гына тасвир чарасы бар. Ул да булса – герой кичерешләрен сурәтләгәндә исләрне файдалану. Укучының аң төпкеленә тәэсир итү максатында кайсы язучы төсләргә, кайсы тавышка, кайсы исләргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Мисал өчен, Н.Л. Зыховская «Сүз сәнгатенең ольфакториясе: проблеманың хәзерге торышы» мәкаләсендә рус әдәбиятында исләрне чагылдыруны өйрәнүгә багышланган хезмәтләргә күзәтү ясый, әлеге күренешнең һәр сәнгати дөньяның уникальлеген күрсәтүче дәлил булуы турында яза.

Ф. Садриевта альфактор (ис аша сурәтләнгән) мотивлар күбрәк табигать, туган җир белән бәйле бирелә. Болар: язгы бөре, шомырт чәчәге, җиләк, печән,

җир, туфрак, көз, иген, арыш, яңа пешеп чыккан икмәк, яңгыр һ. б. исләр. Шулай ук әсәрләрендә кар, яшен, кояш, хәтта таң исе дә очрый. Исләрне геройга мөнәсәбәт белдергәндә куллану очраклары бар. Мисал өчен, «Ишек» хикәясендә Нурулла Флорид кабинетына кергәч, затлы хушбуй исе сизсә, бераздан, Флоридның салкынлыгыннан әлеге ис аның «күзен әчеттереп җибәргәндәй» итә.

Иснең әдәби әсәрдә бирелеше ул – язучы белән укучы хәтере арасына салынган күпер. Тоеп була торган һәркемгә таныш: икмәк, яңгыр, җиләк исләрен хәтердә яңартырга мөмкин, ә менә авторның абстракт төшенчәләрне дә ис белән бирүе тагы да кызыклырак:

«Тургай әнисенең муеныннан кочаклап алды. Әнисе шундый җылы иде, аннан сөт, коймак, ипи исләре килде, йомшак чәчләре бәләкләрен рәхәт итеп кытыклады.

– Әнием, синнән җан исе килә!

– Ни дидең, улым, кабатла әле? – диде әнисе.

– Синнән җан исе килә, – диде Тургай» [Садриев, 2016: 27].

Язучының нинди исләргә еш мөрәҗәгать итүеннән без геройның рухи халәтен тагы да ныграк кичерәбез. Моннан чыгып, әдипнең психологик мотив буларак исне уңышлы куллана дип әйтә алабыз.

Ф. Садриев әсәрләренең теле, сүз белән сурәт ясау осталыгы турында аерым билгеләп үтү мөһим. «Тел-стильнең үтә дә нәфислеге, нәзакәтлеге, нечкәлеге; хис-кичереш дөньясының мәгърур музыкаль симфонияләрдәге шикелле бөек бер гармония һәм драматизм белән агышы; вакыты-вакыты белән югары романтиканың, ә кайчак иң-иң трагик аһәңнәр өскә калкып кеше рухиятенең гаять киң диапазонда һәм тирәнлектә-биеклектә чагылуы – болар барысы да бергә проза әсәрләренен шигърият белән якынайта, алар арасындагы чикне җуйдыр... Ф. Садриев прозасының кайбер урыннары (биргәк тә геройларның эчке кичерешләрен биргәндә, яисә табигать күренешләрен тасвирлаганда, яки автор үзе хисләнеп лирик кичерешләргә кереп китсә) нәкъ менә шундый – зур күләмле әсәрдән аерып шигъри әсәр кебек кулланырлык дәрәҗәдә сәнгатьледер» [Вәлиев, 2011: 92] дип яза Мансур Вәлиев. Язучы геройларының күңел халәтен сурәтләгәндә табигать тасвирын психологизмны үткенәйтү өчен оста файдалана. Менә «Рәхмәт, әтием!...» хикәясеннән өзек: «Күктәге кояш көлеп торса да, йөзгә бәреп язгы җил исә, ул кышның бәсле йөрәгенә соңгы мәртәбә батырып алынган хәнҗәр шикелле салкын иде, аның үткен, нечкә йөзе тәннең әллә кайсы төшләрен ачык урыннан да, кием аша да кисеп-кисеп үтә иде» [Садриев, 2015: 329]. Шул рәвешчә автор укучыны хәвефле, авыр кабул ителәчәк вакыйгага әзерли.

Йомгаклап әйткәндә, Ф. Садриев хикәяләренең геройлары – заман кешеләре. Язучы реалистик иҗат методының киң мөмкинлекләреннән файдалана: кеше холкындагы психологик халәтләрне иҗтимагый тормыш белән бәйләп сурәтли, шәхес азатлыгына һәм бәхетенә каршы булган җәмгыятьтәге тәртипләрне кискен тәнкыйть утына ала. Әсәрләрендә геройны чолгаган мохит төрле яклап яктыртыла. Бу геройның шәхси бәхете (мәхәббәте, гаилә мөнәсәбәтләре), иҗтимагый тормышы (кеше һәм җәмгыять), табигый асылы (кеше һәм табигать, туган җир, татар авылы) яссылыкларында карала. Ф. Садриевның әсәрләрендә һәркемне борчыган мәсьәләләр күтәрелә. Үзәктә – Кеше, аның бәхете. Ә бәхет исә язучы өчен рухи һәм матди бөтенлек, шәхес иреге. Боларга язучы беркемне кабатламаган образлы теле, искиткеч зәвыклы сурәт алымнары аша ирешә.

**Әдәбият**


1. *Вәли-Барҗылы М.* Намуслы кешеләр // Мәйдан. – 2011. – № 3. – Б. 82–95.

2. *Зыховская Н.Л.* Ольфакторий художественной словесности: современное состояние проблемы // Вестник Волжского университета имени В.Н. Татищева. – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/olfaktoriy-hudozhestvennoy-slovesnosti-sovremennoe-sostoyanie-problemy/viewer (мөрәҗәгать итү вакыты: 27.01.2021).

3. *Садриев Ф.* Рәхмәт, Әтием!.. // Дәверләр аһәңе: повестьлар һәм хикәяләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015. – Б. 328–341.

4. *Садриев Ф.* Тургай: бәян // Казан утлары. – 2016. – № 5. – Б. 8–46.

5. *Садриев Ф.* Ялгышны төзәтү // Көлми торган кеше: повестьлар һәм хикәяләр. – Түбән Кама: Ихлас, 2004. – Б. 325–358.



**Т.Ш. Гыйлаҗев**

Казан федераль университеты, Казан


## ТЕАТР ТӘНКЫЙТЕН ФОРМАЛАШТЫРУДА ҺӘМ ҮСТЕРҮДӘ ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ РОЛЕ


**Т.Ш. Гилазов**

Казанский федеральный университет, Казань


## РОЛЬ ГАЯЗА ИСХАКИ В СТАНОВЛЕНИИ И РАЗВИТИИ ТЕАТРАЛЬНОЙ КРИТИКИ


**Аннотация**. В статье исследуются театральные статьи классика татарской литературы и критика Г. Исхаки. Он, как и его современники, внес большую лепту в формирование и становление как сценического искусства, так и

театральной критики. В научной работе освещаются рассматриваемые в критике Исхаки актуальные вопросы национального театра. Выявляются тематика и жанры его статей, а также принципы и критерии оценивания сценических произведений. Г. Исхаки, анализируя пьесы и спектакли, формулировал основные принципы татарского театроведения.

**Ключевые слова:** татарская литература, драматургия, национальный театр, театральная критика, жанры, европеизация татар.

**Abstract.** The article examines theatrical articles of the classic of Tatar literature and criticism G. Iskhaki. He, as his contemporaries, made a great contribution to the formation and development of both the performing arts and theater criticism. The scientific work highlights the topical issues of the national theater considered in Iskhaki's criticism. The topics, genres of his articles, as well as the principles and criteria for evaluating stage works are identified. G. Iskhaki, analyzing plays and performances, formulated the basic principles of Tatar theater studies.

**Keywords:** Tatar literature, drama, national theater, theater criticism, genres, Europeanization of the Tatars.

Күренекле прозаик, драматург һәм публицист Гаяз Исхакыйның татар мәдәнияте тарихында үз урыны бар. Замандашларына хас булганча, Исхакый да төрле тармакларның иң алгы рәтләрендә булып, XX гасыр башында татар халкының рухи һәм мәдәни алгарышында мәгълүм роль уйный.

Яңарыш чоры татар әдәби-эстетик фикерендә әдәбият-сәнгать, музыка, җыр проблемалары төрле яссылыкта тикшерелә башлый. Яңа реалистик татар прозасына нигез салучы Г. Исхакыйның бу хактагы фикерләре игътибарга лаек. 1902 елда иҗат иткән «Ике йөз елдан соң инкыйраз» хыялый-публицистик повестенда милләтнең инкыйразы, бер бөтен халык булып яшәүдән юкка чыгуы хакында уйланганда, язучы татар дөньясында әдәбият һәм сәнгатькә мөнәсәбәт мәсьәләләренә дә кагыла. Татар әдәбияты, сәнгате проблемаларына иҗтимагый-милли яссылыктан якын килеп, аларны татар халкының алгарышын, мәдәни күтәрелешен тәэмин итүче, милләтне юкка чыгудан саклап калучы көч буларак карый.

Татар сәхнә тарихы Г. Исхакыйның драма, комедияләре, трагедияләре белән тыгыз бәйле. С. Рәмиев тарафыннан аның «Өч хатын белән тормыш», «Зөләйха», «Кыямәт», «Җәмгыять», «Тартышу», «Мөгаллим» күп уйнала торган мәшһүр әсәрләр төсендә билгеләнеп узыла. Татар сәхнәсе хәрәкәтендәге һәр вакыйга, театр труппаларының репертуары, басылып чыккан драма әсәрләре, тәрҗемә мәсьәләләре, профессиональ театр оешуда зур көч куйган шәхесләр һәм аларның язмышы, һөнәри әхлак кебек актуаль проблемалар Г. Исхакый тәнкыйтенең үзәгендә тора.

Г. Исхакыйның «Татар матбугаты» (1907) язмасы милли профессиональ театрның рәсми эшли башлавына бер ел тулу уңае белән язылган. Автор хикәяләр, шәкертләр тарафыннан романнар язылу, тәрҗемә итү шаукымының үтеп китүен әйтә. Театрлар уйналуга килгәндә, пьесаларга зур ихтыяҗ барлыкка килеп, күпләп драма әсәрләре языла башлауны бәян итә. Әмма бу эшкә һәр каләм иясенең зур җаваплылык тойгысы белән якын килергә тиешлеген искәртә: «Театр мәдәният галәмендәбер зур дәресханә булганга, монда уйналган нәрсәләр тыңлаучыларның әхлакларына тәэсир иткәнгә, яшьләргәтөрле идеаллар бирергә зур хезмәт иткәнгә, театрга бик зур әһәмият бирергә тиешлегендә һичкемнең шөбһәсе юктыр» [Исхакый, 2005: 113].

«Тавыш» газетасының 1907 елгы 21 май (5 нче) санында «Татар матбугаты» рубрикасында, «Театр мәҗмугасе» дөнья күрү уңае белән, Г. Исхакыйның «Театр китаплары» күзәтү рецензиясе басыла. Анда А.П. Чеховның «Предложение» водевиленнән Ш. Мөхәммәдъяров үзгәртеп эшләгән бер пәрдәле «Кыз сорау» (1907, Оренбург), шул ук рус драматургының «Желанные нежданные» водевиленнән Г. Кәрам үзгәртеп тәрҗемә иткән «Көтелмәгән кадерле кунак» (1907, Казан), С.И. Турбинның «Денщик подвел» водевиленнән Ә. Хәсәни үзгәртеп тәрҗемә иткән «Денщик Гали» (1907, Казан) бер пәрдәлек комедиясе басыла. Җыентыктагы өч комедиянең дә телләре татарча булса да, сурәтләнгән вакыйгаларның татар тормышыннан алынмавы, гайре табигый хәлләр сурәтләнеше, аларда милли рух сизелмәве Г. Исхакый тарафыннан кискен тәнкыйтьләнә, тискәре бәяләнә.

Гаяз Исхакый профессиональ театр оешып, аның ныклы адымнар белән атлавына чын күңелдән сөенә. Ул аны 1910 елда Төркиядә ясалган «Татар әдәбияты турындагы докладының татар мәдәниятендәге «масштаблы» тарихи вакыйга буларак бәяли. Театр барлыкка килүне инкыйразны саклап калуда һәм Аурупа мәднияте дәрәҗәсенә ирештерүдә әһәмиятле бер чара дип карый. Г. Исхакый әдәбиятның халыкчанлыгын нигездә драма әсәрләренә, реаль тормыштан алынып, татар сәхнәләренә чыгарылган типларга таянып дәлилли [Исхакый, 2005: 200].

Мәкалә авторы үз әсәрләреннән мисаллар китерә. «Кыямәт» комедиясенең Казан хәятыннан алынган надан муллалар белән аларга иярүчеләргә сатира булын, пьесадагы муллаларның, сәүдәгәрләрнең шәхес булмыйча, ә «тип»лар икәнен әйтеп чыга. Әдәби әсәрләрдә хатын-кыз типларының милли чынбарлыктан алынуын, әсәр тукымасында аларның әһәмиятен билгели. Г. Исхакый татар әдәбиятында хатын-кызларның тышкы кыяфәтен, ягымлылыкларын, җисемнәрен сурәтләүгә караганда, аларның эчке дөньяларын, рухи гүзәллекләрен тасвирлауга зур әһәмият бирелүен ассызыклый.

Театр сәхнәләрендә татар язучыларының драма әсәрләре уйналу, актер һәм актриссаларның татар халкы вәкилләре, бары татарлар гына булу профессиональ театрның хосусиятләре төсендә ассызыклана. Аларның һәркайсысының тәрбияле, намуслы югары әхлак иясе булуын, театрның әдәп дәресе икәнлеген күрсәтә. Г. Кариев, С. Гыйззәтуллиналарның уен осталыгына соклана. Оешкан театр труппаларының репертуары проблемасына тукталып, Г. Камал, Ф. Әмирхан һәм үз драма әсәрләренең сәхнәләрдә күп уйналуын билгеләп уза.

Гаяз Исхакыйның 1915–1916 елларда бер-берсе белән тематик яктан тыгыз бәйләнгән «“Сәйяр” труппасы хакында» (Ил, 1915, 9 гыйнвар), «Милли йитешсезлекемез» (1915), «Габдулла Кариев» (Ил, 1915, 13 март), «Халык театры съездында мөхтәрәм Гаяз әфәнде тарафыннан бирелгән доклад (татар театрының кыскача тарихы)» (Сүз, 1916, 4 гыйнвар) мәкаләләре дөнья күрә. «Габдулла Кариев» мәкаләсендә күренекле режиссер һәм актер Г. Кариевның сәламәтлегенең какшавы сәбәпләрен ачуга нисбәтле, татар галәмендә милли профессиональ театрының, конкрет алганда «Сәйяр» труппасының, авыр шартларда барлыкка килүе, ул юлда туган каршылыклар этрафлы бәян ителә. Мәкалә авторы, авырлыкларга карамыйча, «Сәйяр» труппасын оештырган, театр эшен җайга салган Кариевка мәдхия укый [Исхакый, 2008: 49].

Бу елларда спектакльләр кую өчен рөхсәт алу, фанатиклар, куштаннар белән ике араны көйләү, билетларны тарату, иң авыр рольләрне башкару, кичен театр уйнау өчен төрле кара эшләр башкару Г. Кариев сәламәтлегенә тәэсир итүе күрсәтелә. Г. Исхакыйның режиссер һәм актер эшчәнлегенә җентекле анализы татар пофессиональ театры үткән авыр юл булып гомумиләшә.

Г. Исхакый мөһаҗирлектә Г. Кариевның үлүенә 16, тууына 50 елтулу уңаеннан бу темага яңадан әйләнеп кайта. 1936 елда «Яңа милли юл» журналының 12 санында «Гаяз Исхакый» имзасы белән «Артист Габдулла Кари» дигән мәкаләсен бастыра. Автор тагын бер кат Г. Кариевның татар мәдәнияте тарихында тоткан урынын югары бәяли: «Ул үзенең кыска тормышында безнең мәдәни үсү тарихыбызда һичбер онытылмаячак эзләр калдырды. Безнең яшь театрыбызның үсүен, алга китүен һичбер аерылмый торган итеп үзенең исеме берлә баглады һәм аны мәдәни тормышыбызда мәңгеләштерде» [Исхакый, 2011: 292]. Г. Исхакый Г. Кариевның 1913 елдан алып 1920 елның 28 январена кадәр тормыш юлын, хакимияткә большевиклар килгәч, гомеренең авыр, хәвефле елларын бәян итә, шуның белән бу күренекле шәхеснең фәнни биографиясен яңа штрихлар белән баета. Күренекле артистның катлаулы яшәешен хикәяләү катлаулы елларда татар театры мәсьәләләре белән үрелеп китә.

«Татарча театр вә концерт», 1915 нче елның ахыры 1916 елның башында Мәскәүдә Бөтенроссия халык театрлары корылтае үткәрелү уңае белән язылган «Милли йитешсезлекемез» дип аталган мәкаләләрендә Г. Исхакыйның

гражданлык позициясе, милләтпәрвәрлеге сәхнә тарихы мәсьәләләренә нисбәтле дә раслана. «Татарча театр вә концерт» язмасында актерларның осталыгы, драма әсәрләрендәге типларны, аларга йөкләнгән идея-эстетик вазифаны дөрес ачу,театр труппаларының һәм тамашачыларның җаваплылыгы, профессиональ әхлагы турында сүз алып бара.

Г. Исхакый татарның театры, әдәбияты, матбугаты һәм җәмәгать эшләре читтән карап тора торган, эшләгән эшләрне хаксызга тәнкыйть итә торган елавыкларга түгел, ә хезмәтнең кадерен белүче, шул хезмәтләр өчен матди, мәгънәви көчләр сарыф ителүен аз гына булса да аңлый торган, җәмәгать эшләренең вазифасы да, бурычы да барлыгын белә торган затларга мохтаҗлыгын тәкърарлый.

«Халык театры съездында мөхтәрәм Гаяз әфәнде тарафыннан бирелгән доклад» «Сүз» газетасының 1916 елгы 14 гыйнвар (10 нчы) санында басылган. Мәгълүм булганча, Мәскәү шәһәрендә 1915 елның 27 декабреннән алып 1916 елның 5 гыйнварына кадәр халык театрларның съезды була. Анда рус театры хезмәтчәннәреннән тыш, башка милләтләрнең дә театр хезмәтчәннәре (театр эшлеклеләре, милли театрның оештыруга көч куйган зыялылар – Т.Г.), җәмгысе 400 гә якын вәкилләр чакырылган. Татарлардан «Сәйяр» труппасы артистларыннан Габдулла Кариев, Өммегөлсем Болгарская, драматурглардан Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый, артистка Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Мохтар Мутин чакырылалар. Г. Исхакый Идел буе сәхнә тарихына багышланган «Идел буе театрларының театры тарихы» дигән доклад ясый. Мәҗлес халык (эшче, крестьяннар – Т.Г.) театрлары булдыруга күп хезмәт куйган академик В.Д. Поленов рәислегендә барган.

Г. Исхакый докладта кыска вакыт эчендә милли театрның тууы, аның үсеш этаплары, тарихы турында доклад әзерли һәм съездда чыгыш ясый. Әдип башта татар театры сәнгатенең тәүге адымнарын бәян итә. Мәкалә авторы милли профессиональ театр барлыкка килү вакыйгасын, бер яктан, Россия күләмендәге үзгәрешләр, икенче яктан, татар халкының иҗтимагый-рухи дөньясындагы үзгәрешләр, төгәлрәк әйткәндә, ислам дөньясын хәрәкәткә китергән «уйгану дәвере» контекстында бәяли [Исхакый, 2008: 119].

Г. Исхакый докладында милли профессиональ театрның үсшенә каршылык тудырган көчләр билгеле бер ситемага салына. Ул театр сәхнәсенә каршы көрәшкәнтатар милләтенең үз эчендәге көчләрнең төрле катламын, аларның төрле юнәлештәге хәрәкәтен аерып чыгара. Беренчедән, афишалар эленү белән иске карашлы татарларның, фанатик хаҗиларның һәмдин әһелләренең, театрны халыкның рухын, әхлагын бозуда гаепләп, аны булдырмау нияте белән, җирле хөкүмәт чиновникларына мөрәҗәгать итүләре әйтелә. Аның белән генә калмыйча, театр биналарына, спектакльдән соң өйләренә кайткан уенчыларга

һөҗүм оештырулары ассызыклана. Икенчедән, муллаллар мәчетләрдә вәгазь укыганда, мөселманнарны төрле ялганнар, яла ягулар белән куркыталар, театрга дин исеменнән ләгънәт яудыралар. Өченчедән, драма әсәрләрендә сурәтләнгән вакыйгаларны, геройлар язмышын турыдан-туры аңлап, аларда үзләре, гаиләләре хәяты тасвирланган дип уйлап, аерым байлар, муллалар китап хакында донослар язалар [Исхакый, 2008: 120].

Г. Исхакый милләт эчендәге һәм җирле губерна дәрәҗәсендәге киртәләрне аерып куйганнан соң, патша хөкүмәте югарылыгындагы каршылыкларны шәрехләүгә күчә. Петроградта Матбугат эшләре Баш управлениесендә күп миллионлы татарларның сәхнә әсәрләре өчен бер генә цензор булып та, аның да эш-гамәлләренең кагыйдә, матдәләр, устав белән билгеләнмәвенең татар театры үсешенә зур тоткарлык ясавын ассызыклый.

Г. Исхакый мәкаләнең йомгак өлешендә хөкүмәт алдына бүген дә актуальлеген югалтмаган таләпләр куя, иҗтимагый-милли һәм гомумкешелек кыйммәткә ия булган проблемаларны ассызыклый. Патша самодержависенең милли-колониаль изү сәясәтен фаш итә. Тирән һәм үткен фикерле публицист буларак, ул татар театрының «милләт театры дәрәҗәсенә үсешен Россиядәге «хокукый үзгәрешләр», эчке сәяси һәм итҗтимагый вазгыять белән бәйле булуын ассызыклый. Татар театрының юридик җәмгыять статусы дәүләт югарылыгында расланып, «мөселманнарның җәмгыятьләргә оешу хакындагы кысынкылыклар» бетерелүен, цензура органының үзгәрергә тиешлеген дәгъвалый. Иң әһәмиятлесе: татар теленә Россиядәге башка телләр белән бер дәрәҗәдә хак бирелеп, аның бөтен чикләүләрдән азат ителүен таләп итеп чыга, «...дүртенче, татар теленә Русиядәге бөтен телләр берлән бер хак бирелеп, татар теленең бөтен кысынкылыклардан хөр ителүе ляземдер» [Исхакый, 2008: 122].

Күренә ки, Г. Исхакыйның театр тәнкыйтенә караган мәкаләләре татар сәхнә сәнгатенең күптөрле проблемаларын яктырта: милли профессиональ театрның авыр һәм катлаулы, салулы тарихы, юлында очраган каршылыклар; театр труппаларының репертуары, группаларның профессиональ әхлагы һәм җаваплылык; тамашачы зәвыгы, татар галәмендә актерлар һәм актриссалар, аларны әзерләү; татар театрының иҗтимагый һәм рухи кыйммәте һәм башка проблемалар шәрехләнә.

## Әдәбият

1. *Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 т. / төз. З. Рәмиев, Ф. Ибраһимова; текст. әзерл. Ф. Ибраһимова, аңл. һәм искәрм. әзерл. З. Рәмиев. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2001. – Т. 6: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре (1902–1914). – 447 б.

2. *Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 т. / төз. Ф. Ибраһимова, З. Рәмиев, Э. Галимҗанова; текст. әзерл. Ф. Ибраһимова, Э. Галимҗанова; иск. һәм аңлат. һәм иск. әзерл. З. Рәмиев, Э. Галимҗанова, Г. Ханнанова, Ф. Кадыйрова. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2008. – Т. 7: Публицистика (1915–1916). – 366 б.

3. *Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 т. / төз., текст., иск. һәм һәм аңлат. әзерл., кереш мәкалә авторы З. Мөхәммәтшин. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. – Т. 11: Публицистика (1934–1936). – 399 б.

**Т.Ш. Гыйлаҗев, А.Р. Хәбибуллина**
Казан федераль университеты, Казан

## Ф. ӘМИРХАН ЭПИК ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МӘДӘНИ ШӘХЕС МӘСЬӘЛӘСЕ

**Т.Ш. Гилазов, А.Р. Хабибуллина**
Казанский федеральный университет, Казань

## КУЛЬТУРНАЯ ИДЕНТИЧНОСТЬ ЛИЧНОСТИ В ЭПИЧЕСКИХ ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Ф. АМИРХАНА

**Аннотация.** В данной статье рассматривается культурная идентичность личности в эпических произведениях Ф. Амирхана, в литературно-философском контексте начала XX в. Задачей исследования является установление общих и своеобразных черт литературных образов. В статье анализируются повести «Фатхулла хазрат», «Хаят» и роман «На распутье», дается объяснение понятия «культурная идентичность личности». В процессе анализа эпических произведений Ф. Амирхана определяется культурная идентичность литературных образов.

**Ключевые слова:** культурная идентичность, личность, образ, идея, мотив, тема.

**Abstract.** This article examines the cultural identity of the individual in the epic works of F. Amirkhan in the literary and philosophical context of the early twentieth century. The aim of the research is to establish the general and peculiar features of literary images. The article analyzes the novels “Fathullah Hazrat”, “Hayat”, and the novel “At the Crossroads”. The article explains the concept of “cultural identity of the individual”. In the process of analyzing the epic works of F. Amirkhan, the cultural identity of literary images is determined.

**Keywords:** cultural identity, personality, image, idea, motive, theme.

Мәдәни тәңгәллек – шәхеснең үсешенә тәэсир итә торган иң мөһим һәм фәнни хезмәтләрдә еш телгә алынган терминнарның берсе. Шәхеснең үз-үзен нинди дә булса төркем өлеше итеп хис итүе – аның психологик тотрыклыгы нигезе.

Мәдәни тәңгәллек билгеле бер берләшмә әгъзасының аерылгысыз һәм мәҗбүри сыйфаты. Мондый берләшмә табигый рәвештә, традицион тәртип белән үссә, шәхес тә аннан аерылгысыз үсеш кичерә. Тышкы тирәлекнең тотрыксызлыгы мәдәни тәңгәллекнең нигезләрен җимерә. Шәхес үз-үзен югалта. Әлеге мәкаләдә Ф. Әмирханның «Хәят», «Фәтхулла хәзрәт» повестләрендә һәм «Урталыкта» романында урын алган мәдәни шәхесләргә күзәтү ясалыр.

И. Нуруллин билгеләп киткәнчә, Ф. Әмирхан беренче әсәрләреннән үк әһәмиятле типлар, кызыклы характерлар белән зур мәсьәләләр күтәрә [Нуруллин, 1982: 288]. Р. Ганиева үзенең хезмәтләрендә Ф. Әмирхан «Фәтхулла хәзрәт» повесте һәм башка әсәрләре белән XX гасыр башы татар әдәбиятына яңа, моңа кадәр милли әдәбиятта күренмәгән геройлар алып килүен билгели. «Болар – яңа чор рухында тәрбияләнеп үскән европача карашлы, зыялы яшьләр. Алар узган гасырның традицияләрен яхшы беләләр, дөнья мәдәниятен югары бәялиләр» [Ганиева, 2016: 101]. Аның фикерен Д. Заһидуллина да яклый. Модернизм фәлсәфәсе йогынтысында XX нче гасыр башы татар әдәбиятында интеллегент һәм интеллектуаль үскән, татар җәмгыятендә үз урынын табарга омтылган яңа герой мәйданга чыга. Яңа герой үзен милләтнең өлеше итеп хис итә, аның вәсвәсә-кайгыларын авыр кичерә. Милли үзаңны торгызу белән беррәттән, татар мәдәниятен Европа үрнәгендә үстерүгә омтылыш тенденциясе билгеләнә [Загидуллина, 2013: 85]. Экзистенциаль компонент җәмгыятьнең һәм милләтнең торышы эчтәлегендә бирелә. Шунлыктан, күп кенә әсәрләрдә этник үзаңны уяту концепциясе үзәккә чыга, татар җәмгыятенең яшәеше экзистенциаль сыкрану сәбәбе була. Әдәби герой татар җәмгыятенең чын торышын аңлау процессында бирелә.

1909 нче елда язылган «Фәтхулла хәзрәт» сатирик повестенда «иске фикерле руханиларга хас сыйфатлар туплаган» Фәтхулла хәзрәт образыүзәктә тора. Фәтхулла хәзрәт әсәр башыннан таныш булмаган киңлеккә, ягъни киләчәккә эләккән итеп тәкъдим ителә. Фәтхулла хәзрәт «уянып» үзен руслар арасында дип уйлый. Иялэнгән дөньясыннан читтә булганга,герой төрле көлкеле вакыйгаларга дучар. Ф. Әмирхан Фәтхулла хәзрәт ярдәмендә XX йөз башындагы кара көчләрнең, кадимчеләрнең тискәре сыйфатларын туплаган җыелма образ тудыра.

«Фәтхулла хәзрәт» комедиясендә образлар мәгърифәтчелек реализмындагыча уңай һәм тискәрегә төгәл аерыла. Уңай персонажлар – Әхмәт, Нәфисә, Зыя, Ләйлә, хадимә Сәгъдия, мөхәррир, имам, Чыңгызлар. Р. Ганиева да

хезмәтендә Ләйләнең, Әхмәтнең яңа чор рухында тәрбияләнеп үскәнлеген, яңа геройлар икәнлеге ассызыклана [Ганиева, 2016: 101]. Яңа чор геройлары татар булулары белән горурланалар, милләт өчен җан атып яшиләр. Алар татар милләтен үстереп, башка милләтләргә таныта алырлык шәхесләр итеп сурәтләнә.

Ф. Әмирханның эпик әсәрләрендә үз-үзен эзләүче геройлар калкып чыга. 1911 елда язылган «Урталыкта» романының төп герое – Хөсәен Арсланов. Әлеге образга галимнәр төрле бәяләмәләр бирә. Ул уңай һәм тискәре образ дип тә, урталыкта торучы образ дип тә бәяләнгән [Ганиева, 2016: 104]. Фәтхулла хәзрәттән аермалы буларак, Хөсәен рус мәдәниятенә тартыла, шул ук вакытта татар булуын да күрсәтә. Хөсәен татар мәдрәсәсен тәмамлаган. Белемнәренең җитеп бетмәвен аңлап, үзлегеннән русча укыган. Аның бүлмәсендә Пушкин, Тургенев, Толстой һ. б. атаклы язучыларның, галимнәрнең рәсемнәре эленгән. Аның киенүе дә европача. Ләкин Хөсәен – бәргәләнүче образ. Ул «татарщина”ны да кабул итми, шул ук вакытта инкыйлаби фикерләр белән дә ризалашмый. Әлеге обаз аша Ф.Әмирхан XX йөз башы татар әдәбиятына импрессионистик стильгә корылган проза кертә, үз киләчәге өчен борчылучы, кәефсезләнүче шәхес тәкъдим итә.

«Хәят» повестендә ике дөньда бәргәләнүче образ бирелә. Хәят Шәрык әхлагы белән тәрбияләнгән, ләкин аның тормышына европача, русча яшәешнең тәэсире көчле. И. Нуруллин Ф. Әмирханның Хәяте иҗтимагый мөнәсәбәтләр белән тыгыз мөнәсәбәттә күрсәтелә дип исәпли [Ганиева, 2016: 102]. Хәят үзенең татарлыгын аңлый, вечерлардан кайткач, озаклап догалар укый. Әмма аңа рус мәдәнияте дә кызыклы. Хәят Лиза белән төрле чараларда була, яңа дуслар таба. Ике мәдәниятнең капма-каршы килүе Хәятнең җанын газаплый, күңелен борчый. Әлеге конфликт повестьнең башыннан ахырына кадәр дәвам итә, ләкин чишелми кебек. Повесть Хәятнең Аллаһка үтенече белән тәмамлана.

Ф. Әмирхан «Хәят»не романтик әдәбият билгеләре белән баета. Татар һәм рус мәдәниятенең тәэсире һәм каршылыгы нәтиҗәсендә драматизм, психологизм, лиризм тирәнәя.

Шулай итеп, Ф. Әмирханның эпик әсәрләрендә яңа чор рухында тәрбияләнеп үскән европача карашлы, зәвыклы, каршылыклы, бәргәләнүче, үз-үзен табырга омтылучы шәхесләр урын ала. Фәтхулла хәзрәт кара көчләрне фаш итүче җыйма образ булса, Хөсәен һәм Хәят бәргәләнүче, үз-үзен эзләүче геройлар. Әхмәт һәм Ләйлә милләт өчен җан атучы, аны үстерергә теләүче буларак тәкъдим ителә. Ф. Әмирханның эпик әсәрләрендә татар милләтенең төрледән-төрле шәхесләре урын ала.

**Әдәбият**

1. *Загидуллина Д.Ф.* Модернизм в татарской литературе первой трети XX века. – Казань: Татарское книжное издательство, 2013. – 207 с.

2. *Мәһдиев М.С.* Сызып ак нур беләл...: шәхесләребез тарихыннан: фәнни-публицистик мәкаләләр / төз. Г.Хәсәнова; кереш сүз авторы Д. Заһидуллина]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. – 583 б.

3. *Ганиева Р.К.* XX гасыр башы татар модернистик әдәбияты һәм Фатих Әмирхан. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2016. – Б. 29–36.

4. *Гыйлаҗев Т.Ш.* Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2008. – 254 б.

5. Нуруллин И.Ш. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1982. – 285 б.

**Р.Р. Гилязова, А.Х. Ашрапова**
Казанский федеральный университет, Казань

# ИНТЕРАКТИВНЫЙ ПОДХОД ПРИ ОБУЧЕНИИ РОДНОМУ (ТАТАРСКОМУ) ЯЗЫКУ ДЕТЕЙ МЛАДШЕГО ШКОЛЬНОГО ВОЗРАСТА

**Аннотация.** В статье рассматривается возможность использования методики интерактивного обучения в начальной школе для изучения татарского языка, раскрываются основные понятия касательно темы, приводятся задачи и преимущества ведения интерактивных тетрадей и их применение в изучении разделов грамматики, лексики, говорения. Данный вопрос на сегодняшний день актуален ввиду популярности интерактивных новшеств.

**Ключевые слова:** интерактивное обучение, интерактивная тетрадь, познавательная деятельность, самостоятельность.

**Abstract.** The article throws light upon the positive effect of using interactive teaching methods at primary school in learningTatar. It reveals the basic concepts of the topic, presents the tasks and advantages of maintaining interactive notebooks and their application in the study of grammar, vocabulary, and speaking sections. This issue is currently relevant due to the popularity of interactive innovations.

**Keywords:** interactive learning, interactive notebook, cognitive activity, independence.

Современное образование все больше нацелено на то, чтобы воспитать у школьников положительное отношение и интерес к процессу обучения. Следовательно, многие преподаватели ищут способы, позволяющие удержать внимание детей на предметеи мотивирующих на получение знаний. Мастерство современного педагога заключается в активации познавательной деятельности учащихся, стимулировании интереса к процессу обучения.

Среди множества современных идей и технологий преподавания одним из действенных методов является методика интерактивного обучения. Интерактивное обучение – это способ познания, при которой учащиеся взаимодействуют друг с другом, обмениваются информацией, оценивают действия друг друга и свое собственное поведение,совместно решают проблемы, моделируют ситуации и погружаются в них [Щукин, 2017: 7].

Интерактивное обучение всравнении сдругими формами обучения, наиболее точно отвечает потребностям современного мира вподготовке квалифицированных кадров, способных адаптироваться под постоянно изменяющиеся условия. Вэтой связи винтерактивном обучении приоритет отдается двум ключевым задачам. Первая задача – «научить учиться», так чтобы человек мог самостоятельно развивать свою индивидуальность, иметь возможность эффективно работать сбольшими информационными массивами, вычленяя иосваивая то, что требуется для решения текущих вопросов. Вторая задача – «научить применять напрактике новые знания» [Райс, Карпенко, 2020: 5].

Интерактивная тетрадь – это современная форма ведения тетради учащегося, которая помогает активно участвовать, анализировать, взаимодействовать с новой информацией на занятиях. Можно утверждать, что такая тетрадь предоставляет ребенку возможность в любое время рассмотреть, изучить, повторить учебный материал в занимательном виде.

Методика преподавания с интерактивными тетрадями была создана американцами для обучения начальных классов для решения следующих задач:

– структурирование и компактная организация информации по изучаемой теме;

– практическое использование теоретической информации;

– детальное понимание и запоминание информации по изучаемой теме;

– многократное повторение изучаемого материала;

– закрепление материала по пройденной теме с учетом различных способов восприятия информации детьми (аудиалы, визуалы, киностеты и дискреты) опираются на логику;

– визуализация теоретического материала;

– развитие творческого мышления учащихся [Вавилова, Панина, 2008: 2].

Преимущества интерактивных тетрадей следующие:

– визиализируется грамматическая теория, что облегчает понимание материала;

– дети учатся систематизировать информацию, практически использовать материал;

– развивается творческий потенциал детей, повышается мотивация к изучению предмета;

– с помощью интерактивных тетрадей будние уроки оживляются.

Интерактивная тетрадь отвечаеттребованиям государственного стандарта в силу следующих характеристик:

– информативен;

– вариативен, т. е. возможно несколько вариантов использования;

– полифункционален, т. е. способствует развитию творчества, воображения, мышления, внимания, логики и памяти ребенка;

– имеет дидактические свойства;

– представляет собой средство для художественно-эстетического развития учащегося;

– обеспечивает игровую, познавательную, игровую, творческую и исследовательскую деятельность активность обучающихся.

Изучение родного языка в начальной школе – это сложный и познавательный курс, содержащий знакомство с буквами, цифрами, изучение новой лексики, знакомство с грамматическими формами и конструкциями, улучшение произношения и общения. Иными словами, программа направлена на усвоение и развитие аудирования, чтения, письма и говорения. Перед педагогом начальных классов стоит сложная задача не только сформировать у учащихся устойчивый интерес к изучению родного языка, но и заложить прочные основы для дальнейшего изучения. Сделать процесс изучения языка эффективным и в то же время интересным и захватывающим помогаютсобранные в интерактивную тетрадь флэпбуки, разные книжечки с окошками, книжки-гармошки, карточки, которые помогают визуализировать грамматическую и лексическую теорию, развить моторику, творческий потенциал детей и быстро усвоить материал. В этом возрасте необходимо применить относительно усложненные шаблоны с словесным содержанием, карточки, наполненные схемами и конструкциями.

Как правило, ученики младших классов очень подвижны, энергичны и эмоциональны, поэтому задания в форме игр (ролевые игры являются неотъемлемой частью интерактивной тетради) позволяют направить энергию детей в правильное русло и сконцентрировать внимание на обучении. Без сомнений, применение полифункциональной интерактивной тетради способствуют развитию творчества, воображения, мышления, внимания, логики и памяти ребенка.

Интерактивные тетради могут применяться в изучении следующих разделов: грамматика, лексика, говорение.

При обучении грамматике, как и при работе с другими аспектами языка, учебный процесс проходит в три этапа: ознакомление и первичное закрепление, тренировка, применение изучаемого материала с выходом в речь. Однако третий этап при работе над грамматическими навыками в школе опускается, при этом игнорируется коммуникативный характер отработки грамматических структур [Рогова, Рабинович, Сахарова, 1991: 6]. При изучении грамматики ребенок, создавая интерактивную тетрадь, развивает зрительную память, которая преобладает у большинства людей. В то время как учащийся оформляет грамматическое правило или какую-нибудь конструкцию самостоятельно с помощью ярких карандашей, разноцветных бумаг, любимых наклеек он делает это с большим интересом, так как процесс создания доставляет ему удовольствие. Красиво оформленное, украшенное с душой грамматическое правило хочется повторять снова и снова.Установлено, что материал в такой форме запоминается лучше, чем любое правило из учебника. Ведь все, что создается руками, ценнее. Таким образом, с помощью интерактивной тетради можно систематически и наглядным образом освоить такие грамматические темы как «Сүз төркемнәре» («Части речи»), «Килеш төрләре» («Виды падежей»), «Фигыль заманнары» («Времена глаголов»), «Кушымчалар төрләре» («Виды окончаний»), «Исемнәрнең күплек саны» («Множественное число существительных»), «Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр» («Имена собственные и нарицательные»), «Сүз кушылу ысуллары» («Способы словообразования») и т. д. Овладение большим словарным запасом крайне необходимо для изучения любого языка. Интерактивные тетради уникальны и тем, что усвоение лексики через флэпбуки, книжки-раскладушки гораздо продуктивнее, чем традиционно «зубрить» слова, которые через две недели забудутся. Можно утверждать, что чем больше органов чувств задействовано – зрение, моторика, слух – тем эффективнее результат. Иными словами, когда ребенок открывает интерактивную тетрадь и видит слова с соответствующими картинками, проговаривает их, он ассоциативно запоминает новую лексику.В интерактивной тетради новые словараспределены по тематикам («Гаилә», «Җиләк-җимешләр һәм яшелчәләр», «Хайваннар дөньясы», «Төсләр», «Саннар», «Ел фасыллары»), тетрадь украшена красочными рисунками, ключевые слова выделены жирным цветом, чтобы при пролистывании сразу бросались в глаза. Выявлено – с помощью такой интерактивной тетради выученный материал сохраняется в долгой памяти.

Всем известный факт: «Чтобы выучить язык, нужно, прежде всего, на нем говорить». Часто в школах для развития речи учителя задают детям выучить готовый диалог из учебника, что доставляет ученикам много усилий и труда, но приносит скудные результаты. В итоге учитель ставит оценку не столько за выработанный навык говорения, как за память учащегося. Таким образом, дети

вместо того, чтобы говорить, привыкают пересказывать «вызубренный» текст. Тут мы задаемся вопросом «Есть ли более продуктивный метод?» В данном случае ролевые игры, которые являются неотъемлемой частью интерактивной тетради, производят яркое впечатление и эффективным образом развивают навыки говорения. Каждый ученик, принимая определенную роль и используя подсказки в тетради, начинает строить собственные, незаученные, уникальные диалоги, тем самым воображая себя участником реальной жизненной ситуации. Учащимся начальных классов можно предложить игры «Кибеттә», «Мәктәптә», «Өйдә», «Театрда», где в каждом из них ребенок, погрузившись в смоделированный мир, начинает выражать свои мысли на изучаемом языке. Несомненно, превращая учебу в игру, можно вовлечь интерес ребенка на процесс обучения и добиться отличных результатов.

Таким образом, внедрение интерактивной тетради способствует развитию творчества, внимания, памяти, воображения, мышления и логики. Использование таких тетрадей на уроках вовлекает всех обучающихся, позволяет сделать процесс обучения активным как для учителя, так и для учащихся.

Интерактивная тетрадь – это не просто современнный метод обучения, помогающий развить познавательную, творческую активность ученика, эффективно усвоить и повторить материал на уроке, это полет фантазии, который в последующем может дать превосходные непредвиденные результаты.

## Литература

1. *Аркадьев А.Г., Днепров Э.Д.* Государственная программа по английскому языку для общеобразовательных школ Министерства образования Российской Федерации. – М.: Дрофа, 2013. – 118 с.

2. *Вавилова Л.Н., Панина Т.С.* Современные способы активизации обучения: учебное пособие. – 4-е изд., стер. – М.: Академия, 2008. – 176 с.

3. *Малышева Т.В.* Влияние методов интерактивного обучения на развитие коммуникативной компетенции учащихся // Учитель в школе. – 2010. – № 4. – С. 14–16.

4. *Пассов Е.И.* Коммуникативное иноязычное образование. – Липецк: Липецкий государственный педагогический институт. – 1998. – 299 с.

5. *Райс О.И., Карпенко Е.А.* Интерактивные технологии в обучении. Педагогика нового времени. – Екатеринбург: Ridero, 2020. – 80 с.

6. *Рогова Г.В., Рабинович Ф.М., Сахарова Т.Е.* Методика обучения английскому языку в средней школе. – М.: Просвещение, 1991. – 287 с.

7. *Щукин А.Н.* Методы и технологии обучения языкам. – М.: Икар, 2017. – 240 с.

**Э.Н. Денмөхәммәтова**
Казан федераль университеты, Казан

# ӘДӘБИ ТЕКСТЛАРДА ЧАГЫШТЫРУЛАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ТӘРҖЕМӘДӘ БИРЕЛЕШЕ

**Э.Н. Денмухаметова**
Казанский федеральный университет, Казань

# СРАВНЕНИЯ В ЛИТЕРАТУРНОМ ТЕКСТЕ И В ЕГО ПЕРЕВОДЕ

**Аннотация.** В работе рассматриваются вопросы перевода сравнений, как одного из видов тропов. На примере произведений А. Гилязова показывается разные формы передачи сравнений в переводных текстах на русский язык. Акцент делается на то, что в татарском языке авторы любят использовать сравнительные конструкции с послелогами, а в переводе они передаются разными грамматическими формами.

**Ключевые слова:** сравнения, послелог, перевод, художественный текст.

**Abstract.** The paper deals with the issues of translation of comparisons, as one of the types of tropes. The author shows the different forms of the transfer of comparisons in translated texts into Russian using the example of A. Gilyazov's works. The emphasis is on the fact that in the Tatar language, authors like to use comparative constructions with postpositions, and in translation they are transmitted by differ.

**Keywords:** comparisons, postpositions, translations, literary texts.

Тәрҗемә төрле милләт халыкларының аралашуына, аңлашуына, рухи хәзинәләр алмашуына хезмәт итә. Шунлыктан аның төп принциплары барлык телләр, тәрҗемә ителә торган барлык материал өчен уртак. Иң мөһиме – төп нөсхәнең эчтәлеге һәм формасы берлегән мөмкин кадәр тулырак саклау. Бу исә тәрҗеменең катлаулы төре – матур әдәбият әсәрләрен башка телдә тәкъдим итүдә шактый кыенлыклар тудыра. Телләр, фикерләр һәм менталитет төрлелеге автор әйтергә теләнгән фикерне тәрҗемәче тарафыннан төгәл белдерүгә ирешү җиңел дә, гади гамәл дә түгел.

Авторлар үз әдәби әсәрләрендә тел- сурәтләү чараларыннан бик еш файдаланалар. Троплар яки ассоциотив чаралар, күчерелмә мәгънәне төрле әйберләр, күренешләр, предметлар арасындагы бәйләнеш аша барлыкка китерә торган гыйбарәләр әдәби әсәрнең һәркайсында диярлек бар. Алар әдәбиятта образ тудыру, текстның тәэсир көчен арттыру, сурәтләнә торган күренеш-халәтне

укучы күз алдына төгәл китереп бастыру өчен хезмәт итәләр [Әдәбият белеме: 191]. Троплар исәбенә кергән чагыштыру да, авторлар тарафыннан актив кулланылышта. Алар нинди дә булса күренешне башка күренешкә охшату ярдәмендә барлыкка килгән сурәтләү чарасы. Рус һәм татар теленең чагыштырма компаратив конструкцияләренең семантикасын тикшерү әлеге тел берәмлекләренең семантик төзелешендәге барлык аермаларны, мили специфик үзенчәлекләрен табуга ярдәм итә. Татар телендә чагыштырулар башка сурәтләү алымнарына караганда күбрәк кулланыла. Сөйләмне мәгънә һәм эчтәлек ягыннан баетуда, аны матурлауда алар зур эш башкаралар. Язучы образларга характеристика биргәндә, чагыштыруларны бик уңышлы файдалана. Вакыйгаларны җанлы тасвирлауның, образлылыкның уңай үрнәкләрен Аяз Гыйләҗев иҗатында да күпләп табарга мөмкин.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә чагыштыруның түбәндәге билгеләре санала:

1. Күренешләрнең, предметларның һ. б. охшашлыкларын яки аермаларын яисә берсенең икенчесеннән өстенлеген билгеләү, ачыклау өчен тикшерү.

2. Кем яки нәрсә белән булса да тиңләү, кемгә яки нәрсәгә булса да охшату.

3. Бер предметны икенче предметка охшатуны эченә алган фраза, тәгъбир, тезмә.

Татар телендә чагыштыруларның ачык күренеп торган тышкы билгеләре була. Алар *-дай/-дәй, -рак/-рәк, -чай/-чәй* аффикслары; *кебек, шикелле, төсле, сыман* бәйлекләре һ. б. Кешеләр белән кешеләр, кешеләр белән хайваннар, кошлар арасындагы чагыштырулар матур әдәбият һәм публицистика әсәрләрендә киң таралган. Татар телендә чагыштырулар башка сурәтләү алымнарына караганда күбрәк кулланыла. Сөйләмне мәгънә һәм эчтәлек ягыннан баетуда, аны матурлауда алар зур эш башкаралар [Әдәбият белеме: 191].

А. Гыйләҗев әсәрләре мисалында, чагыштыруларның әдәби текстларда никадәр актив булуы ачык күренә. Аларны түбәндәгечә төркемләп була:

1. *Кебек* бәйлеге ярдәмендә:

Ф.М. Хисамова кебек бәйлеге нинди дә булса билге буенча чагыштыруларны һәм аерым очракларда якынчалатып әйтү яки икеләнү төсмерен дә белдерергә мөмкинлеген ассызыклап үтә [Хисамова: 300]. Мәсәлән: *«Шулай итеп, кибеттә булганнан соң иске киемең дә яңа кебек була башлый...»* (ҖККБ, 99) / *«Таким образом, в магазине старая одежда как бы обновляется»* (ВПВ, 310). Әлеге очракта автор кулланган *яңа кебек* дигән чагыштыруны, тәрҗемәче *как бы обновляется* дип бирә. Мисалның мәгънәви ягы уңай, ә грамматик ягы кебек бәйлеге белән күрсәтелә. Ә «*Колак төбемдә, тургай җыры кебек булып, сихри өн чыңлый иде»* (ЯК, 388) мисалын тәрҗемәче болай күрсәтә: *«Этой же грустью были овеяны и давно уже покосившиеся, готовые развалиться плетни*

*и домишки Имэново, а в ушах песней жаворонка звенит чарующий голос»* (ВК, 452). Рус теленә тәрҗемәдә чагыштыру юкка чыга, җөмлә чагыштыру төсмерен югалта.

2. *Хәтле* бәйлеге ярдәмендә:

Әлеге бәйлек кебек бәйлеге белән чагыштырганда әдәби телдә пассиврак, әмма автор аны бик яратып кулланалар: *«Казанда быкыр-быкыр ит кайный, мич төбендә бакра иләге хәтле бәлеш кабарып утыра»* (ҖККБ, 157) / «*В казане, значит, буль- буль – мясо варится, в печи – огромный, как медный таз, балиш доходит»* (ВПВ, 365). Мәгънәсе предметның зурлыгына, күләменә ишарә итә. Тәрҗемәче әлеге чагыштыруны сүзгә-сүз тәрҗемә итү ысулы белән бирә.

3. *Төсле* бәйлеге ярдәмендә:

*Төсле* бәйлеге әдәби телдә шулай ук артык еш кулланылмый. «Татар граматикасы»нда әлеге бәйлекнең охшату төсмерен бирүдә катнашуына игътибар бирелә [Татар грамматикасы: 356].

*«Председатель яңа сырма өстеннән иске, кыршылган кожан кигән кожан җиңнәре пычранган, бригадирлар да таш чапкан төсле мыжлар төшкәннәр иде»* (ЯК, 394) / *«И бригадиры с трудом переводят дыхание, словно все они только что кончили долбить камень»* (ВК, 457). Мисалдан күренгәнчә, тәрҗемәче чагыштыруны үзгәтеп тәрҗемә итүне кулай күрә.

4. *Сыман* бәйлеге ярдәмендә:

*Сыман* бәйлеге функциясе белән бигрәк тә чагыштыруларны биргән вакытта бик актив кулланыла.

*«Кылчык сыман гына шыр бер хатын иде бугай»* (ҖККБ, 156) / *«Но, кажется, костлявая была, долговязая, в очках...»* (ВПВ, 364). Тәрҗемәче чагыштыруны үзгәртеп тәрҗемә итә, анда чагыштыру төсмере югала. Мәгънәсе гәүдәнең ябык, нечкә булуын аңлата.

*«Мирвәли канаты талган карт бөркет сыман озак кына баягы кискә өстендә утырды»* (ӨАҖ, 28) / *«Мирвали снова сидел на том же березовом чурбаке»* (ТАЗ, 119). Бу очракта чагыштыруны тәрҗемәче бөтенләй төшереп калдыра. Автор әйтергә теләгән фикер, төп мәгънәдә бөтенләй чагылыш тапмый.

5. *Кук* бәйлеге ярдәмендә:

Ул кулланылышы ягыннан пассив. Әлеге бәйлеккә күбесенчә кебек, сыман, шикелле бәйлекләренә синоним буларак кына мөрәҗәгать ителә дип тә әйтергә мөмкин.

*«Кешегә борылса, йөзе кояш кук балкып торыр иде бичараның»* (ҖККБ, 89) / *«Он повернется, бывало к человеку, а у самого лицо будто солнце засветится!»* (ВПВ, 299) мисалы сүзгә-сүз тәрҗемә ителгән.

Мисаллардан күренгәнчә, Аяз Гыйләҗев тарафыннан бәйлекләр ярдәмендә оештырылган чагыштырулар тәрҗемәдә үзгәрешсез дә, бөтенләй төшереп калдырылып та, башка грамматик формалар рәвешендә дә тәкъдим ителәләр.

*«Хәзер мин җир җимертеп яшим дип үзен үзе ышандырулары бары сабын куыгы кебек шартларга гына торган икән!»* (ӨАҖ, 32) / *«И вот оказалось, что вся его уверенность не больше, как мыльный пузырь!»* (ТАЗ, 122). Тәрҗемәче Ибрагим Гиззатуллин *сабын куыгы кебек* чагыштыруын сүзгә-сүз *как мыльный пузырь* дип бирә.

*«Азаплана торгач ул ике тапкыр чак кына мәтәлеп төшмәде, күлмәгенең икенче җиңе дә умырылып чыкты, комач яулыгы агачка эленеп, канлы әләм кебек селкенеп тора башлады»* (ҖККБ, 225) / *«В этой спешке она едва не слетела с дерева, порвала и второй рукав, кумачовый платок ее, зацепившись за сук, повис, как красный флаг»* (ВПВ, 427) мисалында исә *канлы әләм красный флаг* ка үзгәрә. Кан сүзе кызылга әйләнә. Грамматик яктан чагыштыру кебек бәйлеге белән күрсәтелә.

Гади бер сүз белән тәрҗемә итү – әлеге тәрҗемә икенче төрле конпенсация ысулы дип атала. Бу очракта тәрҗемә телендә кулланылган чара, гади сүз яки сүзтезмә белән тәрҗемә ителә. Гади бер сүз белән тәрҗемә итү вакытында оригиналда булган бердәмлекләр тәрҗемә текстында башка чара белән бирелә һәм урыны да бик үк мөһим булмый. Чагыштырулы мисалларда мондый тәрҗемә төре дә файдаланыла.

*«Балачак охшашлыгы юылган, төрле тормыш юлы үткәнгә, алар хәзер ят кешеләр сыман – ятлар төсле карашып торалар, ятлар төсле әрепләшәләр...»* (ҖККБ, 112) / *«А так вроде и чужие совсем, смотрят как чужие, друг на друга, как чужие, ссорятся...»* (ВПВ, 322). Бу очракта *ят кешеләр сыман* чагыштыруы *чужие* сыйфаты белән генә бирелә.

Алмаштырып тәрҗемә итү – тәрҗемә эшендә иң актив кулланылганы. Бу очракта фразеологизм яки башка сүзтезмәләрне мәгънәсе ягыннан туры килгән башка фразеологизм, сүзтезмәләр белән алмаштырыла. Шулай ук чагыштыруның предметын үзгәреп тәрҗемә итү дә еш күзәтелә. Бу очракта төп текстта чагыштыру юк, ә тәрҗемәдә барлыкка килә. Мәсәлән: *«Әсмабикәнең җәя төсле нәзек кашлары маңгаена сикерде»* (ҖККБ, 102) / *«Узкие, как стрелы, брови Асмабикэ взметнулись на лоб»* (ВПВ, 312). Әлеге мисалда тәрҗемәче А. Сафонов *җәя төсле* чагыштыруын *как стрелы* дип бирә, *җәя* сүзе *ук* белән алыштырыла. Җәя төсле чагыштыруында модуляция барлыкка килә. Җәя – корал (төп корал), ә стрела – бөтенләй икенче коралга кертеп карала (коралның бер өлеше генә). Грамматик формасына килгәндә исә, җәя – берлек санда, ә рус теленә тәрҗемәсендә инде бөтенләй күплек санга әйләнгән.

*«Мәүлиханың күзе шакмак булды»* (МҺНТ, 271) / *«Маленькие глазки Маулихи так и округлились»* (ЛИН, 172). Юрий Галкин тәрҗемәсендә күз шакмак булу фразеологизмы юкка чыга, ә түгәрәкләнүе генә бәян ителә.

Тәрҗемә вакытында Э.И. Сафонов тәрҗемәсендә сүзгә-сүз, төшереп калдыру, И.Г. Гиззатуллин исә күп очракта сүзгә-сүз тәрҗемә итү, ә Ю.Ф. Галкин белән Т.Л. Успенская-Ошанина сүзгә-сүз һәм күбесенчә төшереп калдыру ысулларына мөрәҗәгать итүне өстенрәк күрәләр. Чагыштыру ярдәмендә әсәр үзенә бер матурлыкка күмелә, укырга да кызыклы булган, сокландыргыч әсәргә әверелә. Әсәрләрдә чагыштырулар *кебек, шикелле, төсле, сыман* бәйлекләре ярдәмендә ясалсалар, рус теленә тәрҗемә иткән вакытта *төсле – как*, *словно*, *сыман* бәйлеге – *точно*, *кук* бәйлеге – *будто* дип, тәрҗемә ителүләре ачыкланды.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, тәрҗемәчеләр чагыштыруларны тәрҗемәдә бергәндә төр ле төр трансформацияләргә мөрәҗәгать итәләр, шулай да күп очракларда төшереп калдыру ысулын кулайрак күрәләр. Бу вакытта автор күрсәтергә теләгән төсмер югала. Җөмләләр автор язганча матур килеп чыкмый, гадиләшеп кала.

**Әдәбият**

1. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков / сост.: М.З. Закиев, Ф.С. Сафиуллина, С.М. Ибрагимов, К.З. Зиннатуллина. – Казань: Татарское книжное издательство, 2007. – 230 с.

2. Татар грамматикасы. – М.: Инсан; Казань: Фикер, 2002. – Т. II. – 448 с.

3. *Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335б.

**А.С. Жақсылықова, М.Д. Бекбергенова**
Нукусский государственный педагогический институт,

## ОРАЗБАЙ ӘБДИРАХМАНОВТЫҢ ШЫҒАРМАЛАРЫНДА САТИРАЛЫҚ ОБРАЗЛАР

## САТИРИЧЕСКИЕ ОБРАЗЫ В ТВОРЧЕСТВЕ ОРАЗБАЯ АБДИРАХМАНОВА

**Аннотация.** В статье интерпретируются сатирические произведения Оразбая Абдирахманова, рассказывается о сатирических образах в произведениях автора «Актер», «Көк Ғарбыз», «Гәпке қайым адам» и особенностях жанра сатиры.

**Ключевые слова:** сатира, образ, персонаж, произведение, литературная мысль.

**Abstract.** The article interprets the satirical works of Orazbay Abdirakhmanov. It tells about the satirical images in the works of the author "Aktyor", "Kók ǵarbız", "Gápke qayim adam" and the peculiarities of the satire genre.
**Keywords:** satire, image, character, work, literary thought.

Сатира еркин жәмийетимиздеги унамсыз қәсийетлерге қарсы гүресиўде, оларды ашшы күлки арқалы әшкаралаўда, турмыстағы ҳәр қыйлы ҳәдийселерди сынаўдан, өткир електен өткеретуғын көркем сөз қуралы. Сатира өзинде жәмлеген бундай қәсийети менен жазыўшының журек төрине терең кирип барып, оның айтажақ ойын образлы баянлаўға жақыннан жәрдем береди. Сатирик жазыўшыдан ең дәслеп халықлық көз-қарас, жоқары эстетикалық идея, өмир шынлығын шығармада көркемлик пенен сүўретлеў шеберлиги талап етиледи.

Қарақалпақ әдебиятында сатираның сағасы қарақалпақ фольклоры менен ертедеги қарақалпақ жазба әдебиятынан басланады.

Сатираның шын мәнисиндеги үлгилери қарақалпақ әдебиятында XX әсирдиң 20-жылларында пайда болды. Бул дәўирде А. Муўсаевтың, С. Мәжитовтың, Х. Ахметовтың, А. Матьякубовтың, Ж. Аймурзаевтың гейпара сатиралық қосықлары жүзеге келди.

20 жыллардың орталарына келип миллий баспасөзимиздиң пайда болыўы ҳәм раўажланыўы менен бирге көркем-публицистиканың сатиралық бир формасы сыпатында Т. Сейтмамутовтың, Ж. Аймурзаевтың, М. Дәрибаевтың, Д. Назбергеновтың фельетонлары, Ә. Өтеповтың «Тоғыз жүз грамм», «Бояўшы ўәкил» т. б. комедиялары дөреди.

Қарақалпақ сатирасының ҳақыйқый көриниси екинши жәҳән урысы дәўирине туўра келеди. Усы дәўирден баслап сатира көркем әдебияттың стиллик формасы сыпатында турақлы ҳәм избе-из раўажланды. Сатиралық қосықлар, гүрриңлер, фельетонлар, поэмалар, комедиялар көплеп дөреди, қарақалпапқ повестьлери менен романларында унмасыз қаҳарманлар образы сатиралық позициядан жасалды [1].

XX әсирдиң 80 жылларына келип өз наўбетинде сатиралық прозада раўажлана баслады. Соңғы дәўирлерде сатиралық гурриңлер дөретиўши сыпатында танылып келген көркем сөз шеберлериниң бири Оразбай Әбдирахманов саналады. Оның «Көк ғарбыз», «Гапке қайым адам», «Өжет», «Лық-лық», «Актер», «Ботинка» ҳәм т. б. Гүрриңлеринде сатиралық образлар өнимли қолланылған. Жазыўшы сатиралық образлар арқалы айрым мәденятсыз инсалардын келбетин өткир сынға алып ашкаралаўға ҳәрекет етеди.

Сатиралық образ шығармада сүўретленген турмыслық қубылысларды, жеке адамлардың ҳәрекети менен минез-қулқындағы унамсыз көринислерди шегине жеткерип әшкаралаў арқалы жасалған образ.

Жазыўшы образлар арқалы турмыстың мәлим тәрепин сүўретлер екен, өмир ҳәдийселери үстинен ҳүким шығарады. Ол адамлар образларының өз-ара байланысы, жумысы ҳәм гүресин сүўретлеў арқалы түрли шараятлардағы адамлардың жәмийетлик минез-қулқы ҳәм тәбият ҳәдийселерине қарым қатнасын ашып береди. Бул арқалы жазыўшы китап оқыўшыларда да усындай кейпият туўдырады. Мәселен, О. Абдирахмановтың «Гәпке қайым адам» деген гүрриңдинде баслық образы сатиралық образ сыпатында қаралады. Мәкемеде Таўмурат Жаймуратович деген адам бар. Өзи ислеп атырған хызмет бойынша айрықша бир жуўапкершиликке де ийе емес, бар болғаны техника қәўипсизлиги қәнигеси. Лекин, мекемеде план орынланбаса да, баслық жоқарыдан сөгис еситсе де ямаса баслықтың кеўил кейпи болмаса да усы Таўмуратқа кийлигеди. Бүгинги жыйналыста да Таўмураттың еситетуғыны ақырет, бир ҳәптеден кейинги жыйналыста да, бир айдан кейинги жыйналыста да...

Ақыры, бир күни Таўмурат буған шыдай алмай, жумыстан кетпекши болып, баслықтың алдына кирди:

– Дурыс, сен бар болғаны қәўипсизлик хызметкерисең, – дейди оған баслық. – Бырақ, мен саған сонша жәмийетлик жумысларды бийкарға тапсырып қойғаным жоқ ғой. Саған жол силтеп, сени сөгип турмасам, мениң ағалық ўазыйпам қайда қалды? [2: 5].

Буны еситип баслықтың көрсетип атырған ағайиншилигине кеўли толды ҳәм арзасын қайтып алады.

Автор бул жерде мекеме баслығының ағайынпазлығы, мәжилстеги бақырыс-кейистиң бәри көзабаға исленип атырғанын ашшы күлкиге алады. Шығарма қаҳарманының түсинигинше: баслық ағайинине сонша бақырып атыр, бизлерге индемегей-дә, деп отырыўы мүмкин. Автордың тапқырлығы сонда, ол мекеме басшысын ашықтан-ашық ағайинпаз деп ямаса Таўмуратта ҳәмме нәрсеге көнип қалған деп ашықтан-ашық айтпайды. Оны оқыўшының өзи түсинип алады. Гүрриңниң жуўмағының өзи жазыўшының гөзлеген мақсетин, идеясын айтып тур.

Жәнеде жазыўшының бундай тематикаға жақын «Ботинка» гүрриңиде айрым жоқары орынлы адамлардың ис ҳәрекетлерин өткир сынға алып суўретлийди. Шығармада сатиралық сыпатлар Әмет Әлиевич ҳәм Қабыл Салиевич образлары арқалы көринеди. Қабыл Салиевич баслығына жағыныў ушын оның қас-қабағына, кеўлине қарап ис жүритеди. Ол бир күни үйине мийман шақырып, баслығы Әмет Әлиевичти айрықша сый ҳүрмет пенен күтди. Оған кеўли толған баслық бул үлкен итибардан марапатланып кеўилли түрде үйине қайтады. Бырақ қонақ болған орнында ботинкасының қалып қойыўы шығарманың тийкарғы идеясын ашып береди. Қабыл Салиевич бул ботинка себепли көп қысыныспаға түседи. Баслығына жақсы көриниў ушын ботинканы үйине апараман

деп, баслықтың сырын өмирлик жолдасына билдирип қойыўы ақыбетинде түскинликке түсип қалады. Жағымпазлықтың ақыбети оған аўыр жүк болады. Мысалы жазыўшы бул ҳаллатты жүдә тәсирли етип, образлы баянлайды:

«Қабыл Салиевичтиң ҳүррийи ушқанлықтан уйине сүйретиле қайтты. Енди барлығы тамам жумыстан қуладым – деп ойлайды. Ол жеңгейдиң минези әзелден мәлим, Әмет Әлиевичтиң еки аягын бир етикке тығып жибереди» [2: 11].

Базарда жүрген ўагында оны биришилерден болып оны классклас досты Зийўар ушыратып қалады. Мине, соннан конфликт келип шығады. Дәслеп автор Зийўардың унамлы тәреплерин көрсете баслайды. ўақыялар шийенлескен сайын Зийўардың ҳәм оның күйеўиниң унамсыз қылықлары мәлим бола баслайды. Жөнсиз арақ ишиўлер арқалы турмысы келиспей атырған жас шаңарақ ийелериниң мысалында жәмийетимиздеги үлкен машқаланың бет пердесин ашқан. Егер усындай етип, арақ ишип, келешегин ойламай жасай берсе, тек елимиз емес, ал жәмийетимиз үлкен зыянға қалады. Автор усындай нуқсанды Зийўар ҳәм Әлжан образлары арқалы көрсетип береди.

Оразбай Әбдирахмановтың «Актер» сатиралық гүррищинде сатиралық образ тартымлы жасалған. Онда отыз жылдан бери сахнада өмир сүрип жүрген Түршекең образы сөз етиледи. Бул шығармада автор театр мәселесин өткир сынға алады. Сахналық жумысларда айырым инсанлардың тек жумыс ислеп жүргени, дөретиўшилик қатнас жасамайтуғыны сөз етиледи:

– Ҳүрметли жолдаслар, – деди комиссия баслығы, – ҳүрметли Түршеке мине отыз жылдан бери сахнаның төринде шамдай жарқырап киятыр. Дурыс, оның аты афишаларда бүртийип көринбесе де, яғный сонша жылдан бери бас рольде ойнап көрмесе де ашығын айтыў керек, Түршекеңсиз бирде-бир спектакль қойылмады [2].

Усы қатарларды оқыған китап оқыўшы ерксиз ойланыўы мүмкин. Сахнаның төринде шамдай жарқырап жанып турса, ал неге оның аты афишаларда жоқ? Яки болмаса, ол бас рольде ойнамаса да ҳеш бир спектакль оның қатнасыўысыз өтпеген. Бул жағы да жумбақ. Жазыўшы қаҳарманының унамсыз келбетин бөрттирип мақтап турыпты. Бирақ, өз гезегинде сахнаның төринде шамдай жаныўын айтып, образлы түрде сынға алып тур. Неге шамға теңейди? Себеби, шам тек әтирапына ғана жарықлық береди. Сондай-ақ, сахнаның төри деген сөзде де үлкен мәни жатыр. Төр әдетте, жасы үлкен, абыройлы адамлар отыратуғын инслардың орны. Бирақ, бул жерде сахнада төр емес, ал сахнаның алдыңғы тәрепи айрықша күшке ийе. Өйткени, төрде не болып атырғанын алдыңғы тәрепи жасырып турады. Усыларды есапқа алып, сөз қурайдағы жазыўшының шеберлигин жемисли шыққан деп қараў керек.

Гүрриңде Түршеке сатиралық образ. Бир қарағанда ол унамлы тәрепи сөз етилип атырғандай болады. Шығармада сатира нышанының өткирлиги сүўретлеў объектинен туўылажақ күлкиниң дәрежесине байланыслы.

О. Абдирахмановтың сатиралық шығарималарының жәмийетлик әҳмийети ҳәм ўақыялықтың өзине тәнлиги менен характерленеди.

Жуўмақлап айтқанда, усындай сатиралық образлар дөретиў усылы ҳәзирги қарақалпақ әдебиятында жас жазыўшылардың дөретпелеринде дәстүр сыпатында даўам еттирилип атыр. Соның менен бир қатар жазыўшы О. Әбдирахмановтың шығармаларында сатиралық образлардың орынлы пайдалана билиўи, ең алды менен автордың шебер сатирик екенлигин көрсетеди. Соның менен бир қатарда сатиралық проза дөретиўшилериниң шыгармаларың терең изертлеў бүгинги күнниң актуал мәселелери болып есапланады.


**Әдебият**

1. *Пахратдинов Ю.* Қарақалпақ сатирасы. – Нөкис: Қарақалпақстан, 1992.
2. *Әбдирахманов О.* Бир мухаббат тарийхы. – Нөкис: Қарақалпақстан, 1978.
3. *Нуржанов П.* Ғәрезсизлик дәўирдеги қарақалпақ прозасы. – Нөкис: Билим, 2003.
4. *Нуржанов П.* Дәўир талабы ҳәм көркем әдебият. – Нөкис: Билим, 1993.



**А.И. Забирова**

Московский педагогический государственный университет, Москва


## ОБРАЗ КАЗАНИ В ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ XX–XXI ВВ.


**Аннотация.** Статья посвящена изображению Казани в татарской литературе XX–XXI вв. На основе творчества значимых в татарской литературе и культуре личностей Г. Тукая, М. Джалиля и Р. Хариса проведен анализ символики города в XX в. Так, для татарской литературы характерны традиционные значения Родины, родного края, города детства и др., а также обращение к страницам истории города в контексте истории татарского народа. Результаты исследования представляются важными в дальнейших работах сопоставительного характераи воспитании будущих поколений граждан нашей многонациональной и многоконфессиональной страны.



**Ключевые слова:** татарская литература, образ города, образ Казани, современная татарская литература.



**Abstract.** The article is devoted to the image of Kazan in the Tatar literature of the XX-XXI centuries. On the basis of the works of significant in literature and

culture personalities G. Tukay, M. Jalil and R. Kharis, the analysis of the symbolism of the city of the XX century and modern literature is carried out. Thus, Tatar literature is characterized by traditional meanings of the Motherland, native land, city of childhood, etc., as well as an appeal to the pages of the history of the city in the context of the history of the Tatar people. The results of the study seem to be important in further works of a comparative nature and the education of future generations of citizens of our multinational and multi-confessional country.

**Keywords:** Tatar literature, the image of the city, the image of Kazan, modern Tatar literature.

Город Казань является знаковым в истории татарского народа. К мотиву города обращались в произведениях художественной литературы татарские писатели XX в. (Г. Исхаки, Г. Камал, Ш. Камал. Г. Тукай [3], М. Джалиль [10, С. 190], Ф. Амирхан, Г. Ибрагимов, Х. Туфан и др.) и XXI в. (Р. Кутуй, Р. Хамид, Р. Батулла, Ф. Латыфи, М. Хабибуллина, Р. Харис, Р. Зайдулла, Г. Яхина и др.), где татарская столица занимает центральное место в духовно-культурной картине мира татарского народа. Образ Казани также находит отражение и в творчестве таких русских писателей, как А.И. Герцен и Г.Р. Державин, А.Н. Радищев и А.С. Пушкин, С.Т. Аксаков и Е.А. Баратынский, М. Горький и Л.Н. Толстой и др. Данный образ изучается и в научных трудах исследователей: В. Аристовой, А. Каримуллиной, В. Климентовского [1, С. 190], Э. Шафранской [16, С. 95–103], Г. Зайнуллина [6, С. 208–219] и др.).

Общественно-политические преобразования начала XX в. ознаменовались в татарской литературе творчеством Г. Тукая, который, несмотря на то, что «в начале XX в. татарская культура была самой передовой среди культур тюркоязычных народов» [1, С. 222], во многом внес существенный вклад в литературу, расширил идейно-тематические границы национальной прозы, охватывая все социально значимые события татарского народа.

Так, в литературном наследии основоположника татарской литературы, являющемся **достоянием** татарского народа, образ Казани рассматривается как центр татарской культуры, город науки и просвещения. Неслучайно в этот период в татарской литературе Казань определяется местом, объединяющим всех татар, в это время появляется миф о Казани («Светозарный город»). «О Казань, ты грусть и бодрость! Светозарная Казань!» [14, С. 49] – обращается Тукай к духовному центру татар в своем стихотворении «Пара лошадей» (перевод А.А. Ахматовой), словами «Здесь науки, здесь искусства, просвещения очаг» [14, С. 43] возвеличивает автор его, и искренне радуется, говоря: «...здесь деяния дедов наших, здесь священные места, здесь счастливца ожидают милой гурии уста» [14, С. 43]. Казань со своими лесами, цветочным полями, реками,

церквями и мечетями  приобретает символику сказочного города, идеальной столицы, волшебного города детства. Автор часто обращается к образу Казани, поднимая острые вопросы социально-политической жизни общества (проблем классового неравенства, «черноты» деревень («Казань и Заказанье»), отставшей жизни («Новый Кисекбаш»), высмеивает самодержавие и господство капитализма, пагубные последствия прогресса («Казань») и др.).

В произведениях Г. Тукая этого периода Казань – это образ, символизирующий *родную землю, город детства* писателя, возвращению в который спустя много лет автор безмерно счастлив: *«Хоть юнцом с тобой расстался, преданный иной судьбе, / Заказанье, видишь, снова возвратился я к тебе»* / *«Эти земли луговые, чувства издали маня, / Память мучая, вернули на родной простор меня»* [3, С. 43]. В стихотворении «Родной земле» (1907, перевод А.А. Ахматовой) обнаруживается *мотив возвращения, тоски по Родине*, природе, хоть и она сделала его *«несчастным сиротою»* . Прослеживается мысль о ценности, священности родного края: *«Я постиг, что все священно: и овин твой, и ручей, / И гумно твое, и степи, и дороги средь полей, / И весна твоя, и осень, лето знойное, зима, / Белые чулки, да лапти, да онучи, да сума. / И овчарки, и бараны – вся родная сторона. / Любо мне и то, что плохо, даже то, чем ты бедна»* [3, С. 43].

Говоря о татарской литературе периода Великой Отечественный войны, нельзя не сказать о знаковой (Это определение слишком часто употребляется в тексте. Надо использовать синонимы!) личности не только татарской литературы, но и многонациональной страны в целом – поэте-герое Мусе Джалиле, жизнь и творческий путь которого вызывают искреннее признание. А.А. Ахматова отмечала, что переводила стихи поэта с понятным всякому чувством тревоги и волнения, и нельзя касаться его произведений, не думая о трагической судьбе этого героического человека и поэта.

Образ Казани занимает одно из центральных мест в творчестве поэта, с этим городом связана вся его жизнь, понятия Родины, семьи, дочери. Его жизненный и творческий путь неразрывно связан с образом родного города: если в раннем творчестве поэта Казань – это образ *родины, «свободной навсегда»*, *родины Г. Тукая* (*«Да... Яркие багряные цветы, / Исполненные свежести и света, / Расскажут о сиянье красоты / На возрожденной родине поэта!»* [2], стихотворение «У могилы Тукая»), город светлого *будущего* (*«Льды идут... / На Волге, на раздолье, / Там за льдами и блещет красота. / Вот идут мои друзья, подруги – / Армия труда, родной народ»* [11]), то в военный период Казань для автора – это дом, *Родина, место, где остались родные* (с образом жены поэта, Амины, связано стихотворение «Прощай, моя умница» (1941): *«Я видел тебя, покидая Казань, / Кремлевские белые стены, / Казалось – с балкона ты машешь*

*платком, / И облик твой гас постепенно»* [7]). Образ Кремля здесь не только и не столько знаковый объект города, но также приобретает символику исторического и культурного объекта татарского народа. Центральный мотив военного периода – *мотив возвращения*, возвращения с победой на родину в Казань (ведь там осталась его семья, близкие ему и родные). И *образ Казани-родины,* возвеличивания родины, ее ценности мы наблюдаем через такие средства выразительности, как обращение, олицетворение: *«О, Родина! Ты слезы проливала, / Ждала от сына помощи себе. / Клянусь, что не сойду с пути, родная – / Путем, указанным тобой, вернусь к тебе»* [7].

Образ Казани приобретает значение *природы* Татарстана, по которой писатель скучает (*«Так сильно соскучился я по Замостью, / По нашим лесам и полям»)* и *место*, где остались его родные и любимые, по которым он тоскует (*«Сказать не могу, до чего стосковался / По черным девичьим бровям»* [9]).

В стихотворениях М. Джалиля не только описывается война от лица фронтовиков в значениях тоски по родине, дому, веры в победу), но и показывается жизнь оставшихся в тылу, все тяготы жизни: *«И слышу я, как ночи напролет / Веретено без умолку поет. / На варежки сынам-богатырям / Без сна овечью пряжу мать прядет»* [14]. Образ города воплощен в изображении *труда, огромных заводов* (*«С завода сутками не выходя, / Седой рабочий трудится для нас, цехов, станков»* [14]): *«Я вижу наших девушек-сестер – / Вдали, в цехах огромных, у станков. / Они гранаты делают для нас, / Чтоб нам скорее сокрушить врагов»* [14]. К примеру, в стихотворении «Казанское полотенце» символом родины поэта выступает полотенце, полученное в дар от любимой девушки: *«Ах, как прекрасно это полотенце! – / Любовью вышило его девичье сердце... / Простой подарок тот – девичье полотенце, / Как Родины привет, ласкает сердце»* [1].

Современные татарские авторы также часто обращаются к образу Казани. Этот город представляется неотъемлемой частью истории страны и народа в общем, а также жизни и биографии в частности, особого национально-культурного пространства веротерпимости. Так, Казань занимает особое место в творчестве татарского поэта Р. Хариса. В стихотворениях «Огни Казани» («Казан утлары»), «Лучезарная Казань» («Нурлы Казан») огни этого родного для автора города освещают путь к счастью и любви, а город становится залогом духовного здоровья и сил лирического героя. В его поэзии Казань – особое историко-культурное пространство, особый мир, наиважнейший для татарской культуры [1]. Создавая образ Казани в своих произведениях, Р. Харис изображает многовековую историю столицы Татарстана: *«...в Казани звучат шаги истории / и сердце отзвук отдает / если хочешь шаги объединить / за страну волнуйся и борись».* Неслучайно в произведениях поэтов и прозаиков татарской

эмиграции знаковое место занимают связанные с этим городом объекты (река Идель, Агидель, озеро Кабан, Казанский Кремль) и исторические образы (Атилла, Чингизхан, Лукман Хаким, Улуг Мухаммед, Сююмбике, Тукая, Такташ, Шах-Гали, Джан-Али, Сафа-Гирей и др.).

Таким образом, рассмотрение образа Казани в татарской литературе XX в. (на примере Г. Тукая и М. Джалиля) и современности (Р. Хариса) дает основание сделать предварительные выводы о том, что Казань – основополагающий образ в литературе татарского народа, символ культуры и истории. Так, наиболее частые значения- значения родной земли, города детства, науки и просвещения, родной природы. Кроме того, образ Казани раскрывает не только историю города и традиционную культуру татарского народа, но и затрагивает вопросы синтеза многовековых традиций.

## Литература


1. *Аристов В., Каримуллин А., Климентовский В.* Казань в художественной литературе. – Казань: Татарское книжное издательство, 1977 – 190 с.

2. Воспоминания о Мусе Джалиле / сост.: Г. Кашшаф, Р. Мустафин. – Казань: Татарское книжное издательство, 1966. – 153 с.

3. Габдулла Тукай. – URL: http://gabdullatukay.ru/rus/in-art/in-literature/stihi-o-tukae/musa-dzhalil-u-mogily-tukaya/ (дата обращения: 15.10.2020).

4. *Галиуллин Т.Н., Сабиров Р.Р.* Народный поэт Габдулла Тукай // К(П)ФУ – 2013. – URL: http://gorodskoyportal.ru/kazan/news/cult/4198074/ (дата обращения: 15.10.2020).

4. *Давлетшин Г.М.* Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа (истоки, становление и развитие). – Казань: Татарское книжное издательство, 2004. – 431 с.

5. *Зайнуллина Г.И.* Программирующая мощь казанского текста (символические реалии Казани в прозе В. Попова, А. Сахибзадинова, А. Хаирова, Д. Осокина и Р. Беккина) // Нева. – 2019. – № 3. – С. 208–219.

6. Муса Джалиль «Прощай, моя умница» (1941). – URL: http://www.world-art.ru/lyric/lyric.php?id=9216 (дата обращения: 15.10.2020).

7. Муса Джалиль «Дороги». – URL: https://poemata.ru/poets/dzhalil-musa/dorogi/ (дата обращения: 15.10.2020).

8. Муса Джалиль. Стихи (список). – URL: https://stihipoeta.ru/musa-dzhalil/ (дата обращения: 15.10.2020).

9. Муса Джалиль. Стихотворения. – URL: https://www.docme.ru/doc/98510/musa-dzhalil._.-stihotvoreniya (дата обращения: 15.10.2020).

10. Муса Джалиль «Письмо из окопа». – URL: https://prostih.ru/dzhalil/pismo-iz-okopa (дата обращения: 15.10.2020).

11. Полуденный закат: современная проза татарских писателей / пер. с татар. Г. Хасановой. – Казань: Татарское книжное издательство. – 2006. – 211 с.

12. Татарское народное творчество: в 15 т. – Казань: Магариф, 2009. – Т. 3: Бытовые сказки. – С. 123, 130, 465, 475.

13. *Тукай Г.* Фаэтон весны: стихотворения, стихи для детей, сказки. – М.: Из века в век; Икар. – 49 с.

14. Тукай... Дөньяхалыклары Тукай турында / төз. Р. Акъегет. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2006. – 222 с.

15. *Шафранская Э.Ф.* Мифология Казани в прозе Аделя Хаирова // Вестник Северного (Арктического) федерального университета. Серия: Гуманитарные и социальные науки. – 2014. – № 1. – С. 95–103.

**Т.И. Зайцева, О.М. Максимова**
Удмуртский государственный университет, Ижевск

## ОБРАЗ УДМУРТСКОГО ПИСАТЕЛЯ Г.Д. КРАСИЛЬНИКОВА В ЖАНРЕ ЛИТЕРАТУРНОГО ПОРТРЕТА

**Аннотация.** Удмуртская литература рубежа XX–XXI вв. характеризуется интенсивностью возникновения новых и активным развитием традиционных жанровых форм. Не являетсяисключением и национальная художественно-публицистическая проза. В статье описан процесс трансформации портретного очерка в жанр литературного портрета. На материале литературных портретов, посвященных Г.Д. Красильникову, рассмотрена специфика создания образа писателя-классика.

**Ключевые слова:** удмуртская литература, художественная публицистика, жанр, литературный портрет.

**Abstract.** Udmurt literature at the turn of the XX–XXI centuries. characterized by the intensity of the emergence of new and active development of traditional genre forms. National artistic and publicism prose is no exception. The article describes the process of transformation of a portrait essay into the genre of a literary portrait. Based on literary portraits dedicated to G.D. Krasilnikov, the specificity of creating the image of a classic writer is considered.

**Keywords:**Udmurt literature, artistic publicism, genre, literary portrait.

В удмуртской прозе рубежа XX–XXI вв. наибольшей модификации подвергся жанр очерка, поскольку именно этот жанр на всех этапах истории национальной литературы определял динамику ее развития. Содержательные и

структурные изменения затронули, прежде всего, такой вид очерка, как портретный, занимавший в литературе прошлых лет, наряду с проблемным очерком, главное место. В традиционном удмуртском портретном очерке большую роль в выражении его идейного смысла играл проблемный анализ, то есть преимущественное внимание уделялось профессиональной сфере деятельности человека, занятого,как правило, в сфере сельскохозяйственного производства.

Формирование новой жанровой разновидности, которую вполне можно определить как «литературный портрет», связано со слиянием элементов проблемного и портретного видов очерков, взаимопроникновением компонентов биографии, воспоминаний, мемуаров, записок и даже документальной повести. В центре внимания литературного портрета – смысл жизни и творчества интеллигента, его духовный и интеллектуальный мир.

Следует отметить, что четкого определения понятия «литературный портрет» в гуманитарной науке не существует; в критике и литературоведении наряду с термином «литературный портрет» применяются разные дефиниции – «писательские воспоминания», «творческая биография», «документальный очерк», «очерк», «статья», «эссе», «рецензия» (когда речь идет о литературном портрете как жанре критики) и т. д. [Ведищева, 2011]. Примечательно, что в удмуртской читательской среде по отношению к произведениям, воссоздающим образы людей творческих профессий, в настоящее время стал активно применяться термин «литературный портрет». В общих словах поэтику «литературного портрета» можно охарактеризовать, как способность жанра ставить в центр повествования сюжет самоопределения героя наряду с авторскими размышлениями и впечатлениями.

С большим интересом была встречена портретная публицистика, представленная в книгах П.К. Чернова «Атаймузъем» («Земля отцов», 1983), Г.А. Ходырева «Зечвизь-кенешкотькудуно» («Добрый совет всегда дорог», 1989) и «Кызьы меда лыктиды...» («Как вы добрались...», 1998), С.А. Самсонова «Гожтиськотыныд – сопалдуннее» («Пишу тебе – в мир иной», 1993), М.В. Гавриловой-Решитько «Чыдонтэмпумиськонъес» («Незабываемые встречи», 1995) и «Эшъяськонлэншунытэз» («Тепло дружбы», 2005), Е.Е. Загребина «Яратонэ тон, вожанэ...» («Любовь моя, ревность моя...», 2004) и др. Такого плана работы воспринимаются как ценная информация ореальном человеке, хорошо известном в республике и за ее пределами.

Пожалуй, наибольший интерес удмуртская публицистика в жанре «портрета» проявила к образу писателя-классика Геннадия Дмитриевича Красильникова (1928–1975). Видимо, это во многом связано с вниманием и чуткостью писателя к творческой молодежи, к вступающим в те годы в профессиональную литературу авторам названных книг.

В портретной галерее современников П. Чернова «Земля отцов» особенно выделяется образ писателя Геннадия Красильникова. Знаменитого земляка – «Эшъесынартэ» («Рядом с друзьями») – П. Чернов стремится показать через изображение наиболее значимых фактов и эпизодов биографии. Сюжетообразующим центром произведения является автор-повествователь, который был свидетелем и очевидцем произошедших с героем «портрета» событий. В произведении дается установка на достоверность: «монадзи» («я видел»), «озьы вал» («это было»), «тодамваисько» («я вспоминаю»), «ноку угвунэты» («я не забуду»), «али кадь иксин азям пуктисько» («как сейчас перед глазами») и т. д. Повествование от первого лица делает произведение живым, познавательным.

Важно отметить, в литературном портрете П. Чернова нет детального изображения внешности Красильникова, но сделан акцент на наиболее выразительной портретной детали, выделяющей в герое доминантную черту его характера. Интересно, что эти детали, с одной стороны, индивидуализируют образ удмуртского писателя; с другой – типизируют. Действительно, многое из того, что было свойственно Г. Красильникову, характерно для национальной интеллигенции «шестидесятых» в целом. Это твердость духа, отстаивание идеалов гуманности, усердие в труде, правдивость, внимание к простому человеку, высокие требования к себе как к представителю национальной творческой интеллигенции. «Пуменмоншоди: та таза, жужытегитворгорондыртытэквераське но, вамышъя но, улэ но. Нош со поннаваньзэйыг-йыглэсьтэ, дыр» («Постепенно я почувствовал: этот здоровый, высокий молодой мужчина не только говорит задумчиво, но и шагает по жизни неторопливо, серьезно. И, наверное, он все делает основательно» – удмуртский текст приводится в дословном переводе авторов статьи – Т.З., О.М.) [Чернов, 1983: 74].

В литературном портрете П. Чернова интересен эпизод, раскрывающий неизвестную ранее страницу из творческой биографии Красильникова. Он связан с состоявшимся в 1966 году в г. Москве в Союзе писателей России творческим отчетом писателя. Часть критиков обвинила удмуртского автора в украшательстве, в отходе от действительности. Неверное понимание московской критикой идей красильниковских рассказов во многом обусловлено как изъянами перевода художественного текста на русский язык, так и незнанием ими реалий народной жизни, – поясняет П. Чернов.

Живой образ Г.Д. Красильникова представлен в портрете-очерке С. Самсонова «Асьмевозын, асьмесюлэмын» («Рядом с нами, в наших сердцах»), для которого характерны содержательная и интеллектуальная наполненность, имеющие формообразующее значение. С. Самсонов обращается к типу повествования, который соединяет в себе биографическое (героя) и автобиографическое (автора) начала. С. Самсонов хочет сказать о наставнике-писателе то, что о нем

еще не известно читателю, дополнить и расширить привычный образ известного удмуртского советского писателя. Поскольку образ Г. Красильникова создается на основе личных впечатлений автора, то, описывая собственное восприятие человека, присущие ему привычки, пристрастия, интересы, манеру поведения, Самсонов стремится найти «изюминку» в его творческой индивидуальности.

Образ писателя выстраивается из множества отрывочных авторских воспоминаний и впечатлений, обуславливающих свободное композиционное построение произведения. В целом же, воссоздавая образ Г. Красильникова, С. Самсонов отдает предпочтение таким компонентам жанра, как историческая достоверность, психологизм, принцип типизации, делает особый упор на передачу общественно-литературной атмосферы эпохи, в которой жил и творил писатель. На примере своих взаимоотношений с Красильниковым автор показывает, как в реальности осуществлялась преемственность классических традиций в удмуртской литературе. Не раз брал Г. Красильников начинающего Самсонова с собой в командировки в дальние районы, на производственные предприятия, в различные творческие организации. Более всего восхищали С. Самсонова в облике старшего писателя-современника такие черты, как знание народной речи, сознательное отношение к слову, широта воззрений, твердость убеждений, а в особенности – исключительное внимание и доброжелательная требовательность ко вновь вступающим в литературу. Психологически точно воссозданы эпизоды, раскрывающие то, как учился С. Самсонов у наставника объективно воспринимать критику, конструктивно реагировать на положительные и отрицательные рецензии. В самсоновских воспоминаниях Красильников также представлен в домашнем кругу, в беседах с друзьями-студентами по литературному институту, как гостеприимный хозяин, принимающий в качестве депутата Верховного Совета РСФСР многочисленных посетителей.

Достаточно часто С. Самсонов обращается к историко-литературным отступлениям, к приему беседы, позволяющим представить героя сквозь призму эпохи с учетом ее идеологических, нравственных, этических составляющих. Больше всего Г. Красильникову приходилось бороться с бюрократизмом; не потеряли актуальности красильниковские размышления о том, как чиновничье-бюрократический произвол тормозит новаторские идеи, идущие от жизни, от народа.

Будучи основанным на свободном чередовании зарисовок, сценок, бесед, диалогов, авторских разъяснений, отступлений, обобщений, самсоновский портрет довольно полно представляет основные этапы творческой жизни Г. Красильникова: от работы над первыми рассказами до последних дней, проведенных в больнице. Отсюда достоверность образа героя, дающего представление о типе национального или регионального писателя, пришедшего в отечественную

литературу в эпоху «шестидесятых». Обобщающую силу придает очерку финальный эпизод, рассказывающий о проведении 17 июня 1988 года в Октябрьском зале Дома Союзов в Москве литературного вечера, посвященного 60-летию Г. Красильникова. На его открытии председатель правления Союза писателей РСФСР Сергей Владимирович Михалков верно подчеркнул, что Геннадий Красильников – гордость не только удмуртского народа, но и всей многонациональной России.

В рассмотренных произведениях авторы сами становятся героями наряду с изображаемыми персонажами. Писатели не вводят в тексты своих произведений документальных свидетельств (письмо, дневник, цитата и др.). Здесь можно говорить о таком явлении, как авторский документ, т. е. жанр литературного портрета в удмуртской публицистической прозе чаще создается в форме личных воспоминаний, личного восприятия творчества и человеческих качеств «портретируемого» героя.

## Литература

1. *Ведищева Ю.В.* О современном состоянии теории жанра литературного портрета // Вестник Тамбовского университета. Серия: Гуманитарные науки. – 2011. – Вып. 10 (102). – С. 230–234.

2. Чернов П.К. Атаймузъем: очеркъес / Земля отцов: очерки. – Ижевск: Удмуртия, 1983. – 152 с.

**Ә.М. Закирҗанов**
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, Казань

# ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН – ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫН ТИКШЕРҮЧЕ

**А.М. Закирзянов**
ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, Казань

# ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН – ИССЛЕДОВАТЕЛЬ ИСТОРИИ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ

**Аннотация.** Статья посвящена изучению научных трудов ученого-литературоведа Ф.Г. Галимуллина. Выявляются его научные интересы, методологические и теоретические основы изучения истории татарской литературы. На примерах показывается стремление ученого к объективности и аргументированной

доказательности в описании и анализе различных периодов истории искусства слова и творчества ведущих его представителей. Находки и достижения Ф.Г. Галимуллина стали серьезной базой для дальнейших исследований в истории татарской литературы.

**Abstract.** The article is devoted to the study of the scientific works of the literary scholar F.G. Galimullin. His scientific interests, methodological and theoretical foundations of the study of the history of Tatar literature are revealed. Examples show the scientist's desire for objectivity and reasoned evidence in the description and analysis of various periods in the history of the art of the word and the work of its leading representatives. The findings and achievements of F.G. Galimullin became a serious basis for further research in the history of Tatar literature.

**Ключевые слова:** Фоат Галимуллин, литературовед, татарская литература, методология, принцип, объективность.

**Keywords:** Foat Galimullin, literary critic, tatar literature, the methodology, principle, objectivity.

Тарихы мең елдан артып киткән татар әдәбиятында халыкның үткән тарихы, теләк-омтылышы, яшәү рәвеше, аны милләт итеп таныткан сыйфатлары, ирек-азатлыкка омтылышы, шуның тарихи сәхифәләре чагылыш таба һәм алдагы буыннарга сакланып кала. Шуңа да сүз сәнгате тарихын өйрәнү халыкның җанлы рухын аңлау-бәяләү, аны катлаулы вакыйгалар сөременнән аралап алу, уй-фикер, хис-кичереш аша укучы күңелендә урын алырдай итеп күрсәтүгә хезмәт итә. Әлеге катлаулы һәм җаваплы вазифа бу өлкәдә эшләүчедән аек акыл, чиста күңел, вөҗдан сафлыгы, объективлык һәм принципиальлек, кирәклеген җаның-тәнең белән тоюны таләп итә. Талантлы әдәбиятчы, филология фәннәре докторы, профессор Фоат Галимулла улы Галимуллин – әлеге таләпләргә җавап бирүче олпат галимнәрнең берсе. Табигать биргән сәләте аны яшьлек елларында ук әдәбият-сәнгатькә алып килә һәм шуннан соңгы вакыт эчендә оста оратор-диктор, талантлы җырчы, оештыручы-җитәкче, галим-филолог буларак киң танылу ала [Закирзянов, 2016: 350]. Шулай да ул озын гомеренең күп өлешен татар әдәбиятын фәнни нигездә өйрәнүгә, үз чоры әдәби процессының үзенчәлекләрен ачуга багышлый һәм җитди казанышларга ирешә.

Фоат абый Галимуллин каләмен 1950 еллар уртасында чарлый башлап, район, республика матбугатында язмалары, хикәяләре дөнья күрә. Ә инде 1974 елда Казан дәүләт педагогика институтына эшкә килгәч, әдәбият белән фәнни нигездә кызыксына башлый. Студентларга борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты буенча лекцияләр укуга бәйле, татар әдәбияты тарихын башлангыч дәверләреннән алып өйрәнә. Шул ук вакытта XX гасыр башы әдәбияты, шулай ук үз чоры әдәби барышы да игътибарыннан читтә калмый. Матбугат

битләрендә Ф. Борнаш, Г. Ахунов, М. Әмир, Ш. Бикчурин, В. Нуруллин, Р. Вәлиев иҗатлары турындагы язмалары чыгып, әдәби тәнкыйтькә үзенчәлекле автор килүен хәбәр итә. Яшь әдәбиятчының беренче тикшеренүләре нәтиҗәсе буларак «Хәзерге татар прозасында индустриаль хезмәт кешеләре характерлары» (1980) дип аталган кандидатлык диссертациясе яклана. Бераздан «Инешләр Иделгә кушыла» [Галимуллин, 1985] исемле тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы дөнья күрә. Әлеге хезмәтләрендә яшь галим совет чоры әдәбиятында аеруча киң чагылыш тапкан мәсьәләне – геройның әхлакый йөзе һәм характерының хезмәттә формалашуын өйрәнә. Беренчеләрдән булып Г. Әпсәләмов, А. Гыйләҗев, Ф. Хөсни, А. Расих, Ә. Баян, Э. Касыймов, Ш. Бикчурин, Г. Ахунов, Х. Сарьян кебек әдипләрнең күпсанлы повесть-романнарын бәяли һәм бу чор татар прозасының, XX йөз башындагы традицияләрне дәвам итеп, яңа сыйфат биеклегенә күтәрелүен дәлилли. Соңгысы исә әдәбиятның милли яшәешкә йөз белән борылуы, шуңа нисбәтле татар халкына хас сыйфатларны үзенә туплаган геройларның мәйданга чыгуы белән аңлатыла. Автор татар прозасының сәнгати планда үсеш кичерүен билгели һәм аның түбәндәге үзенчәлекләрен аерып чыгара: халык тормышын киң планда үткән һәм бүгенге бәйләнешендә, әхлакый кыйммәтләр сакланышы аша ачу; геройларның эчке дөньяларын, хис-кичерешләрен тасвирлауга бәйле психологизмның тирәнәюе; яшәештәге җитди мәсьәләләрне бөтен кискенлеге белән куеп, җәмгыятьтә кабул ителгән тәртипләрне мөмкин булган кадәр турыдан туры, еш кына «эзоп теле» ярдәмендә тәнкыйтьләү; сурәтләүдә яңа алым-чараларга актив мөрәҗәгать итү һ. б. Үз чоры татар әдәбиятының әйдәп баручы прозаиклары иҗатына бәяләмәсе тулы бер иҗат портреты яисә фәнни очерк төсен ала һәм киң җәмәгатьчелектә җитди бәхәсләргә, матбугатта фикер алышулар башлануга китерә. Дөрес, әлеге хезмәтләрдә әдәби әсәрләрдә хезмәт кешесе сурәтләнешендәге берьяклылыкка игътибар, тәнкыйди караш җитми, ул исә чорга хас көчле идеологик басым белән аңлатыла. Шуның өстенә башкача язган булса, диссертациясен яклый алыр иде-ме икән? Әмма бу хезмәтләр Ф. Галимуллинның сүз сәнгатен кабул итү һәм бәяләүдә үзенә хас метод-алымнар белән эш итүен күрсәтә. Бердән, яшь галим үзенең эрудиясе белән җәлеп итә. Татар әдәбияты тарихын борынгыдан бүгенгесенә кадәр яхшы белүе һәр язмада диярлек традицияләр дәвамчанлыгы һәм әдипнең яңачалыгы турында җитди сүз әйтү мөмкинлеге бирә. Икенчедән, теге яисә бу язучы иҗатына шул чор әдәби хәрәкәтендә урын алган сыйфат-билгеләр аша килә һәм әдәби барыштагы урынын билгелүгә юл ача. Өченчедән, бәяләнә торган әсәр авторы кем булуына карамастан, объектив бәя бирүне максат итә. Шуңа да әлеге язмалар кызыксынып укыла, җитди фикер алышуга этәрә.

Ф.Г. Галимуллинның фәнни кызыксынулары киңәя барып, ул XX йөз башы һәм гасырның 20–30 еллары татар әдәбиятының үсеш-үзгәреш үзенчәлекләрен

тикшерүгә килә. XX йөз башында татар әдәбияты Яңарыш кичереп, сан һәм сыйфат ягыннан байый, реализм һәм романтизмның яңа хасиятләрен ача, модернистик эзләнүләрдән дә читләшми, күпсанлы традицияләргә нигез сала. Аның Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Җ. Вәлиди, Дәрдемәнд һ. б. турындагы җитди фәнни мәкаләләре әнә шул үзенчәлекләрне ачыклауга юнәлтелгән булуы белән зур кызыксыну тудыра. Галимнең әдәбият тарихын өйрәнүгә алып килгән яңалыгы, бер яктан, күренекле классиклар иҗатының идея-эстетик һәм фәлсәфи-этик катламнарын ачуда, заман биеклегеннән торып бәяләүдә, башка халыклар әдәбияты белән чагыштырып һәм традицияләр дәвамчанлыгы, яңачалыкларга мөнәсәбәтле тикшерүдә булса, икенче яктан, Шәрык һәм Рус-Европа әдәби-фәлсәфи карашлары яссылыгында тикшереп, яңа сыйфатларын ачуда иде.

Әдәбият фәненең тирән катламнарын ачу ягыннан Фоат Галимулла улының «1920–30 еллар татар әдәбиятында эстетик фикер һәм социологизм мөнәсәбәте» дигән докторлык диссертациясе җитди фәнни казаныш буларак бәяләнә. Әлеге тикшеренүнең нигезен тәшкил иткән «Эстетика и социологизм» [Галимуллин, 1998] хезмәтендә гаять каршылыклы һәм күп бәхәсләр уяткан чордагы әдәби хәрәкәт үзенчәлекләрен бөтен асылында ачыкларга һәм бәяләргә алына ул. Бу өлкәдәге тикшеренүләрен дәвам итеп, алдагы елларда «Әле без туганчы” [Галимуллин, 2001], «Табигыйлеккә хилафлык» [Галимуллин, 2004], «Эзләнү вакыты» [Галимуллин, 2005], «Татар әдәбиятында эстетик эзләнүләр» [Галимуллин, 2010] дигән хезмәтләре басылып чыга. Аларда дәвернең катлаулы әдәби мохите тулы, системада күз алдына бастырыла һәм сүз сәнгатендә эстетика кануннары һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәтен, шул исәптән әдәби мирас, иҗат методы, әсәр стиле һ. б. эстетик категорияләрне ачыклый барып, әдәбият фәненә җитди яңалык алып килә.

Автор XX гасырның 20–30 нчы еллар әдәби хәрәкәте үзенчәлекләрен күпсанлы әдәби фактларга, моңа кадәр читтә калдырылган әсәрләргә нигезләнеп өйрәнә. 1920 елларның икенче яртысыннан башлап, әдәбият-сәнгатьнең идеологиягә буйсындырылуы, социаль заказ белән язуның гадәти күренешкә әйләнүе, ягъни вульгар социологизм дип аталган мәнсез күренешнең өстенлек алуы эзлекле рәвештә ачыклана. Безнең күз алдына чорның тулы әдәби мохите бастырыла. Ф.Г. Галимуллин, әдипләр иҗатын объектив бәяли барып, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, Һ. Такташ, Х. Туфан, Ф. Кәрим, К. Нәҗми, Г. Газиз, Г. Рәхим, Г. Толымбай, Ф.С.-Казанлы кебек язучылар шәхесенә, мирасына яңача карарга, аларның иҗат концепциясендәге үзгәрешләрне күзәтергә мөмкинлек бирә. Бөтен җаны-тәне белән яңа җәмгыяткә хезмәт иткән һәм үзләре үк шуның корбаны булган шәхесләрнең фаҗигасен тирәнрәк аңлый башлыйсың. Күпсанлы мисаллар аша, галим, әйдәп баручы әдипләрнең тормыш материалын

сайлап алуда, алым-чаралар, образлы тел куллануда үзләренә генә хас иҗат индивидуальлеген ача, шуның белән аларның әдәби процесстагы урынын, әһәмиятен билгели.

Әдәби хәрәкәтне бөтен тулылыгында күз алдына бастыру өчен, Ф.Г. Галимуллин «Яңалиф», «Безнең юл», «Атака», «Мәгариф» кебек газета-журналлардагы, аерым җыентыклардагы материалларны, төрле истәлекләрне әйләнешкә кертә. Әдәби юнәлешләрнең, аеруча реализм һәм романтизмның үзара нисбәтен тикшерү аша татар әдәбиятындагы стиль үзгәрешләрен эзлекле һәм дәлилле аңлатуга килә. Әлеге хезмәтләрнең тагын бер үзенчәлеге шунда, галим әдипләргә яисә тәнкыйтьчеләргә ярлыклар тагу, барысын да каралтып күрсәтү юлыннан китми, бәлки объективлык һәм дәлиллеккә омтыла. Сүз сәнгатендәге кимчелекләрне, еш кына артка чигенүләрне күзәтү, бәяләү белән бергә, әдәбият үсешен тәэмин иткән, традицияләргә барып тоташкан эзләнүләр Ф.Г. Галимуллин игътибарыннан читтә калмый. Ул Х. Туфан, Г. Кутуй, Ш. Маннур, Г. Мөхәммәтшин, Г. Рәхим, Ш. Усманов кебек әдипләрнең иҗат портретларын тудыруга ирешә. Гомумән, галимнең 1920–30 елларга караган тикшеренүләре әдәби хәрәкәтне, аерым төрләр һәм жанрлар үсешен, тема-мотивлар төрлелеген, эстетика һәм социологизм мөнәсәбәтен, тәнкыйтьнең торышын эзлекле бәяләү белән бергә, яңа фәнни-теоретик эзләнүләргә җитди нигез булып тора.

Фоат абый Галимуллинның фәнни тикшеренүләрендә XX гасыр татар әдәбияты тарихы төп урынны алып торса да, сүз сәнгатенә ул бөтенлекле якын килә. Шуңа да әдәбият тарихының борынгы дәверләреннән алып XIX йөз ахырына кадәрге чорлары даими рәвештә галим тикшеренүләре объекты булып тора. Татар әдәбияты үсешенә гаять зур йогынты ясап, гасырлар дәвамында аны сугарып торган болгар чоры әдибе Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренә, Алтын Урда дәверенең танылган әдипләре иҗатына, шул исәптән данлыклы «Идегәй» дастанына, Казан ханлыгының Мөхәммәдъяр, Кол Шәриф, шулай ук М. Колый, У. Имәни кебек шәхесләргә әледән-әле әйләнеп кайта. Әлеге тикшеренүләрнең методологик нигезе булып, әдәбиятта тарихи-иҗтимагый һәм мәдәни күренешләр чагылышын, аларда халыкның яшәү рәвеше, уй-хыяллары урын алуын язучыларның сәнгати фикерләү үзенчәлекләре белән бәйләнештә ачу билгели. Шуңа да галим әлеге чор әсәрләрендә кеше шәхесенең алгы планга куелуын, аның эчке һәм тышкы матурлыгын, акыл көчен, хисләр муллыгын тикшерүгә максатчан якын килә. Яшәеш мәсьәләләре авторларның фәлсәфи-дидактик, дини-мистик карашлары белән үрелеп баруы, аларның үз чоры өчен генә түгел, киләсе буыннарга да кызыклы һәм гыйбрәтле булуы эзлекле дәлилләнә.

Ф.Г. Галимуллин тикшеренүләрендә мөһим бер урынны әдәбиятларны чагыштырма планда өйрәнү алып тора. Татар әдәбияты үзенең башлангычын

уртак төрки мирастан алган кебек, гасырлар дәвамында Шәрык һәм Гареб әдәбиятлары белән тыгыз бәйләнештә яши, аларның эстетик казанышларын иҗади файдалана һәм шул ук вакытта үзе дә байтак халыклар әдәбиятына шифалы йогынты ясый. Галим татар һәм чит илләр вакытлы матбугатында басылып чыккан мәкаләләрендә, шулай ук «Писательское слово на рубеже эпох», «Татарская литература: взгляд сквозь столетия», «Рухи хәзинәләр гасыры» кебек китапларында урын алган язмаларда милли әдәбиятларның үзара бәйләнешен ачуга, шуның аша әдәбият тарихын яңа фактлар, әдәби-эстетик табышлар белән баетуга, тулылындаруга зур өлеш кертә. Әлеге хезмәтләрдә урын алган «Диалог культур и литератур приволжских народов» [Галимуллин, 2014: 134–140], «Жизнь и творчество Йывана Кырли в татарском литературном творчестве 1920–1930-х гг.» [Галимуллин, 2014: 183–187], «Современная татарская литература в контексте общероссийского искусства слова» [Галимуллин, 2014: 188–192], «Татарская литература в контексте культур тюркских народов» [Галимуллин, 2016: 195–209], «Чингиз Айтматов: взаимодействие литератур и народов» [Галимуллин, 2016: 225–232], «Духовный мир народов в условиях глобализации» [Галимуллин, 2016: 282–287] һ. б. язмалар фикер киңлеге, фәлсәфи тирәнлеге белән җәлеп итә. Әдәбиятларны чагыштырма өйрәнүгә ул заман таләбе һәм гаять перспективалы өлкә буларак якын килә. Ф.Г. Галимуллин иркен рәвештә төрки халыклар әдәбиятына мөрәҗәгать иткән кебек, Идел буе халыкларыннан башкорт, чуваш, мари, удмурт һ. б. әдәбиятларының күренекле вәкилләре иҗатын да тирәнтен белеп тикшерә. Шунысы да игътибарга лаек, галим аерым әдипләр аша чагыштырма поэтика алга куйган метод, жанр, стиль кебек теоретик сорауларга, әдәби тәрҗемә мәсьәләләренә килеп чыга. Әлеге хезмәтләрдә, татар әдәбиятының аерым сәхифәләре яңа аспектта бәяләнү белән бергә, әдәбиятлар арасындагы уртаклык, сүз сәнгатенең милли үзенчәлекләргә нигезләнүе белән бергә, гомумкешелек кыйммәтләренә хезмәт итүе күп санлы мисалларда дәлилләнә.

Фоат абый Галимуллин әдәбият тарихын фәнни нигездә тикшерүче галим булу белән бергә, үз чорының әдәби хәрәкәтен даими күзәтеп барып, этрафлы язмалары белән аның үсеш-үзгәреш үзенчәлекләрен билгеләүче тәнкыйтьче дә булып кала. Татар сүз сәнгатен өйрәнә башлаган 1970 елларда ук ул байтак язучының иҗатына күзәт ясый, аларга хәер-фатиха биргән кебек, язучылык хезмәтенең асылы, бурыч-вазифалары, халык алдындагы бурычы турында уйланырга да этәрә. Шул чордан башлап бүгенгәчә, ул татар әдәби процессының үзәгендә кайный. Ә инде 1999–2005 елларда ТР Язучылар берлеге идарәсенең рәисе буларак, әлеге эшчәнлекне оештыруда турыдан-туры катнаша, шәхси инициативасы белән байтак башлангычларга нигез сала. Безнең буынның күз алдында булган, хәзер инде байтагы тарихта калган әдәби хәрәкәт турында

Фоат Галимулла улы даими рәвештә үз сүзен әйтеп килә. Күпсанлы тәнкыйть мәкаләләрен үз эченә алган «Офыкларны алдан күреп» [Галимуллин, 1995], «Эзләнү вакыты» [Галимуллин, 2005], «Писательское слово на рубеже эпох» [Галимуллин, 2014], «Рухи хәзинәләр гасыры» [Галимуллин, 2017] җыентыклары әдәби вакыйга буларак кабул ителә. Татар әдәбиятын фәнни нигездә өйрәнү һәм шуны студентларга җиткерүне төп вазифасы итеп алган галим әдәби тәнкыйть өлкәсендә чын профессиональ буларак эш итә. Әдәби процессның эчке үзенчәлекләрен ачу аша теге яисә бу әдип иҗатына килә ул һәм сәнгати табышларын чор әдәбиятына нисбәтле бәяли. Шуңа да күпсанлы язмалары дәлилле булуы, фәлсәфи киңлеге, эмоциональ тәэсирлелеге белән аерылып тора. Үз вакытында ук Ә. Баянов, М. Насыйбуллин, М. Хәбибуллин, М. Маликова кебек әдипләрнең иҗат үзенчәлеген күреп алып, аларны әдәби җәмәгатьчелеккә беренчеләрдән булып җиткерүче Ф.Г. Галимуллин була. Әдипләрнең һәр яңа әсәре яисә китабы игътибар үзәгендә булып, әлеге талантлы шәхесләр турында тулы канлы, бөтенлекле иҗат портретлары дөнья күрә. Фоат абый беренчеләрдән булып күреп алып, этрафлы бәя биргән әлеге шәхесләрдән тыш, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Ә. Еники, И. Салахов, Р. Мөхәммәдиев, Р. Сибат, Ф. Садриев һ. б. кебек әдипләрнең күбесе ТР Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган икән, бу да әдәбиятчының профессиональ осталыгы турында сөйли. Ул тәнкыйтьнең һәр жанрында дип әйтерлек үзен иркен хис итә, ә инде күзәтү төсендәге мәкаләләре әдәби әсәр кебек укыла. Аларда әдәбиятка бәя бирү белән бергә, чорның әдәби-мәдәни мохитенә йогынты ясаган шартлар турында җитди сүз алып барыла. Галим-тәнкыйтьченең хезмәтләре эстетик юнәлеше һәм аналитик фикерләүгә йөз тотуы белән дә үзенчәлекле. Әдәбияттагы һәр яңалыкны ул традицияләргә нисбәтле ачу-аңлатуга килә. Ә инде сәнгати фикерләүдәге үзенчәлекләргә әдипләрнең дөньяга карашы, иҗат концепциясе, шулай ук әдәби юнәлеш яисә агым тарафдары буларак бәяләү аша килә.

Шулай итеп, Ф.Г. Галимуллин күпсанлы хезмәтләрендә татар әдәбияты тарихын тикшерүнең фәнни-теоретик нигезләрен, төп принципларын, методларын ачыклауга килә. Сүз сәнгатенең үсеш этап-дәверләренә хас үзенчәлекләрне өйрәнү аша, аларда өстенлек иткән әдәби-эстетик һәм фәлсәфи кыйммәтләрне билгели, киләчәк перспектив тикшеренүләргә юл күрсәтә һәм шуның белән татар әдәбият белемендә лаеклы урын алып тора.

### Әдәбият


1. *Галимуллин Ф.Г.* Әле без туганчы... 1920–1930 еллар әдәби хәрәкәтенә бер караш. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 320 б.

2. *Галимуллин Ф.Г.* Инешләр Иделгә кушыла. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 136 б.

3. *Галимуллин Ф.Г.* Офыкларны алдан күреп. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 200 б.

4. *Галимуллин Ф.Г.* Писательское слово на рубеже эпох. – Казань: Изд. Казанского университета, 2014. – 288 с.

5. *Галимуллин Ф.Г.* Рухи хәзинәләр гасыры. Фәнни, публицистик мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 399 б.

6. *Галимуллин Ф.Г.* Табигыйлеккә хилафлык. XX гасырның егерменче-утызынчы еллар татар әдәбиятының үсеш үзенчәлекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 303 б.

7. *Галимуллин Ф.Г.* Татарская литература: взгляд сквозь столетия. – Казань: РИЦ «Школа», 2016. – 294 с.

8. *Галимуллин Ф.Г.* Эзләнү вакыты. Әдәбият тарихына багышланган мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Мәгариф, 2005. – 247 б.

9. *Галимуллин Ф.Г.* Эстетика и социологизм. – Казан: Мәгариф, 1998. – 224 б.

10. *Закирзянов А.М.* В ногу со временем… (В связи с 75-летием профессора Ф.Г. Галимуллина) // Филология и культура. Philology and culture. – 2016. – № 1 (43). – С. 350–353.

**М.И. Җиһаншина**
Казан федераль университеты, Казан

## ХАЛЫК ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ АВТОР ҖЫРЛАРЫНЫҢ ОБРАЗЛАР СИСТЕМАСЫНДАГЫ УРТАКЛЫКЛАР ҺӘМ АЕРМАЛАР

**М.И. Зиганшина**
Казанский федеральный университет, Казань

## ОБЩНОСТЬ И РАЗЛИЧИЯ В ОБРАЗНОЙ СИСТЕМЕ НАРОДНЫХ И СОВРЕМЕННЫХ АВТОРСКИХ ПЕСЕН

**Аннотация.** В данной статье изучаются образы в народных и авторских песнях, их сходства и различия. Мы рассмотрели образы, связанные с животными, растениями и небесными телами. Нами были установлены сходства и различия этих образов.

**Ключевые слова:** песня, образ, народные песни, авторские песни.

**Abstract.** This article examines the images in folk and author's songs, their similarities and differences. We considered images associated with animals, plants,

and celestial bodies. We have established the similarities and differences of these images.

**Keywords:** song, image, folk songs, author's songs.

Шигърият, гомумән сүз сәнгате, дөньяны образлар аша танып белә. Ул – фикер йөртүнең сурәтле формасы. Әсәрдәге идея дә нигездә образлар аша ачыла, ягъни җәмгыять эчендә, табигать кочагында һәм әйберләр тирәлегендә тасвирлана [Миңнуллин, 2003: 149].

Поэзиянең, шул исәптән җырларның, дөньяның танып белүдә образлар белән эш итүе кешелекнең борынгы чорына һәм шул чорга хас фикерләү формаларына ук барып тоташа. Адәм баласы беркайчан да аерым гына яшәмәгән һәм яшәми, ул табигать һәм хайваннар дөньясы, әйберләр мохите белән тыгыз бәйләнештә.

Образ – әдәби әсәрдә кеше тормышының сурәтләнеше. Язучы образлар ярдәмендә тормышны чагылдыра, кешеләрнең төрле хәлләрдә үз-үзләрен тотуларын табигатькә мөнәсәбәтен белдерә һәм укучыларда да шундый ук мөнәсәбәт уятырга омтыла [Әдәбият белеме, 2007: 136].

Җырларның образлар системасын берничә төркемгә бүлеп карарга була. Алар нигездә түбәндәге бүленешкә сыеп бетәләр: хайваннар дөньясы, үсемлекләр, табигать күренешләре һәм географик атамалар.

Татар халык һәм автор җырларында хайваннар дөньясыннан алынган образлар аеруча киң таралган. Бу төркем еш кына ике өлешкә бүлеп өйрәнелә. Беренчесе – кошлар, икенчесе – җәнлек-хайваннар. Әлеге фәнни эш кысаларында да шартлы рәвештә без әлеге бүленешне саклarбыз.

Кош образлары аеруча актив. Алар арасында төп урынны *сандугач, тургай, аккош, акчарлак, карлыгач, кәккүк* алып тора, *кыр казы, кыр үрдәге, бөркет* кебек кошлар исә сирәгрәк кулланыла.

Халык җырларында сандугач традицион образга әйләнгән, ул күптөрле символик мәгънәләрдә кулланыла. Без күзәтү ясаган җырларда сандугач сайравын моң һәм хәсрәт символы итеп куллану бик актив:

***Сандугачкай*** *сайрый, мин елыймын,*
*Ниләр күрер икән бу башым* [Тарихи һәм лирик җырлар, 1988: 238].

Автор җырларында да сандугач образы сагыну символы буларак бирелә:

***Сандугачкай*** *сайраганда*
*Канат кагына микән?*
*Минем кебек, әллә ул да*
*Ярын сагына микән?* (Ә. Исхак сүзләре, «Сандугач» җыры).

Аккош образына күз салыйк. Татар халык җырларында ул тормыш юлдашыннан, сөйгәненнән аерылып, ялгыз калган кешене белдерә:

*Бөтенләйгә инде ерак-ерак*
*Пар* ***аккошлар*** *очкан бу күлдән;*
*Мин дә китәм инде*
*Шул якларга карап,*
*Тик үкенмәм микән, үкенмәм?* («Аккош күле», татар халык җыры).

Автор җырларында да ялгызлык, сагыш, кемнедер көтү мотивлары белән үрелеп бирелә. Мәсәлән, «Көзге сагыш", «Ал мине дә үзең белән» (Р. Шәгәлиев), «Ялгыз итмә» (А. Басырова) һ. б.

Кайбер автор җырларында аккош көчле мәхәббәт, мәңгелек яр, парны да аңлатып килә. Мәсәлән:

*Камышлы күл буйлап* ***аккош*** *йөзә уйнап,*
*Тибрәлдерә көмеш күл өстен.*
*Төнлә төнбоеклар йомылып йоклыйлар,*
*Һавада кысса да ай күзен* (Г. Рәшитова сүзләре, «Камышлы күл» җыры).

Үсемлекләр дөньясы белән бәйле образлардан иң киң таралганы – гөл.

Ул төрле эпитетлар белән баетылып килә. Мәсәлән, *яран гөл, тамчы гөл, исле гөл, матур гөл* һ. б.

Күп кенә халык җырларында *гөл ал* сүзе белән парланып килә. Мәсәлән:

***Алдыр*** *синең яулыгың,*
***Гөлдер*** *синең яулыгың* [Тарихи һәм лирик җырлар, 1988: 220].

Соңгы еллардагы автор җырларында гөл кызыл эпитеты белән дә белдерелеп килә:

***Кызыл гөлләр, кызыл гөлләр,***
*Бигрәк якын төсләре.*
*Ялкын булса бәхетләре,*
*Юк икән шул исләре* («Кызыл гөлләр», Г. Шакирова сүзләре).

Җырларда үсемлекләрдән еш кына чәчәк сүзе, чәчәк исемнәре урын ала. Алар арасында аермалыклар аз түгел. Мәсәлән, автор җырларында ромашка образы кулланылган җырлар бар, ә халык җырларында күзәтелми.

Умырзая сүзе дә халык җырларында актив түгел, ә менә автор җырларында без мисаллар китерә алабыз: «Кызлар күңеле ак умырзая» (Р. Шәрипова сүзләре), «Ничә язлар үтте йөрәктән» (У. Кинҗәбулатов сүзләре), «Беренче мәхәббәт» (Р. Чурагулов сүзләре) һ. б.

Җырларда урын алган образларның тагын бер зур төркемен күк җисемнәре һәм табигать күренешләре дип атарга була. Биредә без ай, кояш, йолдызлар белән бергә җырларда еш очраган таң, җил һәм болыт образларына тукталырбыз.

Мәхәббәт җырларында еш кына болыт образы урын ала. Ул сагыш, күз белән үрелә һәм лирик эндәш булып килә:

*Кем сагышын алып киттең,* ***болыт,***
*Авыраеп тулып каласың.*
*Күзгә яңгыр күзгә сагыш булып,*
*Кем җанына,* ***болыт,*** *яварсың?* («Сагышларның җиңел кайсысы», Г. Әюпова сүзләре).

Татар халык җырларында *болыт* лирик чигенү буларак бирелә:

*Килә ява, килә ява*
*Иялэшкән бер* ***болыт.***
*Очар канатларым булса,*
*Тормас идем бер минут* («Килә ява бер болыт»).

Халык җырларында *таң* образы иртәне, яңа тормышны, мәхәббәтне искә төшерү символын аңлата:

***Таң-таң*** *ата, чулпан калка,*
*Чулпан* ***таңны*** *уята.*
*Чулпан* ***таңнарны*** *уята да,*
*Нигә сине уйлата* («Таң атканда», татар-башкорт халык җыры).

Автор җырларында таң ату күренеше – аерылышуны белдерә:

*Нигә сагышларны яңарту,*
*Үтте инде сөю-ярату.*
*Мөмкин түгел, түгел шул хәзер*
*Безнең өчен уртак* ***таң ату*** («Үткән инде сөю», Г. Шакрова сүзләре).

Йолдыз образы җырларда чагыштырмача аз кулланыла. Йолдыз төнге күктә айны алыштырырга мөмкин, ягъни сөйгән ярлар ай булмаса, йолдыз яктысында да очрашып серләшә алалар. Борынгы җырларда ук инде мондый юллар теркәлгән:

*Агыйделкәйләрнең аръягында*
*Бүреккә ярый торган кондыз бар;*
*Кич караңгы диеп килми калма,*
*Ай булмаса, якты ла* ***йолдыз*** *бар* [Тарихи һәм лирик җырлар, 1988: 256].

Автор җырларында сурәтләнгән йолдыз образы нигездә сөйгән ярның гүзәллеген тасвирлау өчен кулланыла. Мәсәлән:

***Йолдыз*** *бүләк итмим, чөнки буем җитми,*
*Бүләк итәм сиңа чын сөю.*
*Әгәр булсак бергә, кайгың булмас бер дә,*
*Урап узар яну һәм көю* («Ләйсәнгә», С.Фәтхетдинов сүзләре).

Халык җырларында җил образы гомер узу, гомер агышы итеп сурәтләнә. Мәсәлән:

*Ай-һай, кардәшләр, гомерләр үтә*
***Искән җил кебек*** [Тарихи һәм лирик җырлар, 1988: 82].
*Үтәсең лә, гомрем, ай үтәсең,*
*Сахраларда* ***искән җил кебек*** [Кыска җырлар, 1976: 169].

Автор җырларында җил сөйгәне белән чагыштырыла:

*Утырам җиде юл чатында*
*Уйларым тик синең хакында.*
***Салкын җил*** *өшетә битемне*
*Син дә бит нәк шушы шикелле* («Искән җил», Ф.Тимербаева сүзләре).

Шулай итеп, халык һәм хәзерге автор җырларында образлар системасында охшаш һәм аермалы яклар бар. Еш кына аларда образ бер мәгънә белдереп килсә, кайвакыт бүтән мәгънәләргә дә ия була алар. Әлеге фәнни мәкаләдәге мисаллар шуны күрсәтә.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

2. *Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. – Казан: Мәгариф, 2003. – 400 б.

3. Татар җырлары. – URL: http://erlar.ru/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.02.2021. – 13.02.2021).

4. Татар халык иҗаты. Кыска җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 375 б.

5. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 487 б.

**Л.Ф. Касерта**
Государственный университет им. В. Ферриса, Биг Рапидс, США

# ЛИТЕРАТУРНО-КРИТИЧЕСКАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ФОАТА ГАЛИМУЛЛИНА В ПРОЦЕССЕ РАЗВИТИЯ НАЦИОНАЛЬНОЙ КУЛЬТУРЫ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ

**Аннотация.** Современное исследование литературно-критической деятельности Ф. Галимуллина является актуальным изучением литературоведческих статей ученого для развития татарской национальной культуры как части межкультурного коммуникативного процесса.

**Ключевые слова:** литература, литературоведение, критика, татарская литература.

**Abstract.** Modern research of literature critical work of Foat Galimullin is relevant study of articles about Tatar national culture as a part of intercultural communication.

**Keywords:** literature, literature critics, Tatar literature.

Фоат Галимуллович Галимуллин – выдающийся ученый, известный литературовед, автор многочисленных учебников, профессор кафедры татарской литературы Казанского Федерального университета. Научные исследования Ф.Г. Галимуллина широко известны и разнообразны; исследования татарской литературы второй половины XX века, проведенные ученым, опубликованы в многочисленных монографиях, учебных пособиях и статьях. Х.Й. Миннегулов дает следующую характеристику академической работе Ф.Г Галимуллина: «Ученый работает в различных отраслях, принимает активное участие в воспитании национальных кадров, создании программ, учебников, хрестоматий для уроков литературы в учебных заведениях. И все-таки основная сфера его научной деятельности – литературоведение, литературная критика» [Миннегулов, 2014: 121]. Произведения Ф.Г. Галимуллина «Реки присоединяются к Волге» (1985), «Предвидя горизонты» (1995), «Время поиска» (2005) посвящены анализу татарской литературы. Например, в статье «Эзләну вакыты» (2005) ученый анализирует творчество Г. Исхаки и определяет новые литературные темы и образы в татарской литературе, созданные писателем. Литературовед выделяет глубоко национальную проблему исторического развития татарского народа на рубеже веков – конфликт нового и старого в жизни молодого поколения: «Такие люди бывают и в жизни. Он думает правильно, душой готов творить что

угодно, нет предела мечтам. Однако не может приступить к действиям, чтобы сделать эти намерения реальными» [Галимуллин, 2005: 167].

Следует особо отметить вклад Ф.Г. Галимуллина в изучение творчества Г. Тукая. В работе «Халыкнын уз шагыйре» (2005) ученый высоко оценивает не только творчество, но и характер писателя. Ф.Г. Галимуллин выделяет такие черты характера Г. Тукая как прямолинейность, бесстрашие, любовь к природе, умение видеть и ценить красоту женщин. «Г. Тукай – это не только поэт, быть может, язык нашего народа, и мелодия, и дух, и судьба», – пишет критик [Галимуллин, 2005: 125]. Анализируя роль творчества Г. Тукая, Ф.Г. Галимуллин также отмечает синтез национального и общенародного в поэзии татарского поэта: «Г. Тукай успел выполнить очень важную роль в истории татарской поэзии: заложил основу новой эры развития татарского словесного искусства, обеспечил выход нашей поэзии на мировой уровень» [Галимуллин 2005: 46].

Важное место в литературоведческой деятельности Ф.Г. Галимуллина занимает изучение литературы 20–30 гг. XX века. Ученый исследует проблемы стиля, метода, литературных направлений, влияния социологии на формирование литературы данного периода. Например, Ф.Г. Галимуллин объясняет ошибочное мнение критиков 20–30 гг. о Г. Тукае как о мелко буржуазном поэте связью поэта и ислама, вероисповедание Г. Тукая, его знание Корана понималось как недостаток, а не как национальная реалия представителя татарской интеллигенции начала XX века.

Исследование татарской литературы профессором Ф.Г. Галимуллиным всегда ведется в контексте других культур. Например, во множестве статей ученого анализируется взаимосвязь татарской литературы с литературой Поволжья: башкирской, чувашской. Татарская литература в работах критика рассматривается как национальная и общероссийская в контексте многонационального и мультилингвального пространства. Работы ученого позволяют понять своеобразие татарской культуры. Большое внимание уделяет исследователь творчеству современных татарских писателей. Примером такого изыскания является статья «Художественное изображение исторических вех в творчестве Роберта Минуллина» (2018). Статьи ученого помогают понять татарскую культуру не только татарскому читателю, но и любому читателю, ценящему литературу.

Научная и педагогическая работа Ф.Г. Галимуллина развивает татарскую культуру, создает базу для исторических и литературных исследований татарской литературы в контексте межкультурного и мультилингвального сообщества. Благодаря исследованиям ученого, татарские язык и литература занимают важное место в культуре народов Российской Федерации.

**Литература**

1. *Галимуллин Ф.Г.* Эзләнү вакыты. – Казан: Мәгариф, 2005. – 253 с.
2. *Галимуллин Ф.Г.* Офыкларны алдан күреп. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 200 с.
3. *Миннегулов Х.Й.* Ижади гамәлле шәхесләр: мәкаләләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. – 286 с.
4. *Галимуллин Ф.Г.* Художественное изображение исторических вех в творчестве Роберта Минуллина // Сборник материалов Международной науч.-практ. Конференции. – Казань: Артифакт. 2018. – С. 45–52.

**Г.Ф. Каюмова**
Казан федераль университеты, Казан

## ФОАТ ГАЛИМУЛЛИННЫҢ ЗАМАНЧА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕ ТӨЗҮДӘГЕ РОЛЕ

**Г.Ф. Каюмова**
Казанский федеральный университет, Казань

## РОЛЬ ФОАТА ГАЛИМУЛЛИНА В СОВЕРШЕНСТВОВАНИИ СОВРЕМЕННЫХ УЧЕБНИКОВ ПО ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ

**Аннотация.** В статье предпринята попытка осознания вклада известного татарского ученого-литературоведа Фоата Галимулловича Галимуллина в методику преподавания татарской литературы, в совершенствование содержания современных учебников. Известно, что к современному учебнику предъявляются определенные требования, которые перекликаются с введением в образовательную систему ФГОС. Одним из таких требований является направленность на формирование этнокультурной компетенции у обучающихся. Автор статьи приходит к выводу о том, что многие качества учебников, выпущенных при непосредственном участии Ф. Галимуллина – его авторстве, в его редакции – определенно направлены на формирование данной компетенции.

**Ключевые слова:** Ф. Галимуллин, учебник, татарская литература, литература родственных народов, национальное самосознание, диалог культур.

**Abstract.** The article attempts to estimate the contribution of the well-known Tatar scholar-literary critic, F.G. Galimullin in the methodology of teaching Tatar literature, in improving the content of modern textbooks. It is known that certain requirements are imposed on a modern textbook, which echo the introduction of

the Federal State Educational System into the educational system. One of these requirements is the focus on the formation of ethno-cultural competence among students. The author of the article comes to the conclusion that many of the qualities of textbooks published with the direct participation of F. Galimullin – its authorship, in its edition – are definitely aimed at the formation of this competence.

**Keywords.** F. Galimullin, textbook, Tatar literature, literature of related peoples, national identity, dialogue of cultures.

Фоат Галимуллинның фәнни эшчәнлеге, иҗатына күзәтү ясаучылар аның уку-укыту өлкәсенә, төгәлрәк әйткәндә, әдәбият укыту методикасына керткән өлешен дә ассызыклап китәләр. Мәсәлән, үзе дә галим, тәнкыйтьче, дәреслекләр авторы яки редколлегия әгъзасы булган, димәк, Ф.Галимуллин эшчәнлек күрсәткән өлкә белән яхшы таныш булган А.Әхмәдуллин болай яза: «Иҗади эшчәнлегенең тагын бер зур өлеше итеп Ф.Галимуллинның урта мәктәпләр өчен әдәбият дәреслекләре язуын күрсәтергә кирәк. Илебез үзгәртеп кору чорына кергәч, урта мәктәп программаларын да яңартып эшләү көн тәртибенә басты. Татар әдәбияты өчен 5–8 сыйныфлар өчен программалар, дәреслекләр язу һәм хрестоматияләр төзү, аларны башкарып чыгу өчен, авторлар коллективы туплау эше башланды. Профессорлар А. Әхмәдуллин, Ф. Галимуллин, Ф. Ганиева, М. Җәләлиева, И. Нуруллин, Х. Миңнегулов, Д. Сибгатуллина, Ф. Хатипов, М. Хәсәнов, Н. Юзиев һ. б.) авторлыкка тартылды. 2000 елда яңартылган программалар чыкты, 2001 елдан яңа дәреслекләр һәмхрестоматияләр басыла башлады. Бүгенгә инде алар төзәтелеп, беркадәр үзгәртелеп, дүртәрбишәр кат дөнья күрде. Бу зур һәм җаваплы эштә Ф.Галимуллин иң зур таяныч булды» [Әхмәдуллин, 2016: 124]. Чынлап та, шушы чорда басылып чыккан дәреслекләрдә Ф. Галимуллин аеруча әһәмияткә ия булган бүлекләргә күзәтүне укучыларның яшь үзенчәлекләренә ярашлы рәвештә җиткерүне тәэмин итә, атаклы әдипләребез иҗаты хакында мәгълүматның яңача, хакыйкатькә хилафлык китерелмичә бирелүен тәэмин итә. Берничә мисал гына китерик: 10 нчы сыйныф укучыларына атап төзелгән дәреслектә ул Г. Исхакый, Г. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Н. Думави, Һ. Такташ иҗатларына күзәтү тәкъдим итә, моннан кала аерымчорларга күзәтү дә аның тарафыннан башкарыла. 11нче сыйныф укучыларына атап төзелгән дәреслектә ул «40–50 нче еллар әдәбиятында Бөек Ватан сугышының чагылышы», «Балалар әдәбияты» дигән темаларга күзәтү ясый, Ф. Кәрим, Р. Мөхәммәдиев (А. Әхмәдуллин белән берлектә), Р. Миңнуллин, Ш. Галиев иҗатлары турында мәгълүмат бирә [Татарская виртуальная гимназия].

Гомумән, дәреслекләр өстендә эшләү осталыгы заманыбыз өчен иң актуальләрдән булуын ассызыкласак та ялгышмабыз, чөнки XX гасырның

соңгы дистә елларында – XXI гасырда мәгариф системасында, шулай ук, моңа бәйләнешле рәвештә уку-укыту методикасында үзгәрешләр җәһәт тизлек белән бардылар. Татар теле һәм татар әдәбиятын укытуда иҗтимагый-сәяси вәзгыять, полилингваль укыту шартлары белән бәйлелектә исә алар үзләрен аеруча нык сиздерделәр. Шуңа бәйлелектә XXI гасыр дәреслегенә куелган таләпләр элгәреге дәреслекләрдән аерылалар, әмма Ф.Галимуллин редакциясендә чыккан дәреслекләр дә иң күркәм традицияләр белән яңа заман таләпләре гаҗәеп рәвештә ярашып, бер-берсен тулыландырып, нәтиҗәдә, татар милли рухлы, әдәбиятны ихлас яраткан, аның белән кызыксынган, мөстәкыйль, тәнкыйди һәм иҗади фикерләргә сәләтле укучыны тәрбияләүне күздә тотып төзеләләр. 2016 елда Ф. Галимуллин редакциясендә һәм аның авторлыгында да басылып чыккан дәреслеккә күз салыйк. Мисал итеп рус мәктәпләрендә татар төркемнәрендә 11 нче сыйныфта укучыларга атап төзелгән дәреслекне алыйк. Бу – бик җаваплы хезмәт. Авторлар шуны истә тотып эшлиләр: 11 нче сыйныф – мәктәптә укуның соңгы, җаваплы чоры. Бер яктан, әдәбият дәреслеге төзү һәм аның буенча нәтиҗәле эшләүдәге авырлыкларның объектив сәбәбе бар: соңгы, димәк, сынаулы елда укучыларның бар егәре, куәте имтихан бирә торган предметларга юнәлтелә, имтиханнарны уңышлы тапшыру укучыларның якын киләчәктәге тормышын билгели. Укучыларның рус теле, рус әдәбияты, инглиз теле, математика кебек фәннәрне җигелеп уку, өстәмә дәресләр алуы шуның белән аңлатыла. Ни кызганыч, татар теле һәм әдәбиятының бу яктан таянычы зур түгел. Әмма шунысы куанычлы: үз исемен лаеклы йөртүче галим, үз һөнәренең остасы булган укытучы эшләгәндә, әдәбият дәресләренең укучы күңеле, аңында озак саклану омтылышы, ышанычы бар. Бу яктан Ф. Галимуллин дәреслекләренең кайбер уңышлы якларын ассызыкларгакирәк, дип уйлыйбыз. Шуларның беренчесе буларак, милли үзаң тәрбияләүгә юнәлгәнлекне атар идек. Әлбәттә, татар әдәбияты дәресләрен тәрбиянең әлеге аспектыннан гайре күз алдына китерүе авыр. Әмма төрле чорларда һәм хәзерге вакытта басылган аерым дәреслекләрне күзәтүебез дә шуны күрсәтә: кайбер очракларда дәреслек авторлары әдәбият дәресләрендә дә халыклар дуслыгы, рус, Көнбатыш Европа авторларының татарчага тәрҗемәдәге әсәрләрен укытуга игътибар бирәләр. Бу яктан тикшерелә торган дәреслектә аермалар бар. Мисал китерик. Дәреслек буенча «Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты» бүлеге өйрәнелә. Татар әдәбияты бу чорда ватанпәрвәрлек рухы белән сугарылган, гражданлык пафосы белән дә өртелгән, тирән лиризм белән дә сугарылган гүзәл әсәрләр белән байый. Әмма мөһиме шул: татар әдипләре батырлык һәм ватанга тугрылыкны үзләренең төп көче булган каләм белән генә түгел, корал белән дә дәлилилиләр: фронтта күпләгән каләм осталарының гомере өзелә, кайберләре мәңгелек яралар белән, Җиңү белән туган якларына кайталар. Дөресен әйтик:

Бөек Җиңүгә Россиянең керткән өлеше турында сөйләгәндә, татарларның батырлыгы аерым аталган очраклар еш күзәтелми; борынгыдан яугир булган, дәүләте өчен үзен аямыйча көрәшкән бабалар хәтере бу очракта да үзен күрсәтә: татарлар арасында каһарманнар саны бик күп була. Дәреслек авторларының укучыларга тәкъдим иткән сорауларына игътибар итик:

– «Бу сугыш безнең илебез өчен нинди сугыш була? Халык, шул исәптән, татарлар, аны ничек кабул итә?

– - Татарстанлылар сугышта нинди батырлыклар күрсәтә?

– Татар солдатлары турында күренекле язучы, публицист Илья Эренбург ниләр әйтә?

– Утыздан артык язучыбыз сугыш кырларында һәлак була. Сез алардан кемнәрне атый аласыз? Аларның нинди әсәрләрен укыгынагыз бар? Сезнең күңелләрдә аеруча кайсылары уелып калды?

– Фронтта татар телендә чыккан газеталарда эшләгән язучыларны әйтегез. Сез алар турында ниләр беләсез?» [Галимуллин, 2016: 6].

Аталган һәмбашка сорауларның дәреслектә урын алуы – заман таләбе буларак та аңлашыла, чөнки соңгы берничә дистә елда, бөтен дөньяга хас күренеш буларак милли мәдәнияткә җитди игътибарның артуы нәтиҗәсе буларак, уку-укытуда этномәдәни компетенциянең аерым бер планлаштырылган нәтиҗә буларак күрсәтелә. Әлбәттә, бу өлкәдә эш башка предметларны өйрәнүдә дә алып барыла, гәрчә тел һәм әдәбият дәресләрендә аның роле, тел һәм әдәбият дәресләренең этномәдәни компетенция формалаштырудагы потенциалы бермә-бер артык.

Дәреслекнең тагын бер уңышлы ягы – тугандаш халыклар әдәбиятына игътибар. Укучылар рус классиклары иҗаты, шулай ук Көнбатыш Европа әдипләренең иҗаты белән дә өлешчә таныш, әмма әйтик, Ф. Галимуллин редакциясендәге дәреслек авторлары тәкъдим итә торган Решат Нури Гүнтекинның (төрек язучысы) «Чалы кошы» классик әсәре (илебез җәмәгатьчелегенә «Королек – птичка певчая» фильмы буенча яхшы таныш) югары сыйныф укучыларына беренче мәртәбә тәкъдим ителә. Алай гына да түгел, дәреслек авторлары кайбер башка төрек язучыларының әсәрләрен укып, алар буенча да әңгәмә корырга тәкъдим итәләр[Галимуллин, 2016: 337]. Искәртеп китик: әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителгән төрек язучылары күп түгел, әмма бу әңгәмәне рус теленә тәрҗемәдә укылган әсәрләр буенча да оештырырга була. Әйтик, Орхан Памукның «Минем исемем Кызыл», «Истанбул. Хатирәләр шәһәре» әсәрләре буенча әңгәмәләр корырга мөмкин. Мондый эшнең әһәмияте бик зур: беренчедән, икътисади яктан Төркия белән илебез арасындагы багланышлар шактый тыгыз, ә бу мәдәниятара диалогны да күздә тота. Бер-береңнең мәдәниятен, шул исәптән әдәбиятын тану, аңлау мөнәсәбәтләрнең уңай тотрыклылыгын

тәэмин итә торган шартларның берсе булып тора. Икенчедән, кызыксынган укучылар киләчәктә төрек язучыларының әсәрләрен татар теленә һәм киресенчә, татар әдипләре әсәрләренең төрек теленә тәрҗемә итүгә өлеш кертмәс дип тә әйтеп булмый.

Төрек-татар мәдәниятләренең диалогын тәэмин итүдә Ф. Галимуллин редакциясендәге дәреслекләре зур өлеш кертә. Гомумән, галимнең татар укучысын яңа әдипләр белән таныштырудагы роле моның белән чикләнми, киресенчә, бу – күркәм традициянең бер чагылышы буларак та карала ала. А. Әхмәдуллин язганча, «исеме һәм иҗаты әйләнеп кайткач, Г. Исхакый әсәрләрен мәктәп дәреслегенә кертүне дә нәкъ менә ул – Фоат Галимуллин башкарды» [Әхмәдуллин, 2016: 124].

Ф. Галимуллинның методика өлкәсендәге эшчәнлегендәге тагын бер аспектка игътибар итәсем килә. Ул татарча саф, төзек, сәнгатьле сөйләмгә игътибарлы һәм таләпчән шәхес буларак билгеле. «Укытучы сөйләме аеруча күз алдында. Ул дәрес буе яңгырап тора. Әгәр дә ул сөйләм культурасына, төгәллеккә ия икән, бу укучы өчен бәя биреп бетергесез файдалы чыганак, охшарга тырышу күренеше. Укытучыга укучы тулысынча ышана. Укытучы әйткәч, укыгач, дөрес дип карый, күңеленә шик-шөбһә килми. Димәк, культуралы сөйләмгә һәмсәнгатьле уку күнекмәләренә ия булмаган укытучы балаларның тел үсешенә никадәр зыян китерергә мөмкин», – дип яза ул хаклы рәвештә [Галимуллин, 1984: 6–7]. Бу сүзләрнең кыйммәте бүген һич тә кимеми.

Мәкаләмә йомгак ясап, шуны да ассызыклап китүне урынлы саныйм: Фоат Галимуллин минем өчен танылган галим, гаҗәеп киңкырлы офыкка ия булган әдәбият белгече генә түгел, ул миңа остазым, фәнни җитәкчем, якташым буларак та якын. Миң аңа алга таба да фәнни уңышлар телим, аның башкарган эшләре белән соклануымны белдерәм. Фәндә объективлык, аналитик фикер йөртү кыйммәтле сыйфатлардан санала, Ф. Галимуллинда бу сыйфатлар әдәбиятка һәм шул әдәбиятны биргән милләткә тирән мәхәббәт белән тулыланалар. Мәктәп укучыларын беренчеләрдән булып Г. Исхакый иҗаты белән таныштыруга ирешкән галим бүген дә заман сулышын сизгер тоя, бүгенге укучыларны тугандаш халыклар мәдәнияте белән танышуга тартуның, милли үзаң үсешенең әһәмиятен яхшы аңлап эш итә икән, мин остазыма хәерле гомерләр телим.

**Әдәбият**

1. *Әхмәдуллина А.* Киң карашлы галим һәм җәмгать эшлеклесе. – Казан утлары. – 2016. – № 3. – Б. 122–124.

2. *Галимуллин Ф.Г.* Татар әдәбияты. 11 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче

укучылар өчен) / Ф.Г. Галимуллин, Л.И. Минһаҗева, Л.К. Хисмәтова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 359 б.

3. *Галимуллин Ф.Г.* Мәктәптә сәнгатьле уку. – Казан: КДПИ, 1984. – 101 б.

4. Татарская виртуальная гимназия. – URL: https://tatar.org.ru; мтьитү вакыты: 24.02.2021.

**З.Н. Кириллова**
Казан федераль университеты, Казан

## КУПРИН ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРЖЕМӘЛӘРЕНДӘ ГРАММАТИК ТРАНСФОРМАЦИЯЛӘР

**З.Н. Кириллова**
Казанский федеральный университет, Казань

## ГРАММАТИЧЕСКИЕ ТРАНСФОРМАЦИИ В ПЕРЕВОДАХ ПРОИЗВЕДЕНИЙ КУПРИНА НА ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

**Аннотация.** Данная работа посвящена исследованию грамматических трансформаций в переводах на татарский язык произведений известного русского писателя А.И. Куприна. Источниками были выбраны рассказы «Слон», «Детский сад», «Собачье счастье» и их переводы, выполненные Раисом Даутовым. В результате исследования выделены трансформации, связанные с морфологическими и синтаксическими особенностями разноструктурных языков.

**Ключевые слова:** литературный перевод, татарский язык, трансформации, грамматические трансформации, рассказы А.И. Куприна.

**Abstract.** This work is devoted to the study of grammatical transformations in translations of the works of the famous Russian writer A.I. Kuprin into the Tatar language. The selected sources are the stories “Elephant”, “Kindergarten”, “Dog Happiness” and their translations made by Rais Dautov. As a result of the study, transformations related to the morphological and syntactic features of differential languages have been identified.

**Keywords:** literary translation, Tatar language, transformations, grammatical transformations, stories by A.I. Kuprin.

Татар һәм рус телләре лексик-семантик яктан гына түгел, грамматикасы белән дә бер-берсеннән нык аерыла, шуңа күрә тәрҗемә барышында сүзләрнең грамматик төзелешен үзгәртергә һәм грамматик трансформацияләрне кулланырга туры килә.

А.И. Куприн хикәяләрен татар теленә тәрҗемә иткәндә барлыкка килгән грамматик трансформацияләрне тикшерү өчен, хезмәттә чыганак итеп «Балалар бакчасы», «Фил» һәм «Эт бәхете» әсәрләренең Р. Даутов тарафыннан башкарылган тәрҗемәләре алынды.

Тәрҗемәче ике телнең үзенчәлекләрен тоеп, белеп эшләгәндә, трансформацияләр урынлы һәм төгәл булып чыга. Тәрҗемә трансформацияләренә оригинал тел берәмлекләренә турыдан-туры тәңгәллекләр табып булмаганда мөрәҗәгать ителә. Әдәби текстны тәрҗемә иткәндә, тәрҗемәче каршында текстның эмоциональ яңгырашын саклау бурычы тора.

Билгеле булганча, татар теле белән рус теле арасындагы морфологик аермалар, нигездә, исем һәм фигыль сүз төркемнәре өлкәсенә карый. Мәсәлән, татар һәм рус телендә исем сүз төркемендә сан категориясе белән бәйле аермалыклар күзәтелә. Татар теле исемнәре арасында, күплек мәгънәсен белдереп тә, берлек формасында йөри торганнары да бар. Аларның рус телендәге эквивалентларын тәрҗемә иткәндә, дөрес лексема сайлап алырга кирәк була. Мәсәлән, легкие – үпкә, слезы – күз яше, санки – чана, часы – сәгать һ. б. Рус телендә андый сүзләр күплек санда булса да, татар теленә тәрҗемә иткәндә, аларны берлек формасында бирү дөрес була. Шулай ук бу күренешнең киресе дә күзәтелә. А.И. Куприн хикәяләрендә мондый мисаллар шактый табылды: *Среди шума и кипучего движения большого города она напоминала те **чахлые травинки**, которые вырастают – бог весть каким образом – в расщелинах **старых каменных построек.** (Детский сад) Зур шәһәрнең кайнап торган шаушулы, ыгы-зыгылы тормышында ул **иске таш йорт** стенасы ярыкларына, – алла белсен, нинди юл беләндер, – кысылып үскән ниндидер **зәгыйфь үләнне** хәтерләтә иде. (Балалар бакчасы).* Әлеге җөмләдә без рус телендә күплек сан формасында килгән исемнәрнең татар телендә берлек санда бирелүен күрәбез. Беренче очракта бу кабатлаулардан котылу өчен кирәк булса (иске таш корылмалар стеналары ярыкларына дию гә караганда, иске таш йорт стенасы ярыклары дип әйтү, һичшиксез, матуррак яңгырый), икенче очракта кызның нәкъ менә ялгыз үлән белән чагыштырылуы автор фикерен бирергә, текстның эмоциональ яңгырашын саклап калырга мөмкинлек бирә.

Алдагы мисалда исем сүз төркеменә кагылышлы трансформацияләр сан кушымчаларына карый: *Но старый **портвейн и – 18 рублей и 33 1/3 копеек** жалованья... (Детский сад) – Ләкин **утыз өч тәңкә ярым** жалунья белән ниндидер **унсигез тәңкәлек портвейннар** сатып алырга – монысы инде... (Балалар бакчасы).* Әлеге җөмләдә портвейн сүзе татарчага портвейннар дип тәрҗемә ителгән, бу – татар телендәге, исемнәргә күплек кушымчасы кушып, эмоциональлекне арттыру үзенчәлеге белән бәйле. Ә рус телендә күплектәге исемнәрнең берлек санда бирелүе татар телендә саналмышларның грамматик үзенчәлегенә кайтып кала.

Шулай ук русларда билгеле бер күренешләрне, бигрәк тә табигатькә караган әйберләрне, иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялгап әйтү хас, ә татар телендә бу матур яңгырамаска мөмкин, чөнки кушымчаның кечерәйтү функциясе алгы плангарак чыга. Р. Даутов тәрҗемәсендә дә оригинал тексттагы иркәләү-кечерәйтү кушымчасы алган исемнәрне гади формада тәрҗемә итү очрый: *Там... **листики** зелененькие**...** **травка...** как у крестной **в садике**... (Детский сад) – Анда яшел **яфраклар**... **чирәм** үсә... Кодагый әбиләр **бакчасындагы** кебек. (Балалар бакчасы). Хочешь, я посажу к тебе на **постельку** всех твоих кукол. Мы поставим **креслица,** диван, **столик** и чайный прибор. (...) А может быть, позвать к тебе Катю или **Женечку?** (...) Хочешь, я тебе принесу **шоколадку**? (Слон) – Телисеңме, мин сиңа монда, **караватыңа**, барлык уенчыкларыңны алып киләм. Без синең белән монда **кечкенә кәнәфи,** диван куярбыз, **бәләкәй өстәлгә** чәй табыны әзерләрбез. (...) Бәлкем, синең янга Катя белән **Женяны** чакырыргадыр? (...) Телисеңме, мин сиңа **шоколад** алып киләм. (Фил)*

Татар телендә исемнәргә хас булган мөһим категория – тартым категориясе. Рус телендә предметның нинди дә булса затка караганлыгы алмашлыклар ярдәмендә белдерелә, татар телендә исә бу функцияне, алмашлыклардан тыш, тартым кушымчалары башкара. Рус телендәге текстларны тәрҗемә иткәндә, гадәттә, тартым алмашлыклары төшереп калдырыла. Р. Даутов тәрҗемәсендә дә бу шулай*: Я, конечно, надеюсь, что **моя девочка** выздоровеет. (Слон) Мин, әлбәттә, **кызым** терелер дип өмет итәм. (Фил)*

Сыйфатлар өлкәсендә аермалыклар күп түгел. Бер мисал гына карап китик: *Бурмин старался согреть поцелуями ее **худенькие, холодные руки** (Детский сад) – Бурмин аның ябык, **нәзек, салкын кулларын** үбеп җылытырга тырышты. (Балалар бакчасы*). Тәрҗемәдә ябык, нәзек синонимнарын куллану сурәтләүнең тәэсирлелеген арттырган, образларның кызганыч халәте, геройның хәсрәтле күңел кичерешләре бик төгәл ачылган.

Рус һәм татар телләрендә фигыльләрнең дә төрле булуы ачык күренә. Бу фигыль заманнарында да ачык күренә. Мәсәлән, рус телендә үткән заман хикәя фигыль бер генә форма белән белдерелә. Ә татар телендә аның биш формасы бар. Тәрҗемәче әнә шуларның барысының да мәгънә үзенчәлекләрен белеп, рус текстындагы мәгънәгә туры килерлеген сайлап ала белергә тиеш. Р. Даутов тәрҗемәсендә бу эш уңышлы килеп чыккан, фигыль заманнары төгәл бирелгән, бу грамматик трансформацияләр хисабына да башкарылган. Мәсәлән: *Илья Самойлович Бурмин **служил** старшим писцом в сиротском суде. (Детский сад) – Илья Самойлович Бурмин ятимнәр судында өлкән писер булып **эшли иде.** (Балалар бакчасы)*

Тәрҗемә текстында синтаксис өлкәсендә үзгәрешләр, синтаксик трансформацияләр шактый. Бу аңлашыла да, чөнки татар һәм рус телләренең синтаксик

системасы үзгә. Мәсәлән, түбәндәге мисалда оригиналда исем белән белдерелгән ия тәрҗемәдә исем фигыль белән алыштырыла: *Поймите же, что ваша* ***дочка*** *больна равнодушием к жизни, и больше ничем... (Слон) – Аңлагыз шуны: аның бөтен* ***авыруы*** *– тормыштан кызык тапмауда… (Фил)*

Бер составлы җөмләләрне ике составлы белән бирү очраклары күп. Мәсәлән: *Нет, мама, ничего не хочется. (Слон) – Юк, әнием, миңа берни дә кирәкми. (Фил) Но девочка тут же вспоминает о вчерашнем и спрашивает: – А слон? (Слон) – Ләкин кызчык шундук кичәге хәлләрне исенә төшерә дә: – Ә фил кайда? – дип сорый. (Фил)* Алдагы мисалда исә рус телендәге ике составлы җөмлә Р. Даутов тарафыннан бер составлы итеп үзгәртелгән: *Я в седьмой раз туда еду. (Собачье счастье) – Минем инде анда җиденче тапкыр баруым! (Эт бәхете)*

А.И. Куприн хикәяләрен татар теленә тәрҗемә иткәндә, шундый үзенчәлек тә күзгә ташлана: аларда төрле җөмлә кисәкләрен өстәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән грамматик трансформацияләр бик күп очрый. Р. Даутов төрле җөмләләрдә теге яки бу иярчен кисәкләрне өстәп кертеп җибәрә: *После этой вспышки наступило напряженное и печальное молчание. (Собачье счастье) –* ***Кыска*** *бу ярсудан соң* ***тимер читлектә яңадан*** *киеренке һәм моңсу бер тынлык урнашты. (Эт бәхете) Хочешь конфетку с картинкой? Яблочко? Башмачки желтые? (Детский сад) – Рәсемле конфет алып кайтыйммы әллә?* ***Бәлки,*** *алма* ***кирәктер****? Сары* ***күн*** *башмаклар* ***булса ничек****? (Балалар бакчасы).* Әлеге җөмләләрдән күренгәнчә, өстәлгән җөмлә кисәкләре эчтәлеккә зыян китерми, киресенчә, алар текст вакыйгаларына төгәллек кертергә, эмоциональ-экспрессив үзенчәлекләрне сакларга мөмкинлек бирә. Шунлыктан мондый грамматик трансформацияләрне уңышлы дип саный алабыз.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, тәрҗемәдә грамматик трансформацияләр шактый күп. Тәрҗемәче грамматик категорияләрне үзгәртергә (иркәләү-кечерәйтү кушымчаларын төшереп калдырырга, күплек сандагы исемнәрне берлек санда бирергә һәм, киресенчә, тартым алмашлыкларын төшереп калдырырга һ. б.), җөмлә төзелешен башкачарак итәргә мөмкин. Бу грамматик трансформацияләрнең берсе дә текстның образлылыгына зыян китермәгән. Гомумән, хикәяләрнең тәрҗемәләре рус телендәге текстка эчтәлеге белән дә, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан да тәңгәл.

### Әдәбият

1. *Куприн А.И.* Повесть һәм хикәяләр / Р. Даутов тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. – 283 б.

2. *Куприн А.И.* Рассказы. – М.: Правда, 1983. – 512 с.

**З.К. Ктайбекова**
Ажиниёз номидаги Нукус давлат педагогика институти, Нукус

# Г.ТУРСИНОВА ҲИКОЯЛАРИДА МУАЛЛИФ ВА ҲИКОЯЧИ ОБРАЗИ

**З.К. Ктайбекова**
Нукусский государственный педагогический
институт имени Ажинияза, Нукус

# ОБРАЗ АВТОРА И РАССКАЗЧИКА В РАССКАЗАХ Г. ТУРСЫНОВА

**Аннотация.** В статье рассматривается образ автора и рассказчика в каракалпакских рассказах на примере рассказов известного писателя Г. Турсинова. Рассказчик в произведении искусства – это особый человек, который рассказывает историю, а слово автора – это повествование и интерпретация автора, которые отличаются от слов главных героев в произведении. В рассказах анализируется, была ли жертва женщиной, ребенком, школьницей, сестрой старухи или автором.

**Ключевые слова:** рассказ, образ автора, образ рассказчика, сюжет, содержание, творческая позиция.

**Abstract.**The article analyzes the image of the author and narrator in Karakalpak stories.It is studied on the example of the stories of the famous writer G. Tursinov. The narrator in a work of art is a special person who tells the story,and the word of the author is the narration and interpretation of the author, which differs from the words of the protagonists in the work.In the stories it is analyzed whether the victim was a woman, a child, a schoolgirl, an old woman's sister, or the author.

**Keywords:** story, author’s image, narrator’s image, plot, content, creative position.

Қорақалпоқ ҳикояларининг ривожланишида асосий сюжетмазмунини қизиқарли ҳодисаларни маҳорат билан баёнлаб берадиган ҳикоячи образи алоҳида кўзга ташланади. Ушбу баъзан муаллиф бўлиб,баъзан алоҳидаҳикоячи бир қария сифатида, баъзан ёзувчнинг моҳирлилига мос ҳикоячи она ёки сулув келинчак, гўзал қиз, жабрланган аёл, ёҳуд ёш йигит, азобланган норасида бўлиб, чуқурҳаётий ҳодисаларни ёритиб, кўз олдимизда гавдаланади. Булар қорақалпоқ ҳикоячилигидақадмдан келаётган анъанавий тасвирлашнинг бир кўринишин белгилайди. Ҳозирги даврдаги ҳикоя жанрининг ривожланишида муаллиф

ва ҳикоячи образининганча такомиллашган, унинг ҳархил усулларда, сюжет воқеалар тизмасида, муайян вақт ичида, давр ҳақиқатлигининг тасвирланишида турли кўринишлардаюзага келвётганлигин кўриш мумкин.

Ҳикоячи образи – бадиий асарда воқеаларни ҳикоя этувчи махсус шахс. «Ҳикоя жанрининг ўзига хослиги, сюжет характерида, муаллиф сўзида, ҳикоячи тилида, бадиий деталларда акс эттирилади» [Сойфер,1976: 300].

Бадиий асарда қаҳрамонлар сўзидан фарқланувчи муаллифнинг баён қилиши ва тушунтириши, муаллиф сўзи ёрдамида кўпинча сюжет экспозицияси, пейзаж тасвирлашлар ва образларнинг психологик ҳолатлариифодаланади. Кўпгина ёзувчилар ўз асарларини бевосита муаллиф сўзи билан бошлайди [Ҳотамов, Саримсақов, 1979: 20].

Адабиётшуносликда ҳикоячи тушунчаси бадиий асар таҳлилида муҳим ўринни эгаллайди. Чунки қайси шахс томонидан айтилмасин, ҳаётий воқеаларни эстетик жиҳатдан баҳолашда ҳикоячи ва ижодкор позицияси бир-бирига жуда яқин келади ва ва бирлашиб кетади. Умуман олганда, бадиий асарни икки хил: 1) Махсус ҳикоячининг баён қилиш асосида. Бунда ҳикоячи персонаждан бўлиши мумкин. Айрим ҳикоячи асар воқеаларида қатнашмайдиган, бироқ у ёки бу тарихини билувчи ва ҳикоя қилиб берувчи шахс сифатида ҳам гавдаланади. 2) Асар воқеалари нейтрал шаклда тасвирланади. Бундай ҳолатда баён этиш номаълум бир одамнинг гаплари асосида олиб борилади [Ҳотамов, Саримсақов, 1979: 251]. Шунингдек «муаллиф ҳикоячини ўзининг таниши, тасодифан учрашган таниши, нотаниш одам, ушбу воқеани бошқа бировдан эшитган, ўзи биладиган сирни узоқ йиллар сақлаб келган гувоҳ, муаллифни «яхши» ёки «ёмон одам» этиб кўрсатувчи йилномачи, стенограф, хроникер, ном қўшувчи ва ҳ. к. қила олади» [Есембеков, 2012: 76].

Г. Турсинованинг «Афсонага айланган қишлоғим» номли повесть ваҳикоялари тўпламидаги «Энг бебаҳо совға», «Сеҳрли қамчи», «Кундаликнингёзилиш тарихи» ҳикояларида воқеалар жабрдийда аёл, ёш бола, мактабўқувчиси, кампир опасининг тилидан ёҳуд муаллиф томонидан сўз қилинади. Масалан, «Оқсоқол» ҳикоясида ўз фарзандидан зулм кўрган она қишлоқ оқсоқолини излаб келиб, нотаниш одам билан танишади ва бошидан кечган турмушвоқеаларининиайтиб беради [Турсынова, 1997].

Ҳикояда бир оиланинг аянчли тақдири, она билан фарзандорасидаги турмушвоқеалари тасвирланади. Турмуш ташвиши билан оқсоқолни излаб келган аёл ўз қизининг мол-дунё, бойлик учун онасини судга бериб, урди дебтуҳмат қилиши, қизинингушбу ифлосликларигатоқат қила олмасдан, юраги тошга айланган она ўзинггуноҳсиз эканлигини исботлаш учун шуқишлоқ оқсоқалидан ёрдам сўраб келганлигининотаниш одамга гапириб беради. Ҳикоя якунидаушбу аёл тақдирига ачинганнотаниш одам ҳамқишлоқ оқсоқалининг олдига бориб,

ундан яхшисўз ола олмаганлигига ўкинчи баён килинган. Ҳикояда оддий аёл билан фарзанди, қуда – анда орасидагизиддиятларниеча олмай, ишни судга оширган, халқ тақдириниуйламайдиган айрим раҳбарлар билан узоқга бора алмайдиганлиги – ачинарлиҳолат эканлиги ёзувчи томонидан маҳорат билан ифодланган.

Ёзувчининг «Гуноҳкор»ҳикояси сут сотиб келган сотувчи кампир билан қаридор диалогидан бошланади. Ҳикояда кампир ўзинингҳаётидаги кечинмаларни баён қилади.Қартайганчоғида роҳат-фароғатда яшайман дебкамолга келтирган фарзандининг аёли билан ҳар куни айши-ишрат қилиб, ичувчиликга берилгани оқибатида, сут сотиб невараларини боқиб, кун кўраётганлигини, ушбу воқеаларга айбдор ўзи эканлигини, боласига қишлоқ қизини олиб берса ҳам, уларнинг ҳар куни меҳмонга кетишларини тўхтата олмай, қайтанига келинини ҳам қўшиб юборганига ўкинчиниқаридоргакўзига ёш олиб айтиб беради. Муаллиф бу ҳикояда ёш оила аъзоларинингўз онасининг топгани билан кун кечираётганининг аянчлиҳолатэканлигинитасвирлаб, жамиятимизда бунақа ёшларнинг мавжуд эканлигини танқидқилиб, шунақа вазиятларнингбўлиши, албатда, кимни бўлса ҳамўйландирадиган масала эканлигини айтмоқчи бўлган [Турсынова, 1993].

Г. Турсинованинг «Энг бебаҳо совға» ҳикоясидаги воқеалар талабалар ҳаётидан олиб ёзилган. Ҳикояда опасининг туғилган кунига совға юборган сингилнинг совғаси барча совғалардан ҳам энг яхши бебаҳо совға бўлганлиги муаллиф тилидан баёнланади. Ушбу совға бешинши синфда ўқиётган синглисининг солган расми, яъни туғилган қишлоғининггўзал манзараси тасвирланган расм эди. Расм билан опасини қутлаб, мактуб ҳамёзибюборган. Мактубда опасининг ўзи совғақилган буёқлари билан туғилган қишлоғининг баҳордаги ажойиб манзарасини тасвирлаганини, дарахтларнинг яшиллибосда, боғларнинг гуллаб яшнаётганлигини айтади ва ўз меҳнати билан солган расмини юбораётганини келтириб ўтади [Турсынова, 1996: 4]. Албатта, қишлоқдан узоқда, Москвада ўқийдиган инсонлар учун бундан яхшисовға бўлмаса керак.

«Сеҳрли қамчи» ҳикоясиданевара қизи билан, йўлга чиқган кампир опасининг тилидан Қизил қум бағридаги сурув-сурув қўйларни боқган чўпонлар ҳақидаги эртак баён қилинади. Ҳикояда Қизилқум томондаги тоғасинин гуйига меҳмонга бораётиб бувисиневарасига «Сеҳрли қамчи»эртагини айтиб беради. Эртакдабўрилар подшоҳи томонидан чўпон болага берилган совға “сеҳрли қамчи” ҳақида сўз қилинади. Эртакдан таъсирланган неварасининг катта одамлардек фикр юритиб, экологик офатчиликга қаршикурашдаги, Орол билан Амуни сувга тўлдириб, эл-халқ обод қилинса, элдан кўчиб кетмаслиги ниятини бажариш учун бувисидан шу қамчини сўрайди. Бувиси унга:«-Ҳа қизим, бу офатдан қутқаришгабутун дунё ҳаракат қилади. Бутун дунё халқи ҳаракатқилса,

биз ҳеч нарсадан қўрқмаймиз» [Турсынова,1996: 10], – деган гапларибилан ҳикоя якунланади.

Муаллиф бу ҳикоя орқалиэлимиздаги асосий муаммо экологик офатчиликдан эл-халқни қутқазиш масаласиникўтариб, ҳар бир инсоннинг, у майли ёши катта, майли ёши кичик бўлсин, эл-йўрти учун бошини оғритиши кераклигини сўз қилмоқчи бўлганлигини англаймиз.

«Кундаликнинг ёзилиш тарихи» ҳикоясида мактаб турмушидагивоқеалар, таълим – тарбия масалалари сўз қилинади [Турсынова, 1996: 5]. Ҳикоя раиснинг боласи, тентак Мақсаднинг эсга туширишлари асосида баёнланади. Мактабгашаҳар спорт залининг футбол бўйича ўргатувчиси вақтча муаллим бўлиб келиб, дарс бера бошлайди. Дарслардан ёмон ўқийдиган Мақсад шуянгиликга интилувчан муаллим – Полвониёз Аметовнинг таъсирида спортда ҳам аъло, билимда ҳам иқтидорли бўлиши натижасидаўзининг синфраҳбарининг Пердебай Қалимбетовни танқидга олади. Натижадасинфраҳбариўз аризаси билан ишдан кетади. Бу ўринда ёш боланинг, айниқса, билимдон, спортда ҳам аълочи бўлган ўқувчининг ўз устозига бунақа қўпол муносабатда бўлиши ишончсизроқ тасвирланган. Ёзувчиушбуҳикоячи орқали жамиятимиздаги айрим ўқитувчиларнинг ўз вазифасига лоқайд қарайдиганлиги танқидга олишни мақсадқилган.

Хулоса қилиб айтганда, Г. Турсинова асарлари, жумладан, ҳикояларида муаллиф ва ҳикоячи образинитадқиқ қилиш қорақалпоқ адабиётида ҳали ҳам тадқиқ қилинишини кутиб турган долзарб масалалардан бири.

**Адабиёт**

1. *Сойфер М.И.* Мастерство Шолохова. – Ташкент: Литература и искусство, 1976.

2. *Ҳотамов Н., Саримсақов Б.* Адабиётшунослик терминларининг русча-ўзбекча изоҳли луғати. – Тошкент: Ўқитувчи, 1979.

3. *Есембеков У.Т.* Көркем мәтін поэтикасы. – Алматы: Қазақ университети, 2012.

4. *Турсынова Г.* Аңызға айланған аўылым. Повесть ҳәм гүрриңлер. – Нөкис: «Қарақалпақстан, 1996.

5. *Турсынова Г.* Ақсақал. /«Еркин Қарақалпақстан». – Нөкис, 1997, 12-август.

6. *Турсынова Г.* Гүнәкар. /«Еркин Қарақалпақстан». – Нөкис, 1993, 30-январь.

**М.М. Курбанова**
DSc, профессор
Национальный университет Узбекистана
имени Мирзо Улугбека, Ташкент
**Н.А. Садуллаева**
DSc, доцент
Национальный университет Узбекистана
имени Мирзо Улугбека, Ташкент

## ЙИҒИҚ ГАПЛАРНИНГ ДИСКУРСДА ҚЎЛЛАНИЛИШИ ВА МАВҚЕИ

## РОЛЬ И СТАТУС НЕРАСПРОСТРАНЕННОГО ПРЕДЛОЖЕНИЯ В ДИСКУРСЕ

**Аннотация.** В этой статье рассмотрены нераспространенные предложения в формальном и субстанциальном направлении. Был также сформирован комплекс формальных, семантических и структурных критериев, необходимый для определения статуса речевых конструкций, обладающих свойствами нераспространенности и распространенности, и рассмотрена проблема разделения исследуемых конструкций на определенные группы. Освещены причины и следствия активизации исследуемых структур в условиях дискурса и в различных речевых ситуациях. Исследованы различные виды дистрибуции состава текста данных предложений писателей, а также с какой целью их размещают.

**Ключевые слова:** нераспространенные предложения, формальное и субстанциальное языкознание, речевая конструкция, распространенное предложение, дискурс, дистрибуция.

**Abstract.** This article examines unextended sentences in a formal and substantial direction, a set of formal, semantic and structural criteria, which is necessary to determine the status of speech structures with the extended and unextended units, and the problem of dividing the structures into certain groups. The reasons and consequences of the activation of the studied structures in the conditions of discourse are highlighted. The text distribution of the sentences and the purpose of writers are investigated.

**Keywords:** unextended sentences, formal and substantial linguistics, speech construction, extended sentence, discourse, distribution.

**Кириш.** Инсонлар бир-бирлари билан мулоқотда бўлганида турли лисоний воситалар – сўз, иборалар, гаплар ва уларнинг вариантларидан фойдаланади. Буларнинг ҳар бирини ишлатаётганда, табиийки, ёзувчи ва шоирлар умуман,

сўзловчилар ўз мақсадларига мослаштиришга ҳаракат қиладилар. Маълумки, фикрни шакллантирувчи синтактик қурилмалар мазмун доирасини кенгайтириш имкониятлари чексиз ҳамда буларга қуйидагиларни киритиш мумкин: модал сўзлар, киритмалар, уюшган, ажратилган бўлаклар ва бошқалар. Санаб ўтилган бирликлар лисон нутқ дихотомиясида алоҳида мавқега эга. Модаллар гап кенгайтирувчи мақомида бўлса, уюшган, ажратилган бўлаклар гапнинг қайси бўлаги ажратилиб ёки уюшиб келаётганига қараб ё гап кенгайтирувчиси, ё сўз кенгайтирувчиси мақомида бўлади [1]. Кузатишларимиздан маълум бўлмоқдаки, ушбу мақоламизнинг тадқиқ объекти бўлган бирликлар дискурсда жуда катта прагматик «юк» ни ташийди ва бундай бирликлар нутқнинг прагматик хусусиятларини очиб беришда тенгсиз имконият касб этади [2]. Шу боис бу каби кейинги йилларда ўзбек тилшунослигида турли аспектларда, жумладан, инглиз ва турк тилларига қиёсан ҳам ўрганилмоқда [3].

**Асосий қисм.** Ёйиқ гап таркибидан кенгайтирувчи бирликларни биринкетин олиб ташлаб, уни минимал ҳолда, яъни бир ёки икки сўздан иборат тарзда қолдириш ҳам мумкин. Албатта, бундай ҳолда унинг тузилиши ўзгаради ва мазмун доираси тораяди. У йиғиқ ёки тўлиқсиз гап бўлиши мумкин: *У рўмолининг учини юзига босганча ҳиқ-ҳиқ йиғлар эди.* (Ў. Ҳошимов)

1. *[У] Рўмолининг учини юзига босганча ҳиқ-ҳиқ йиғлар эди;*
2. *[У] [Рўмолининг учини] Юзига босганча ҳиқ-ҳиқ йиғлар эди;*
3. *[У] [Рўмолининг учини] [Юзига босганча] ҳиқ-ҳиқ йиғлар эди;*
4. *[У] [Рўмолининг учини] [Юзига босганча] [ҳиқ-ҳиқ] йиғлар эди.*

Биринчи мисолдаги "*йиғлар эди*" шакли содда гап кесими вазифасини бажармоқда.

Ушбу тузилманинг яна бир матнда фаоллашуви ҳолатини кузатамиз: *«Дарахтга суяниб бир қизча турарди. Оёқлари олдида нимадир думалаб ётар. Унинг нималигини узоқдан кўролмадим. Бу қизча ўша нарсага қараб қўярди. Қизчанинг кулгиси ҳам, йиғиси ҳам эшитилмас. Бир ўзи нима қилиб турибди, кимни кутмоқда ё адашганми? деган хаёл билан ёнига бордим. Елкалари силкинар, совқотган бўлса керак... У йиғлар эди».* Бу матнда *йиғлар эди* бирлигига қандай ёндашиш лозим?! Агарда анъанавий тилшунослик ақидаларига амал қиладиган бўлсак, ушбу бирликни йиғиқ, баъзан тўлиқсиз гаплар қаторига киритган бўлар эдик. «Назарий грамматика» муаллифлари таъбирича, «Тилшуносликдаги мантиқий йўналиш назариясига мувофиқ, ҳукмнинг икки асосий аъзоси бўлган субъект ва предикатга икки бош бўлак – эга ва кесим мувофиқ келади. Улар бир-бирини ўзаро тўлдиради. Улардан бири иштирок этмаса, гап тўлиқсиз бўлиб қолади» [4:65] Демак, шу каби фикрларга асосланилса, «*У йиғлар эди*» гапидаги бирор бўлак тушиб қолса, тўлиқсиз гапга айланади. Бу ҳолатда шу икки бирликлардан қайсиси тўлиқсиз гап: *Йиғлар эди* ёки *У*? Назаримизда, улардан бироргаси ҳам тўлиқсиз гап эмас, чунки бу гапларда ҳеч қайси бўлак тагмаъннода яширинган

эмас. Бу гап матндан ташқарида қандай мазмун ифодаласа, матндан кейин қўлланганда ҳам шу мазмунга эга бўлиб қолади.

Биргина мана шу мисол йиғиқ гапнинг борлиқ воқеа-ҳодисаларини ифодалашда ёйиқ гапдек кенг имкониятларга эга эмаслигини кўрсатиб турибди. Аммо йиғиқ гапнинг ўзига хос хусусиятлари борки, улардан қаламкашлар унумли фойдаланишга ҳаракат қилганлар ва қилмоқдалар.

Ўзбек ва инглиз тилларида йиғиқ ва тўлиқсиз бирликларнинг ўзаро ўхшаш, фарқли томонлари қиёсан ўрганилмаган бўлса-да, умумий маълумотлар мавжуд, аммо уларнинг дискурсив фаоллашуви масаласи очиқ қолмоқда [5:85]. Худди шунингдек, бу бирликларнинг турли услубларда қўлланилиши ҳақида ҳам ҳеч қандай тадқиқот олиб борилмаган.

Дастлаб, бу икки бирликнинг публицистик асарларда ишлатилишига аҳамият берилди. Олдинги даврда бўлган ёки ҳозирги воқеалардан бирини тасвирлаш учун ёзувчи, одатда, рўй берганларнинг кетма-кетлигига риоя қилади. «*Чўлпоннинг айби йўқ. Бунга кўпроқ биз – адабиётшунослар айбдормиз: Чўлпонга нисбатан ўтмишда йўл қўйилган адолатсизликлар ва жабр-зулми бироз бўлса-да, ўртадан кўтариш учун бугунги адабиётшунослар Чўлпонга алоҳида меҳр-муҳаббат билан иш юритмоқдалар. Бу муҳаббат мутлақо қонуний ва ўринлидир. Бироқ айрим ўринларда муҳаббат зўрайиб кетиб, объективликка путур етказиб қўяётганга ҳам ўхшайди*». (О. Шарафиддинов)

Бу матнда «*Чўлпоннинг айби йўқ*» йиғиқ содда гапи қўлланган. Бу абзацда муаллиф ёзувчи Чўлпонни айбсиз деб билади. Кейинги матнда Чўлпоннинг отилгани ҳақида фикр юритиб, ўша даврдаги «*қоронғи кечалар*» и, ноҳақликлар рўй бергани, сўнг фашистларнинг бостириб келиши тасвирланган. Ўқувчи онгига тез ва кучли таъсир қилиш учун абзац «*Чўлпон отилди*» йиғиқ гапи билан бошланган:

*<u>Чўлпон отилди</u>. Чўлпон билан бирга яна юзлаб, балки, минглаб миллатнинг энг асл фарзандлари – адиблар, шоирлар, олимлар, давлат арбоблари, саркардалар, хўжалик ходимлари, ишнинг кўзини биладиган деҳқонлар отилди. Лекин бу билан ҳам қоронғи кечаларнинг тонги отмади – халқ бошига тушган даҳшатли фожиа тугамади – ҳали унинг кейинги пардалари ўйналиши керак эди.*

*Чўлпон отилди* гапи каттагина матннинг бош қисмида жойлаштирилганлиги аниқ прагматик мўлжалга эга. Биринчидан, муаллиф ўқувчининг диққатини баён бошидаёқ ёритилаётган воқеликка тортмоқчи, иккинчидан, ушбу ўзига хос синтактик киритма мавзу ривожини таъминловчи ролни ўтамоқда. Назаримизда, бу билан О. Шарофиддинов ўша мудҳиш даврда кечган воқеа-ҳодисаларни кетма-кетликда ва таъсирчан руҳда тасвирламоқчи. Ушбу очеркнинг кейинги қисмида «*Йўқ, ундай бўлмади?*» йиғиқ гапи қўлланган. Муаллиф риторик-сўроқ гапни кейинги воқеаларни янада кенгроқ изоҳлаш мақсадида ишлатган. Шу риторик тузилма пайдо бўлганидан сўнг, матннинг

давомида бўлиб ўтган воқеаларнинг таҳлили берилади. Бу икки матнда қўлланган йиғиқ гаплар муаллиф интенциясини ифодалаш вазифасини бажармоқда. Берилаётган изоҳлар асосан содда гаплардан иборат.

Шундай ҳолатни қуйидаги инглизча матнда ҳам кузатамиз:

*"I hadn't even occurred to me.", said Edmund, a look of concern on his face. "Well, it's simple – you mustn't do anything more about the murders".*

*Lenox shook his head. "No, I can't do that. If Poole is guilty, I have to confirm it; if Poole is innocent, I have to prove it"(Ch. Finch).*

Бу парчада *it's simple* йиғиқ гапи матн бошида қўлланган. Шундан сўнг биринчи гапда ифодаланган ахборотга нисбатан изоҳ сифатида ёйиқ гап келтирилган. Шунингдек, кейинги абзацда шарт тобе таркибли қўшма гап (Adverbial Clause of Condition) учрайди: *If Poole is guilty, I have to confirm it; if Poole is innocent, I have to prove it.* Бу ерда . *Poole is guilty* ва *Poole is innocent* гаплари тузилишига кўра йиғиқлик хусусиятига эга. Ушбу тузилмалар ўзига хос тактик параллелизм ҳодисасиниюзага келтириб, матнга эмоционаллик руҳини бағишламоқда, шу тарзда ахборот ифодасини таъминлаётган нутқий ҳаракатнинг таъсир қувватини кучайтирмоқда.

Ёзувчилар ижодида фикрларини ифодалаётганда кириш сўз, гаплардан, модал сўзлар, инкор ва тасдиқ сўзлардан ҳам фойдаланадилар. Айрим ҳолларда бир матнда икки ёки ундан кўпроқ киритмалар келиши мумкин.

*Бундай завқ-шавқ, кўп ҳолларда мадҳия тарзида, адоқсиз мақтов шаклида намоён бўлади. Натижада, у сиймонинг ҳаёт йўлига, фаолиятига оид материаллар фақат баланд авж пардаларда, фақат ёрқин рангларда намоён бўлади. Кейин, тасвир объектига бундай ёндашиш салмоқли самаралар бермайди. Ўтмишдаги буюкларимиз жуда катта жасоратларни кўрсатгани учун, маънавият бобида улуғ кашфиётлар қилгани учун буюк бўлишган. Улар ҳаётини силлиққина яшаб ўтган жўн одамлар эмас. Бу – қийин, албатта. Лекин қачон, қаерда ким осон йўлдан бориб, улуғ марраларни эгаллаган. Кўринадики, ҳали қилинадиган ишлар кўп. Адибларимиз ва санъаткорларимиз бутун масъулиятни чуқур идрок этган ҳолда бу муҳим мавзуни ёритишга бел боғлашса, уларга буюк аждодларимизнинг руҳи мададкор бўлади. Бунга шубҳа йўқ. (О. Шарафиддинов)*

Шактый гына тормыш тәҗрибәсе туплаган, күркәм баритон, бәрхет тавышлы, җыр-әдәбиятны яраткан, туган төбәгендә абруй казанган Фоат Галимуллин, күпләрнең тәкъдиме белән, Татарстан радиосына (ул бу төр чараның техник якларын Армиядә чакта ук үзләштергән була) дикторлык конкурсында катнаша, шактый авыр, җаваплы сынауларны үтеп, 1967 елда диктор булып эшли башлый. Консерваториягә керергә тәкъдимнәр булса да, ахыр чиктә сүз сәнгатен, филологияне сайлый. Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә читтән торып укый. Иҗтимагый-мәдәни-сәнгати тормышның үзәгендә кайный. Күпләгән күренекле һәм гади (рядовой) кешеләр белән таныша, аралаша. Пединститутта бик яхшы укуын, мәкалә-хезмәтләр дә язуын исәпкә алып, аны 1974 елда татар әдәбияты кафедрасына укытучы итеп эшкә чакыралар. Шулай итеп Фоат Галимуллин вуз мөгаллиме булып китә. Әмма ул үзе 7 ел эшләгән радиокомитет, шулай ук телевидение белән хезмәттәшлеген теге яки бу дәрәҗәдә дәвам итә: киңәш-теләкләре белән уртаклаша, аның күркәм тавышы эфирда еш яңгырап тора. Әле менә шушы мәкаләне язган вакытта, төгәлрәге 13 нче февраль көнне ТНВ каналындагы Фәридә Тәхфәтуллина алып барган «Сиңа миннән сәлам» тапшыруына «кунак» сыйфатында чакырылган Фоат әфәнде куелган сорауларга бик төпле җаваплар бирде; тел, милләт, сөйләм культурасы хакындагы фикерләре белән уртаклашты. Дикторлыктан китүенең төп сәбәбен дә аңлатты. «әзер, кешеләр язган текстны укудан ялыктым»; «Үзем язып, үземнекеләрне күбрәк сөйлисем килде», – диде ул.

Фоат Галимуллин эшчәнлегенең Казан чоры, аеруча пединстимтуттагы, Язучылар Берлегендәне, Дәүләт Советындагы эшчәнлекләре шактый бай, күпкырлы. Шунысы үзенчәлекле: боларның зур өлеше киң җәмәгатьчелекнең күз алдында башкарылды, гавамга, аеруча зыялыларга билгеле. Мәкал-хезмәтләре, дәреслек-әсбаплары бер-бер артлы чыгып кына тора. Өстәвенә аның үзе хакында да шактый гына махсус тапшырулар бар, берничә дистә язма да дөнья күргән. Мәсәлән, «Фикер һәм хис гармониясе» исемле җыектыкта (К., 2011. 192 б.) Ренат Харис, Фәрит Хатипов, Рүзәл Юсупов, Шаһинур Мостафин, Факил Сафин һәм кайбер башка әдип-галимнәрнең, хезмәттәшләренең, шулай ук студенетларның язмалары, шигъри юллары да бар. Бик эчтәлекле, фотоиллюстрацияләргә

дә бай булган бу китап профессор эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген, муллыгын шактый тулы күзалларга ярдәм итә. Мәгълүм ки, юбилярыбыз гомер буе әдәби иҗат белән дә шөгыльләнеп килә. Аның шигырь-хикәяләре сирәк-мирәк булса да вакытлы матбугат битләрендә дә күренгәләп ала. 2011 елгы җыентыкта Фоат Галимуллинның ике дистәләп чәчмә, тезмә әсәре урын алган. Шигырьләренең берничәсе Тукай, Такташ, С. Хәким, К. Нәҗми кебек күренекле әдипләргә мөнәсәбәтле. [Ишетүемчә, Татарстан Язучылар Берлегенең «башлыгы» да булып торган бу тыйнак зат, ниһаять, үзенең чәчмә-тезмә әсәрләрен туплап, аерым китап итеп чыгара икән. Ул тиз арада кулга керергә язсын!]. Бу җыентыкта һәм гомумән башка язмаларда, шул исәптән Г. Ахунов, М. Мәһдиев, Римма Казакова.... мәкаләләрендә бәйрәмдарыбызның эшчәнлеге хуплана, бик тә уңай бәяләнә. Мәсәлән, профессор Азат Әхмәдуллин үзенең бер язмасында (Казан утлары. 2016. № 3. 122–125 б.) Фоат Галимуллин «җитди иҗат мирасын булдырган киң карашлы галим», «күренекле җәмәгать эшлеклесе», «оста оештыручы һәм укытучылар остазы», дип атый. Без фәкыйрегезнең дә «Күренекле һәм мөхтәрәм зыялыбыз (Фоат Галимуллинга – 70 яшь) » дигән шактый күләмле мәкаләсе бар (Мәдәни җомга. 18.03.2011). Мондый шартларда исә Хатыйп Йосыф улына бу язмасында кайбер факт-мәгълүматлар китерү, күзәтүләр ясау белән генә чикләнергә туры килде һәм килә.

Фоат әфәнде Казан педагогия институтында эшли башлагач, Башкорт дәүләт университеты проректоры, милләттәшебез Мидхәт Гайнуллин җитәкчелегендә читтән торып аспирантура уза һәм 1980 елда Уфада «Хәзерге татар прозасында хезмәт кешеләре характерлары» темасына диссертация яклый һәм «филология фәннәре кандидаты» дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була. 19 елдан соң, ягъни 1999 елда Казан университетында докторлык диссертациясе яклый. Миңа, бу советның гыйльми секретаре буларак, яклау процессының үзәгендә кайнарга туры килде. Фоат Галимуллинның диссеррация яклавы фәнни-рухи тормышыбызда мөһим бер вакыйга рәвешендә яңгыраш тапты. Тиз арада ул «филология фәннәре докторы», «профессор»лык дипломнарын да алуга иреште. Ф. Галимуллин 1977 елдан башлап 15 елга якын тарих-филология кебек зур факультетның декан урынбасары, деканы булып эшләде. Шактый еллар буе татар әдәбияты кафедрасы мөдире булды. Шәхсән минем үземә дә деканатта эшләргә, кафедра белән җитәкчелек итәргә туры килде. Шуңа күрә андагы эшләрнең күплеген, катлаулылыгын, җаваплылыгын яхшы беләм. Фоат әфәнде ул вазыйфаларны күңел биреп, үзенә хас җаваплылык һәм намус белән башкарды. Ул хәзер дә КФУның татар әдәбияты кафедрасында уңышлы гына эшләвен дәвам итә.

Ярты гасырга якын вузда эшләү дәверендә бәйрәмдарыбызга әдәбият тарихының төрле чорларын укытырга туры килә. Аның фәнни-тәнкыйди

хезмәтләре, нигездә, соңгы двәер сүз сәнгате белән бәйле булса да, ул озак еллар буе, дәвамлы рәвештә «Борынгы һәм Урта гасыр әдәбияты» курсын алып барды, аны яратып укытты. Бу яктан без аның белән хезмәттәшләр дә идек. Чөнки минем дә төп укыткан предметымның берсе – татар әдәбияты тарихының тәүге кисәге булды. Фоат әфәнденең икенче яраткан «дисциплинасы» – «Сәнгатьле уку». Нәфис сүз остасы буларак, ул үзенең шәхси тәҗрибәсенә таянып, бу өлкәдәге гыйльми-методик казанышларны иҗади файдаланып, бу курс буенча берничә хезмәт – методик әсбап та язды. Алар студентлар арасында гына түгел, укытучылар, методистлар, иҗат әһелләре тарафыннан да бик теләп кулланыла. «Сәнгатьле уку» курсын Ф. Галимуллин университет студентларына да укыды. Татарча төзек итеп сөйләү, чыгыш ясау хәзер аеруча актуальләште. Шуңа мөнәсәбәттә профессорыбызга да бу юнәлештә хәзер дә ныклап хезмәт кылырга туры килә. Аның бу мәсьәләләр буенча чыгышларын, төрле конкурс-җырларда катнашуларын без еш ишетеп, күреп торабыз.

Вузда эшләү елларында Ф. Галимуллин җитәкчелегендә язылган курс, диплом эшләре, мөгаен, берничә йөздән артык китәдер. Ул мәктәп укытучылары, әдип-шагыйрьләр, журналистлар тәрбияләү белән бергә, югары квалификацияле гыйлем әһелләре әзерләүгә дә үзеннән җитди өлеш кертеп килә. Аның җитәкчелегендә язылып, якланган кандидатлык, докторлык диссертацияләренең саны, мөгаен, ике дистәләп бардыр.

Ф. Галимуллин эшчәнлегенең нигезен, төп өлешен, умыртка сөяген, гәрчә ул төрле тармакларда хезмәт куйса да, халкыбызның сүз сәнгатен өйрәнү тәшкил итә. Ул татар әдәбиятының тарихчысы һәм тәнкыйтьчесе дә, теоретигы һәм методисты да. Аның әлеге тармаклардагы эзләнү-тикшеренүләре, уйлану-күзәтүләре әдәбиятчы-галимнең гәҗит-журналларда басылган мәкалә-хезмәтләрендә, дистәләгән китапларында (монография-җыентыкларында) чагылыш тапкан. Болар арасында Фоат әфәнденең «1920–1930 еллар татар әдәбиятында эстетика һәм социологизмның үзара мөнәсәбәте” темасына язылган докторлык диссертациясе һәм аның төп эчтәлеген, нәтиҗәләрен чагылдырган «Эстетика һәм социологизм» исемле монографиясе (К., 1998) аеруча мөһим урынны били. Исеменнән үк күренгәнчә, куелган тема бик тә катлаулы, каршылыклы. Автор гаять күп төрле чыганакларны, әдәби әсәрләрне, гыйльми-теоретик хезмәтләрне өйрәнеп, аларны фәнни-тәнкыйди анализлап, үз алдына куелган проблемаларны, иң беренче чиратта, «эстетика», «социологизм» кебек теш үтмәслек мәсьәләләрне уңышлы гына яктыртуга ирешә, әдәбият фәненә үзенең җитди генә өлешен кертә.

Ф. Галимуллин язмаларында күпгасырлык татар әдәбиятының төрле чорлары, мәузуглары, әдипләре гәүдәләнеш тапкан. Әмма аның гыйльми-тәнкыйди эшчәнлегендә төп урынны гасырдан артыкка сузылган соңгы чор сүз сәнгате

били. Юбилярның Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, Ф. Бурнаш, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Еники, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Г. Ахунов, М. Хәбиуллин, И. Салахов һәм янә кайбер башка әдипләр хакындагы мәкалә-хезмәтләре укучыларга шактый билгеле. Фоат әфәнде заман әдәбияты белән даими танышып бара. Яңа әсәрләр, яңа, яшь авторлар хакында уйлану-тәэсирләрен үзенең тәнкыйть мәкаләләрендә укучыларга җиткереп тора. Ул бу төр язмаларында, нәкъ остазларыбызның берсе булган Гази аша Кашшаф кебек, мөмкин кадәр уңай, позитив якларны күрсәтергә тырыша, кимчелек-җитешсезлекләрне шәхесне рәнҗетмичә, тупаслыкка юл куймыйча, сак кына, гадел-объектив рәвештә бәян итәргә омтыла. Бу хосусият аның фәнни хезмәтләргә, гыйльми-популяр җыентыкларга язылган рецензия-бәяләмәләрендә дә даими күзәтелә (Аның безгә мөнәсәбәтле язмалары да бар. Янә рәхмәт үзенә!). Галимнең әдәби бәйләнешләр, башка халыкларның әдәбиятлары хакында язылган хезмәтләре дә бар.

Милли мәгариф, тел-әдәбиятны укыту-өйрәнү һәр халыкның, аеруча безнең кебек үз дәүләте булмаган кавемнәрнең рухи яшәеше өчен һәрчак мөһим. Соңгы дистә елларда, бигрәк тә XX–XXI гасырлар аралыгында бу иң төп проблемаларның берсенә әверелде. Ф. Галимуллин, – шушы зарурият-ихтыяҗны тирәнтен тоеп, мәктәтәпләр, уку йортлары өчен милли кадрлар тәрбияләү белән бергә, дәреслек-әсбаплар әзерләүдә дә иң актив галим-методистларыбызның берсе. Аның үзе һәм хезмәттәшләре белән берлектә төрле сыйныфлар өчен язылган дәреслек-хрестоматияләре инде соңгы чирек гасырда кат-кат басылып, уку йортларында иркен кулланыла. Болар арасында бигрәк тә «XX йөз башы һәм 20 нче еллар татар әдәбияты»н яктырткан, 10 нчы сыйныфка адресланган дәреслек үзенең яңалыгы, бай эчтәлеге, методик корылышы белән аерылып тора. Фоат Галимуллин Татарстан Язучылар Берлегенең 1999, 2002 нче корылтайларында бу оешманың рәисе итеп сайланды. Ике срок, ягъни алты ел буена ул бу авыр да, шәрәфле дә вазыйфаны гаять җаваплылык, тырышлык белән башкарды. Әдәбиятны үстерү, иҗат көчләрен барлау һәм тәрбияләү, әдипләрнең тормыш хәлләрен кайгырту, сүз сәнгатебезне пропагандалау һәм кайбер башка юнәлешләрдә бик күп эшләр башкарылды. Мин боларны Язучылар Берлеге әгъзасы, идарә члены буларак, шәхсән үзем дә күрдем, аларда мөмкин кадәр катнашырга тырыштым. Фоат әфәнде, оста дирижер кебек, зур оешма белән оста җитәкчелек итте. Шушы елларда әдәби мирасны кайтару, өйрәнү юнәлешендә дә зур эшләр башкарылды. Күпләгән китап-хезмәтләр дөнья күрде, диссертацияләр якланды. [Бүгенге көндә гыйльми кадрлар тәрбияләү аянычлы хәлдә. Диссертация советлары эшләми диярлек. Булган кадәресебез өлкәнәеп, картаеп бара. Яшьләр әзерләнми диярлек. Боларны күрә торып, без чаң какмыйбыз, тиешле эш-гамәлләр кылмыйбыз].

Ф. Галимуллинның тырышлыгы белән күп төрле гыйльми, мәдәни чаралар уздырылды. Аның ил, халыкара семинар-конференцияләрдә, җыелышларда әдәбиятыбызны таныту өлкәсендәге эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Бу мөхтәрәм затыбызның рекомендация-тәкъдимнамәләре, рецензия-бәяләмәләре белән берничә дистә чордашыбыз Язучылар Берлегенә кабул ителде, фән кандидатлары һәм докторлары сафына басты. Ул безнең университетта һәм кайбер башка югары уку йортларында ГЭК рәисе буларак та эшләде, йөзәрләгән студентларга дипломнар тапшырды.

Безнең шактый гына милли зыялыларыбызның, шул исәптән әдип-галимнәребезнең дә балалары, гаилә әгъзалары татарчадан бик хәбәрдар түгел, хәтта газиз телебезне бөтенләй диярлек белмәүчеләр дә бар. Оныкларыбыз арасында – Владимир, Татьяналар да очрап тора. Бу яктан Фоат Галимуллин безгә күркәм бер үрнәк. Аның балалары, оныклары татар телен, мәдәниятен танып белү генә түгел, ул өлкәләрнең белгечләре дә. Кызы Әлфия ханым Галимуллина – филология фәннәре докторы, КФУ профессоры, әдәби бәйләнешләрне өйрәнүче күренекле методист галимә. Улы Фәрит Казан университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетында укыды, күренекле шәхесебез Габдрахман Ибраһимов хакында диссертация язып, тарих фәннәре кандидаты булды. Оныгы Айдар да, бабасы юлыннан барып, әдәбиятыбызны өйрәнеп, кандидат булырга җыена.

* * *

Гомер дигәнең аккан су, искән җил кебек уза да, уза. Әле яңа гына Фоат әфәнденең 70 еллыгын киң күләмдә билгеләп үткән идек. Инде менә аңа 80 яшь тә тулып бара. Шактый гына зыялыларыбыз җиденче дистәне тутыргач, иҗади, гыйльми, иҗтимагый тормыштан читләшәләр; тынып калалар. Фоат әфәнде исә соңгы унъеллыкта үзенең күпкырлы эшчәнлеге белән безне гаҗәпләндерде. Рәхмәт үзенә, бер үк күзләр тимәсен! Алдагы дистәсен дә тутырып, 90 еллыгын да хәзерге кебек исән-сау, сәламәт акыл, зиһен, иҗади уңышлар белән каршыларга язсын!

Фоат Галимулла угылы күп төрле бүләк-дәрәҗәләргә ия. Аны халкыбыз таный, белә, хөрмәт итә. Монысы исә, Адәм баласы өчен иң зур бүләк, иң зур дәрәҗә!

**Ф.Х. Миңнуллина**
ТРФА Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

## 1920 ЕЛЛАР ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ЯҢА ГЕРОЙЛАР

**Ф.Х. Миннулина**
Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова АН РТ, Казань

## НОВЫЕ ГЕРОИ В ТАТАРСКОЙ ДРАМАТУРГИИ 1920-Х ГОДОВ

**Аннотация.** Статья посвящена изучению татарской драматургии 20-х годов XX века, где показана трагедия человека, на долю которого выпали суровые жизненные испытания. Драматурги не только изобразили на страницах своих произведений исторические события, но также смогли отразить трансформацию мировосприятия и ценностных ориентиров человека под влиянием диктатуры. Проблема противостояния героев трагическим обстоятельствам в безвыходной ситуации в каждой из рассматриваемых пьес решается по-разному.

**Ключевые слова:** герой, идеология, конфликт, драма.

**Abstract.** The article is devoted to the study of the Tatar drama of the 20s of the XX century, which shows the tragedy of a person who suffered severe life trials. The writers not only depicted historical events on the pages of their works, but also were able to reflect the transformation of a person's perception of the world and values under the influence of the dictatorship. Problem of the heroes confrontation the tragic circumstances in a desperate situation is solved in each of these works in various ways.

**Keywords:** hero, ideology, conflict, drama.

1917 ел һәм аннан соңгы вакыйгалар сәхнә әдәбиятыбызга сизелерлек эз сала. Бу елларда коммунистлар партиясенең идеологик басымы көчәю язучыларның иҗатын билгеле бер кысаларга кертә, идея-эстетик яктан капма-каршы төркемнәргә аеруга китерә. Татар язучыларының кайберләре инкыйлабны бер каршылыксыз яклап чыга, икенчеләре урталыкта, өченчеләре исә большевиклар сәясәтен инкарь итеп, мөһәҗирлеккә китә. Туган илдә калган әдипләрнең күпчелеге, яңа хакимият вәгъдәләренә ышанып, аңа ихлас күңелдән хезмәт итәргә алыналар, милли-социаль идеалларына турылыклы булып, большевикларны әлеге идеалларын тормышка ашырачак дип саныйлар. Әдәбиятта

фронт, сугыш, Кызыл Армия, хәрби коммунизм, дин һәм дин әһелләре белән көрәш, хезмәт, яңа тормыш төзү, яңа кеше, гаилә формалашу, завод фабрикалар, хезмәт процессы, совет крестьяны психологиясе, эшчеләр көнкүреше һ. б. темалар актуальләшә, гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр дә инкыйлаби яссылыкта бирелә.Болар барсы да герой концепциясенең, идеянең үзгәрешенә этәрә. Билгеле булганча, бу еллар әдәбиятында үзенчәлекле бер тема – яңа тормыш төзү хакына бар нәрсәдән ваз кичү, шәхси тормыштан баш тарту темасы игътибар үзәгендә булды. Һ. Такташның мәсәлән, «Күмелгән кораллар» драмасының төп герое Мансурныңбарлык эш-гамәлләренмиллионнарның бәхете өчен бернәрсәне дә кызганмау, һәммәсен гомум көрәш файдасына корбан итүгә корылуы шуңа мисал. Ул сөйгән кызы Сәгыйдәгә: «Авыр бер эш. Ләкин син аны эшләргә тиешсең. Нинди генә авырлыклар белән булса да, аның кемлеген, алдагы планнарын, аның кемнәр белән бәйләнеш тотуын белергә кирәк» [Такташ, 1981: 24–25] – ди. Боерыкны исә, кыз сафлыгын югалту бәрабәренә эшли һәм «... мин аны синең соравың өчен түгел, революция өчен эшләдем» [Такташ, 1981: 47], – дип аңлата ул үзенең адымын. Биредә корбанчылык сыйфатларны данлаучы, яңа тормыш хакына үзен корбан итүче яңа заман герое күзаллана. Бу революцион чынбарлыкта туган һәм яшәгәнаскетизмның әдәбиятта чагылуы, заман зарурияте иде. Әйергә кирәк, 1917 елдан соңгы әдәбиятта яңа заманны бүтәнрәк позициядән торып бәяләү, башкарак мотивларны яктырту, халык тарихына игътибар көчәйтү күзәтелә. Революцион өчен шәхси мәнфәгатьләрдән баш тарту, яңа чорның уңай героен бары тик иҗтимагый эшчәнлектә генә сурәтләү әсәрләрдә шәхси интриганың читтә калуына китерде. Ш. Госмановның «Канлы көннәрдә» (1919), «Беренче адым» (1919), К. Тинчуринның «Йосыф – Зөләйха» (1918), Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» (1920), Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» (1920), Т. Гыйззәтнең «Наёмщик», «Талир тәңкә» (1922), «Кызыл карчыга» (1928),пьесаларындамәсәлән, яңа заман сулышы, әле генә мәйданга чыккан заман геройлары, әхлакый кыйммәтләр үзгәреше, халыкның кан коюны кабул итмәве дә бар.

Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» (1920) драмасы яңа заман сулышын, әле генә мәйданга чыккан заман геройларын, совет иделогиясе тудырган яңа кешеләрне, яңа кыйммәтләрне алга куюы белән үзенчәлекле. Бу пьеса – язучының бердәнбер сәхнә әсәре – күп төрле фикерләр кузгатты. Аерым бер тәнкыйтьчеләргә, язучының пьесаданың үзәк герое Батырханны бай кызы Зәйниягә булган мәхәббәтен көрәшнең кызган бер чорында күрсәтүе һәм бу мөнәсәбәтне уңай яктан сурәтләве ошамый. Мәсәлән, Фатих Сәйфи-Казанлы әсәрнең яшь һәм яңа әдәбият өчен зур әһәмиятен билгеләп уза. Ә менә Шәриф Байчура исә «Яна кешеләр»не каты тәнкыйть итә. Пьесаның каһарманы гомумирәк теләкләр өчен газапланучыитеп сурәтләнергә тиеш иде дип чыга. Димәк, әсәрдә Г. Ибраһимов

шәхси һәм иҗтимагый тормышны үзара сыеша алу мөмкинлеген дә күрсәтә. Автор инкыйлабның кешеләр аңына зур үзгәрешләр, яңа геройлар алып килүен Хәйри бай гаиләсе язмышы аша да ачып бирә. Язучы бу гаилә әгъзаларының кайберләренең инкыйлабчылар ягына күчүен, байның гаделсез, кансыз булуы белән бәйләп күрсәтә. Фәтхия карчыкның улы Вәли мәсәлән, тормышның элекке хәленә кире кайтуыннан саклана, шул ук вакытта Хәйри байның Себергә качуы, Вәлинең аннан калган байлыкны саклап калуы инкыйлабның киләчәктә яшерен дошманнары булуын күрсәтә. Әйтергә кирәк, әдипнең бу әсәрендә яңа җәмгыять төзү өчен көрәшкә күтәрелгән геройлар өстенлек итә, сыйнфый көрәш идеясе, яңа система дошманнарын юк итү конфликты үзәккә куела. Шулай да, Г. Ибраһимов пьесасында сыйнфый каршылыкларны гына түгел, ә яңа җәмгыятьне төзүче кешеләрнең формалашуын, үз чорының канлы вакыйгаларын, гражданнар сугышы фаҗигаларына бәйле рәвештә шәхес фаҗигасын дә күзалларга мөмкин. Бу яктан драмада сурәтләнгән яшь буын вәкиле Тимеркәй образы игътибарга лаек. Вакыйгалар үстерелешендә ул кызу канлы, хаксызлыкны, гаделсезлекне кабул итә алмаучы шәхес буларак ачыла. Егетнең Вәли абыйсын үтерүе һәм: «Агайны гына түгел, андый урында туган атайны да кызганмам мин!» [Ибраһимов, 1976: 410], – дип әйтүе аеруча тетрәндерә. Ул гомумкешелек бәхетенә көрәш, кан коею юлы белән генә ирешеп була дип уйлый. Канлы көрәш көннәрен кешелексез, фаҗигале бәрелеш рәвешендә тасвирлаган драмаларда туганлык, мәхәббәт проблемалары да үзәккә куела. Т. Гыйззәтнең «Кызыл карчыга» (1926) драмасында кеше, гаилә фаҗигасе ахыр чиктә ил фаҗигасы югарылыгына куела. Драматург совет власте урнаштыру өчен канлы көрәш барган көннәр вакыйгаларын тергезә. Яхшы тормышлы шәһәр кешесенең улы үз теләге белән Кызыл Армия сафларына языла. Кызыл карчыганың туган йорты канкойгыч бәрелеш үзәгенә әйләнә, бу бәрелештә атасы ялгышлык белән улын атып үтерә. Үз гаебе белән улын югалткан ата фаҗигасы сәяси көрәш шартларында бер гаилә, нәсел, ил кешеләренең үзара дошманлашуы, кан коюы, идеологик каршылыклар кешеләрнең бер-берсен физик юк итүгә китерүе хакында уйландыра. Сыйнфый көрәшнең кискенләштерү сәбәпле, 1920 елларның икенче яртысында язылган әсәрләрдә дошман эзләү мотивы кискеләшә. Һ. Такташның 1927 елда язылган «Күмелгән кораллар» пьесасының үзәгенә мәсәлән, гражданнар сугышы чорында авылда барган сыйнфый көрәш куела. Пьесада катнашучылар капма-каршы ике төркемгә аерыла. Берәүләр инкыйлап яклылар булсалар, икенчеләре – аның дошманнары итеп тасвирланалар. Элеккеге ак офицер Солтан кулак, мулла малайларын туплап, урманда үзенә бер төркем оештыра. Габдулла, Мокай кебек ярлыларны гражданнар сугышына китүдән тыя. Авыл ярлыларын советларга каршы һөҗүмгә әзерли. Сәбәбе – этисенең совет иярченнәре, дөресрәге, туганы

Мансур тарафыннан үтерелүе, мал-мөлкәтсез калуына бәйле. Әмма, акрынлап аңа иярүчеләр Солтанны ялгызлыкта калдыралар. Ахыр чиктә герой «Коммунистлар белән килешеп эшли башлаган идем бугай? Ни өчен мин киттем?» [Такташ, 1981: 54] – дип өзгәләнә. Пьесада Мансур каты бәгырьле, явыз, үз эше, идеалларына бирелгән кеше буларак ачыла. Ул инкыйлабка каршы чыккан өчен атасының агасын үлемгә хөкем итә, Солтанны кулга ала. «Байлык кардәшлекне белмәгән кебек, революция дә кардәшлекне белми. Мин аны агай тиешле булуы өчен аярга тиеш булсам да, миллионнарның теләге андый революциягә каршы кешеләрне ату булгач, мин миллионнарның теләген үтәдем...» [Такташ, 1981: 47], – ди герой үзенең эш-гамәлләре хакында. Әлеге сүзләр Мансурның характерын гына түгел, ә шул заман кешесенә хас булган сыйфатларны, яңа кешенең формалашуын ача. Биредә язмышны гәүдәләндерүче, хәл итүче коммунист-җитәкче образ булрак күзалана. Дошманнан үч алу вазифасын башкара. Үткән тормышның җимерелүе, яңа тормышның төзелүе, аның кеше язмышына, аңына драматик чагылышы бирелә. Шул рәвешчә, «Җир уллары трагедиясендә» бирелгән туганны үтерү мотивы әдип тарафыннан «Күмелгән кораллар»да һәм «Камил» драмаларында да үстерелә. Югарыда искә алынганча, большевикларның милли өлкәдә бөтенләй башка сәясәт үткәрүләрен аңлап, яңа хакимиятнең вәгъдәләренә ышанмаучылар ватаннарын калдырып чит илгә китәләр. Мәсәлән, Г. Исхакый илдә урнаштырыла башлаган яңа тәртипләр, бигрәк тә большевикларның милли сәясәте белән килешә алмыйча, туган иленнән мөһәҗирлеккә китәргә мәҗбүр була. Әдипнең мөһаҗирлектә язылган «Җан Баевич», «Олуг Мөхәммәд», «Хәят юлында», «Дулкыннар арасында» кебек сәхнә әсәрләре милли рух белән сугарылган. Р.К. Ганиева билгеләгәнчә, ул большевиклар сәясәте, кызыл террор мәсьәләләрен тасвирлаган «Дулкын эчендә», «Катлаулы рус һәм татар сәяси мөнәсәбәтләрен, христиан һәм ислам диннәренең рус һәм татар тарихындагы урынын, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы кебек дәүләтләребезнең, казан татарларының ниндиерәк варислары булу мәсьәләсен, тарихи барышта ирешкән уңышларыбыз һәм җибәргән хаталарыбыз турындагы уйлануларны, гореф-гадәтләребезне “Олуг Мөхәммәд” драмасында чагылдырды» [Ганиева, 2002: 147]. Язучының «Дулкын эчендә» драмасында автор яшьли тол калган Разыя абыстай белән аның бердәнбер кызы Бану язмышы мисалында халык язмышы, фаҗигасе хакында сүз алып бара. Драмада Разыяны ике балалы Хәйрулла яучылый. Ләкин, Разыя кызы хакына аңардан баш тарта. Кызы Бану кияүгә чыгып Кырымга киткәч, ул бу адымының хата булуын аңлый. «Мин гаепле... Мин сине балам өчен корбаниттем. Сине генәтүгел, үземне дә корбан иттем... Анда үлсәң, син анда кан эчендә буылып, балаларыңны күрергә тилмереп үлсәң, мин монда ялгызлыкта, ятимлектә буылам...» [Исхакый, 2009: 280]. Шул рәвешле әсәргә үз-үзен ялгызлыкка дучар иткән кеше фаҗигасе

килеп керә. Гражданнар сугышын, Беренче бөтендөнья сугышын кичергән гаиләнең язмышы, большевиклар властька килгәч, фаҗигале төсмер ала. Кызыллар Разыяның бер гаебе булмаган киявен атып үтерәләр, үзен, буржуйлыкта гаепләп, булмаган акчаларын бирүне таләп итәләр, өйдәге бар әйберен алып чыгып китәләр. Бу авырлыкларга түзә алмаган хатын якты дөньядан китеп бара. Шул рәвешле, әдип сәясәттән ерак торган бер гаилә мисалындаяңа заман җилләренең кырыслыгын һәм яңа хакимият вәкилләренең рәхимсезлеген ассызыклый. Әлеге күренешләр ананың бала алдындагы бурычының шәхси мәнфәгатьләр белән каршылыкка керүе кебек мәсьәләләр тирәсендә яктыртыла.

«Дулкын эчендә» (1920), «Олуг Мөхәммәд» (1944–1947) драмаларында тарихи яктан якын килә, иҗтимагый-сәяси эчтәлекне алга планга куя. «Әйтерсең тарихның иң катлаулы этапларын тергезү аша татар өчен мөһим рухи кыйммәтләрне барлый. Алар – туган җир, туганлык, тугрылык, намус» [Заһидуллина, 2018: 16].

Г. Исхакыйның тарихи пьеса буларак тәкъдим ителгән «Олуг Мөхәммәд» пьесасында татар халкының үткән тарихын бирү. Әсәрдә Олуг Мөхәммәд зирәк, алдан күреп эш итүче идарәче буларак ачыла. «Без таралган илемезне берләштерергә тырышамыз.... Дәүләт корыр өчен белем кирәк, бер-береңә ышаныч кирәк, халыкның төрле катлаулары арасында күңел бавы кирәк...» [Исхакый, 2009: 455]. «Зөләйха» трагедиясендәге кебек, биредә дә әдип һәр халыкның үз диненә хаклыгы булу мәсьәләсен күтәрә. Драманың ахыры да тирән мәгънәгә ия. «Бу сәгатьтән башлап, Мәскәү князьлеге берлә Казан ханлыгы арасында сугыш бетте, килешү булды... Халыкка белдереңез..., халык өч көн, өч кич бәйрәм итсен...» [Исхакый, 2009: 517], – ди хан. Олуг Мөхәммәд кан коюны бетерергә, дуслык урнаштырырга, халыкны тынычлыкта яшәтергә уйлый. Автор Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыклары хакында сүз алып барып, татар халкының үз вакытында дәүләтле булуын билгели.

Гомумән, язучылар үзләренең геройлары аша үткән чорның социаль күренешләрен, халык язмышын, аның яшәешен, уй-фикерләрен, катлаулы тормышын сурәтләп, чынбарлыкта хөкем сөргән социальәхлакый тәртипләр турында сүз алып баралар һәм тарихның катлаулы, фаҗигалы елларын күрсәтәләр.Яңа заманның яңа кешеләре мөнәсәбәтләрен ачу, яңа әхлакый нормаларны ассызыклауны үзәккә куялар.

**Әдәбият**

1. *Ганиева Р.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – 272 с.

2. *Заһидуллина Д.Ф.* Г. Исхакыйның әдәби иҗаты: милләтне үстерү-үзгәртү юлын эзләү // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале

XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – 450 с.

3. *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 454 б.

4. *Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 томда. 5 том: Хикәяләр, повестьлар, пьесалар (1920–1947). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 559 б.

5. *Миңнуллина Ф.Х.* Г. Исхакый драматургиясендә фаҗигалелек («Зөләйха», «Дулкын эчендә», «Олуг Мөхәммәд» әсәрләре мисалында) // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – 450 с.

6. *Такташ Һ.* Сайланма әсәрләр. Өч томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 2 т. –254 б.

**В.Т. Михайлов**
Марийский государственный университет, Йошкар-Ола

# СТРУКТУРА И СОДЕРЖАНИЕ СОВРЕМЕННЫХ УЧЕБНИКОВ-ХРЕСТОМАТИЙ ПО МАРИЙСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ ДЛЯ ОСНОВНОЙ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЙ ШКОЛЫ

**Аннотация.** В статье рассматривается современное развитие национальной учебной книги по марийской литературе для основной общеобразовательной школы Республики Марий Эл. Теоретически осмысливается ее историко-культурный и научно-педагогический потенциал. Анализируются структурные и содержательные компоненты учебной программы и учебников-хрестоматий. Выявляется основная образовательная цель УМК – формирование гуманистической личности и этнокультуроведческой компетенции обучающихся.

**Ключевые слова:** марийская литература, учебник-хрестоматия, межпредметная связь, культурологический подход.

**Abstract.** The article examines the modern development of the national educational book on Mari literature for the main secondary school of the Republic of Mari El. Its historical, cultural, scientific and pedagogical potential is theoretically comprehended. The structural and content components of the curriculum and textbooks-anthologies are analyzed. The main educational goal of teaching materials is revealed – the formation of a humanistic personality and ethnocultural competence of students.

**Keywords:** Mari literature, textbook-reader, intersubjective communication, cultural approach.

Содержание учебной дисциплины *марий литератур* (марийская литература) регламентируется требованиями к обязательному минимуму содержания литературного образования, зафиксированными ФГОС общего образования, а также примерной учебной программой «Марийская литература: Примерная программа для основной школы», составленной в соответствии с базовыми положениями ФГОС.

С учетом возрастной группы обучающихся программа включает перечень произведений устного народного творчества и художественной литературы, краткие аннотации, раскрывающие их основную проблематику и художественное своеобразие. Изучению произведений предшествует краткий обзор жизни и творчества писателя. В программе предложен новый культурологический подход, который в условиях национальной школы реализуется в диалоге родной и русской литератур, а также литератур народов РФ и зарубежной литературы. Наряду с произведениями родной литературы для ознакомительного чтения предложены небольшие разделы «Фольклор и литература народов России» и «Зарубежная литература». В них нашел отражение диалог марийской литературы и литературы соседних народов (башкирской, татарской, чувашской). Например, в разделе «Фольклор и литература соседних и родственных народов» учащиеся изучают мансийскую сказку «Заяц» и удмуртскую – «Как купец хотел солнце остановить», стихотворение башкирского поэта Мустая Карима «О березовом листе», татарского поэта Роберта Минуллина «Слово соседа – божье слово», чувашского поэта Надежды Сильби «Чувашия – мой край родной» [5]. Из зарубежной литературы в основной школе предусмотрено изучение карело-финского эпоса «Калевала», стихотворения Арво Валтона «Что тебе нужно в этой жизни», Лены Лаулаяйнен «Чачавий» [5] и др. Знакомство с ними ориентировано на раскрытие взаимосвязи их творчества с творчеством марийских писателей.

В основной школе УМК по марийской литературе представлен учебным и рабочими программами, учебниками-хрестоматиями (5–9 кл.) и книгами для внеклассного чтения (5–9 кл.).

Составителями предложена следующая структура учебников:

1) материал, предшествующий основному тексту: краткие сведения о жизни и творчестве писателя; сведения из истории марийской литературы, помогающие осмыслить эпоху, отраженную в произведении;

2) основной текст (фольклорный материал и художественные произведения ((в сокращении или во фрагментах), предлагаемые для текстуального изучения);

3) самостоятельные статьи по теории литературы;

4) дополнительный материал по взаимосвязи литературы с другими видами искусств (сведения о живописи, музыке, опере);

5) методический аппарат, включающий вопросы и задания аналитического характера, творческие задания на осмысление художественного своеобразия произведения, вопросы и задания на усвоение теоретико-литературных понятий, на развитие художественного творчества, словарно-фразеологические сноски, культуроведческий словарь и т. д.

В изложении материала и при анализе художественных текстов внимание акцентируется на нравственном пафосе произведения, на их художественной специфике, при отборе биографического материала – на идейно-познавательные ценности фактов жизненного и творческого пути писателя, а также на значение тех или иных сведений о нем для понимания и усвоения авторской художественной концепции произведения.

В учебниках-хрестоматиях широко представлены произведения, насыщенные культуроведческой информацией, которые вводят учащихся в контекст культуры родного народа, отражают своеобразие быта, традиций, обычаев марийского народа, особенности его национального характера, духовые основы марийской культуры (традиции, обычаи, обряды, праздники). Таким образом, на первый план выдвигается культурологический аспект, возрастает роль изучения языка художественного произведения в процессе формирования национального и личного самосознания учащихся.

На восприятие и усвоение этнокультуроведческой информации направлен и методический аппарат учебников-хрестоматий, что выражается, прежде всего, в организации работы над содержанием и выразительными средствами языка художественных произведений. В этой связи в учебниках задействована методическая система работы над художественным текстом с целью формирования этнокультуроведческой компетенции учащихся. В частности, в 9 кл. при изучении повести Я. Ялкайна «*АндрийТолкын*» одним из заданий обобщающего характера является задание «Обобщите материал о быте и традиции марийского народа» [4, с. 62].

Методический аппарат учебников-хрестоматий включает такие рубрики как «Беседа, темы для сочинений», «Дополнительное задание», «Проводите исследовательскую работу», «Острый вопрос» [2, с. 56], «Проверь свои знания» [2, с. 61], «Чтобы знать»[2, с. 98]. Такая разбивка на рубрики позволяет учащимся сосредоточить внимание на проблемах изучаемого произведения и на особенностях их художественного решения. Вопросы и задания нацелены на развитие творческого начала и исследовательских навыков, а также на помощь обучающимся в самостоятельном нахождении ответа, предлагают свободное диалогическое общение учителя с учениками.

Особую группу представляют вопросы и задания на сопоставление произведений, выявление, с одной стороны, общности проблематики, нравственных идеалов, идейных позиций, с другой, – творческих особенностей в решении сходных проблем марийскими писателями. Например, «Сопоставляя ранее изученные произведения (О. Шабдара «*Кориш*», С. Чавайна «*Акпатыр*») найдите сходства в образе героев произведений» [2, с. 93].

В отдельных случаях практикуются развернутые формулировки вопросов: «Наверное, замечаете, О. Шабдар мастерски рисует картину природы с использованием подходящих речевых оборотов, с широкой опорой на лексическое богатство, обостряя события, ярче раскрывает их. Холодный зимний день – раскрывается смутное время, горестная деревенская жизнь. Объясните, а с каким событием связана картина ясного весеннего дня» [3, с. 83]. Иногда в вопросах содержатся цитаты из текста: «Объясните, как вы понимаете размышления Юкея: «Если ты, Юкей, отдашь свою жизнь в борьбе за народ, тогда искупишь свою вину» [3, с. 50]. Такие вопросы и задания акцентируют внимание учащихся, с одной стороны, на идейно-нравственных проблемах, с другой – на художественных средствах их воплощения.

Тексты, а также вопросы и задания к ним, заключают в себе идеи гуманизма, способствуют выработке у детей таких качеств как доброта, трудолюбие, честность, любовь к природе и родному краю. Например, в 5 кл. для учащихся предлагается подумать над такими вопросами, как «Почему народ Водяного называет Черным, а Пампалче – Серебряной? Как в сказке рисуется зловещий характер Водяной старухи?» [1, с. 15].

С учетом особенностей национальной школы в учебных пособиях большое внимание уделяется национальным ценностям, народным взглядам на проблему воспитания гуманистической личности, а также материалам народной педагогики. Проблемная постановка вопросов в аспекте нравственных проблем при изучении биографии писателя, в материалах по анализу художественного текста, при знакомстве с мемуарными источниками способствует активизации творческой деятельности, формированию этнического самосознания учащихся.

Авторы учитывают учебно-методическую целесообразность включения в учебники материалов межпредметных связей, взаимосвязи родной литературы с родным языком, музыкой, изобразительным искусством. В частности, в 8 кл. предлагается рубрика «Работа с картинками» [2, с. 214–216], где дается краткая информация о художнике и план работы над содержанием картины. Подобная работа ведется и при анализе художественных текстов. Например, по рассказу К. Васина «Юкей Егоров» предлагаются такие вопросы, как: События какого времени отражаются в рассказе «Юкей Егоров»? Где они происходят? Что вы знаете о пребывании Пугачева и его повстанцев на Марийской земле? При

ответах на вопросы опирайтесь на картины М.И. Авипова «Помощь уральцев Пугачеву», а также Е.Д. Атлашкиной и М.М. Васильевой «Пугачев в марийской деревне» [3, с. 52].

Особое место в литературном образовании учащихся занимает изучение теоретико-литературных понятий. Литературоведческий материал в учебных хрестоматиях предлагается в самостоятельных статьях на доступном для учащихся материале. Определения по тем или иным теоретико-литературным понятиям даются с опорой на конкретные художественные тексты. При этом авторы стараются соблюдать принцип преемственности в подаче теоретико-литературных понятий (принцип углубляющейся повторяемости от класса к классу, переход от наиболее простых теоретических сведений к сложным теоретическим обобщениям, от частных проблем к общим и т. д.).

При формировании теоретико-литературных понятий авторам можно предложить следующие рекомендации:

– целесообразно в конце каждой теоретической статьи помещать вопросы, проверяющие ее правильное понимание, и задания по самостоятельному анализу художественного текста или его части, содержащего анализируемые теоретические вопросы;

– вопросы, касающиеся теоретико-литературных понятий при изучении марийской литературы, должны соотноситься с аналогичными вопросами при изучении сходных понятий по русской литературе;

– развитие речи школьников за счет расширения лексики путем включения в активный словарь теоретико-литературных терминов;

– развитие самостоятельности мышления школьников путем включения в учебники заданий для самостоятельного анализа учениками несложных художественных произведений, обучение этим умениям по образцам, предлагаемым в учебниках;

– включение сопоставительного материала (тем, идей, образов, эстетических особенностей произведений), позволяющего сравнить сходные по тематике и идейной концепции произведения родной, русской литератур, литератур народов РФ, чтобы путем сопоставления ярче показать национальное своеобразие произведений марийских писателей.

Основной недостаток учебных хрестоматий по марийской литературе для основной школы – это несоответствие их структуры и содержания «Примерной программе по марийской литературе для основной школы». Если в программе предложен новый культурологический подход, который в условиях национальной школы реализуется в диалоге родной и русской литератур, а также литератур народов РФ и зарубежной литературы, то в учебных хрестоматиях в связи с отсутствием рекомендованных программой этих произведений данный подход не соблюдается.

В целом структура и содержание учебной программы, учебников-хрестоматий и учебных пособий по марийской литературе для основной общеобразовательной школы способствуют развитию у учащихся интереса к чтению родной литературы как к средству идейно-нравственного и эстетического воспитания школьников, развитию их знаний в области родной литературы и родного языка, повышению уровня этнокультурного и культурологического образования в целом.

### Литература


1. *Иванова Е.М.* Марий литератур: Визымшекласслаnучебник-хрестоматий / Е.М. Иванова, Т.Н. Воронцова. – Йошкар-Ола: Марий кн. савыктыш, 2005. – 176 с.
2. *Кузнецов В.В.* Марий литератур: 8 классланучебник-хрестоматий / В.В. Кузнецов, Н.В. Кузнецова. – Йошкар-Ола: Марий кн. савыктыш, 2008. – 220 с.
3. Марий литератур: 7 классланучебник-хрестоматий / П.А. Апакаевден А.Т. Тимиркаевямдыленыт. – Йошкар-Ола: Марий кн. савыктыш, 2008. – 256 с.
4. Марий литератур: 9 классланучебник-хрестоматий / А.П. Апакаевден Г.Н. Бояринова ямдыленыт. – Йошкар-Ола: Марий книга савыктыш, 2011. – 312 с.
5. *Михайлов В.Т.* Марий литератур: Тӱншколлан примерный программе / В.Т. Михайлов, П.А. Апакаев. – Йошкар-Ола: Марий образований ин-т, 2014. – 100 с.



**Ә.Р. Мотыйгуллина**
Идел буе дәүләт физик тәрбия,
спорт һәм туризм академиясе, Казан


## ФОАТ ГАЛИМУЛЛИННЫҢ ФӘННИ-МЕТОДИК ЭШЧӘНЛЕГЕ


**А.Р. Мотигуллина**
Поволжская государственная академия
физической культуры, спорта и туризма, Казань


## НАУЧНО-МЕТОДИЧЕСКАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ФОАТА ГАЛИМУЛЛИНА


**Аннотация**. В статье освещается многолетняя научно-методическая работа профессора Ф.Г. Галимуллина. Также систематизируются все научно-

педагогические статьи, анализируется вклад ученого в развитие литературоведческой и научно-методической мысли с середины XX века до наших дней.

**Ключевые слова:** развитие методической мысли, учебник-хрестоматия, обзорные темы, монографические темы, методическое наследие.

**Abstract.** The article highlights the multi-year scientific and methodological work of Professor F.G. Galimullin. Also, all scientific and pedagogical articles are systematized, the contribution of the scientist to the development of literary and scientific-methodological thought from the middle of the twentieth century to the present day is detailed.

**Keywords:** development of methodological thought, textbook-anthology, review topics, monographic topics, methodological heritage.

Әдәби иҗат, тәнкыйть, сәнгатьле сүз, фәнни тикшеренүләр өлкәсендә эшләп, әсәрләр иҗат иткән, күпсанлы мәкаләләр, китаплар язган, сүз җегәрен аңлап, башкаларга җитерүнең юлларын эзләп тапкан әдәбият галиме Фоат Галимулла улы Галимуллин үзенең түгәрәк датасын билгеләп үтә. Гомер юлын мәдәният хезмәткәре булып башлаган кешенең әдәбият дөньясына килеп керүе, шунда көчен-куәтен салып эшләве эзлекле күренеш буларак күзаллана.

Галим Фоат Галимулла улы бик күп иҗтимагый, иҗади, сәнгати эшләрен бер якка куеп, даими рәвештә педагогик карашларын чагылдырган методик юнәлешне алгы планга куя. Аның бу эшчәнлеген берничә юнәлештә күзалларга мөмкин:

– укучыларны һәм студентларны сәнгатьле укырга өйрәтү;

– урта мәктәп өчен дәреслекләр төзү эшендә катнашу;

– укытучылар өчен әсбаблар язу, җыентыклар чыгару, мәкаләләр бастыру;

– студентларга әдәбиятны үзләштерү өчен язылган программалар, ярдәмлекләр, кулланмалар эшләү;

– даими рәвештә Татарстанда һәм чит өлкәләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту белән кызыксынып, өйрәнеп тору һ. б.

Әгәр аның үткән тормышына күз салсак, тормыш сәхифәләренең сәнгать, мәдәният белән бәйләнешен күрәбез. Башта Кукмара районының Арпаяз авылында клуб мөдире, аннары район комсомоллары белән җитәкчелек итү, районда инструктор, район мәдәният йорты директоры вазифаларын башкарганнан соң, Татарстан радиосы дикторы, Казан дәүләт педагогия институты мөгаллиме. Әмма бу күчеп йөрүләр шуның белән төгәлләнә. Калган гомерен студентларга белем бирүгә, яшь буын өчен татар әдәбияты укытучылары әзерләүгә багышлана.

Әдәбият фәне тирән әзерлекле булуны, күп аралашуны, яңа язылган әдәби әсәрләр белән танышып баруны, гомумән, даими рәвештә эзләнүдә булуыны

сорый. Фоат Галимуллович көнне-төнгә ялгап әдәбият сөючеләр белән очраша, Татарстандагы һәм районнардагы барлык чараларда катнаша. Театр, концерт залларындагы һәр яңа тамашаны калдырмый.

Шулай да әдәбият галиме булып танылуда аның педагогик осталыгы, тел куәсе, фәнни-методик юнәлештәге эшчәнлеге төп рольне башкара. Итәгатьле, тыныч табигатьле Ф. Галимуллинның фәнни-методик эшчәнлегенең башлангычы гамәли юнәлештә әдәбиятны укыту өчен киңәшләргә, күрсәтмәләргә бәйле җыентык, мәкаләләрдә чагылыш таба. Аеруча үтемле, күңелен салып эшләгән өлкәсе – сәнгатьле сөйләмгә өйрәтү, нәфис сүзнең нечкәлеген бәяләргә юл күрсәтү иде [4], [5].

Гомерен югары уку йортында белем бирүгә багышлаган кешенең фәнниметодик эшчәнлегенең икенче, әмма бик әһәмиятле ягы – студентларга лекцияләр уку, гамәли дәресләр уздыру барышында әдәби барышка бәя бирү, аерым язучылар иҗатына күзәтү ясау, аларның стиль үзенчәлекләрен, образлы фикерләү сәләтен күрсәтү өчен тел чараларыннан оста файдалануын ачыклау. Әлбәттә монда мөгаллим-галимнең үзенең дә бәя бирү, тәнкыйди фикер үсешендә катнашуы кирәк. Бу яктан аның газета-журналлардагы күп санлы мәкаләләрен, саллы-саллы әдәби-тәнкыйди җыентыкларын, монографик күзәтүләрен билгеләп үтәргә кирәк [6]. Галим эшчәнлегендәге фәнни-методик төп, аеруча күп эшләгән юнәлешне – урта мәктәптә белем алучы укуылар өчен басылган дәреслек-хрестоматияләр, дәреслекләр һәм хрестоматияләр, уку әсбапларыннан башка күзаллап булмый.

1990 нчы еллар әдәбиятның эстетик вазифасын калкытып куйгач, аны яшь буынга тәкъдим итү, укыту алымнары, ысуллары да үзгәреш кичерде. Шул шартларда А.Г. Әхмәдуллин җитәкчелегендә бер төркем әдәбият галимнәре яңартылган әдәбият дәреслекләре төзи башлый. Борынгы, Урта гасырлар, XIX гасырны иңләгән 9 нчы сыйныф дәреслеген Ш. Садретдинов белән Х. Миннегулов төзи. 10 нчы сыйныф дәреслеге XX гасыр башы һәм 1920–1930 нчы елларны яктырта. Аны төзүдә А. Әхмәдуллин, М. Хәсәнов, Ф. Галимуллин, И. Нуруллин катнаша. Дәреслекнең күп бүлекләре Ф. Галимуллин тарафыннан языла. Галим күзәтү төсендәге темаларны да, монографик темаларны эшкәртеп чыга.

Галим тарафыннан язылган күзәтү төсендәге темалар («Гасырга аяк басканда», «Татар прозасы ирешкән уңышлар», «Яңарыш нурлары», «Балалар әдәбияты», «Иҗтимагый фикер үсеше һәм публицистика», «Әдәби тәнкыйть», «Егерменче еллар әдәбияты») әдәбиятта чорның сәяси, иҗтимагый, мәдәни үзенчәлекләрен яктыртуга юнәлтелә. Шушы ук материал эчендә бирелгән әдәби-теоретик төшенчәләр укучы аңларлык, әсәр анализы барышында файдаланырлык итеп тәкъдим ителгән.

Шунысына басым ясарга кирәк, әдәбиятка әйләнеп кайткан Г. Исхакый иҗаты беренче тапкыр Ф. Галимуллин тарафыннан мәктәп баласына тәкъдим ителә. Р. Фәтхрахманов тарафыннан Ф. Әмирхан, Г. Исхакый иҗатын бирүдә эзлеклелек сакланмавы билгеләп үтелсә дә, бу укучыга барып җиткән беренче шәрехләү аерым игътибарга лаек.

Дәреслектә Г. Исхакый биографиясе, тормыш сәхифәләре, иҗаты эзлекле күздән кичерелә. Аның прозаик һәм драматург буларак эшчәнлеге «Кәләпүшче кыз», «Бай углы», «Өч хатын белән тормыш», «Ике гашыйк» әсәрләренә бәя аша дәлилләнә. Әдипнең «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре «яңа әдәбиятка нигез салучы» буларак ачып бирелә. Әсәр геройларына бәя укучыны кызыксындырырлык итеп, татар халкы язмышын күрсәтүнең көтелмәгән яктан тәкъдим ителешенә басым ясала [1; 21–62].

Әдипнең тормышы һәм эшчәнлеге билгеле бер эзлеклелеккә салынган материал укучы өчен генә түгел, ә әдәбият укытучылары, хәтта вузда әдәбият тарихын өйрәнүче студентлар өчен дә бердәнбер күп кулланмага әверелә.

Унынчы сыйныф дәреслегенә кертелгән Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Нәҗип Думави, Һади Такташ иҗатларына багышланган темалар эзлекле, куллану өчен уңайлы, салынган мәгълүматның эчтәлекле булуы белән аерылып торалар.

Әдипләр иҗатын монографик планда өйрәнү тормыш сәхифәләрен ачуны, берничә әсәргә бәя бирүне, аның әдәби барышта урынын билгеләүне таләп итә. Фоат Галимуллович тарафыннан язылган темалар әдипнең шәхси язмышын тирән ачу белән аерылып тора. Әйтик, Һади Такташның беренче тапкыр тәпи йөрүен, сөйләшә башлавын, әти-әнисенең белемле булуын, авыл мәдрәсәсе белән генә чикләнмичә Пешләдә укуы тәвсилле языла. Шунда шагыйрь татар әдәбияты белән таныша, Г. Тукай, С. Рәмиев шигырьләрен өйрәнә, ятлый, сөйли. Галим шагыйрь шәхесен ачу барышында истәлекләрдән уңышлы файдалана. Монда Һ. Такташның балачагын тәфсиллерәк күрсәтү өчен язучы Кәрим Әмиринең сүзләре китерелә: «Унике-унөч яшьлек кечкенә Адюк мәктәптә чакта шигырь сөйләргә яратса, зурайгач та шулай булды. Такташ булгач та бик күпләрне үзенә каратты” [1; 307].

Ф. Галимуллин 11 нче сыйныф дәреслегенең дә кайбер бүлекләрен яза. Күзәтү темаларыннан «1940–1950 нче еллар әдәбиятында Бөек Ватан сугышының чагылышы», «Балалар әдәбияты», ә монографик темалардан Фатих Кәрим, Ринат Мөхәммәдив (А. Әхмәдуллин белән берлектә), Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллинга багышланганнары аның каләме аша үтә. Монда да галим мәктәп укучыларына әдип иҗатын өйрәнү, аңлау өчен ярдәм итәрлек анализ үрнәкләре урнаштыра. Гомумән, югары сыйныф укучылары өчен тәкъдим ителгән материал галимнәрнең әдәбиятка биргән бәясе, иҗат процессын аңлауга юл

күрсәтүе дә булып тора. XX гасыр ахырында нәшер ителгән дәреслекләрнең галимнәр тарафыннан гына язылуы күчеш чорында әдәби барышны бәяләү ягыннан үзен аклый иде.

XX гасырның 90 нчы елларында Ф. Галимуллин Ф. Хатипов белән берлектә татар мәктәпләренең 7 нче сыйныфы өчен дә дәреслек-хрестоматия төзүдә катнашты. Бу сыйныф балалары өчен программа да уңышлы төзелгән була. Шуңа күрә дәреслек-хрестоматия дә эчтәлекле, эзлекле булуы белән аерылып тора. Дөрес, беренче вакытта кайбер әсәрләр балаларның яшь һәм әдәби үсеш үзенчәлекләренә туры килмәве сәбәпле, башка әсәре белән алмашынды (К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» драмасы башка проза әсәре белән алыштырылды).

Бу елларда рус мәктәбенең татар төркемнәренә өчен чыккан дәреслекнең фәнни редакторы Ф.Г. Галимуллинны була. Алар дәреслек авторлары З.Н. Хәбибуллина, Х.Г. Фәрдиева белән берлектә дәреслек-хрестоматияләр төзеп, мәктәп балаларына тәкъдим итеlә [7]. Аның бу өлкәдәге эшчәнлегенең файдасы безгә дә тиде. 2002–2003 нче елларда рус мәктәбендә укучы рус телле балалар өчен тәҗрибәле мөгаллимә И.М. Ибраһимова белән төзегән «Сынап карау программалары»ның да фәнни редакторы Ф.Г. Галимуллин булды [15].

Шул рәвешле, Ф.Г. Галимуллин берничә дистә еллар дәвамында мәктәп дәреслекләрен төзү эшендә катнаша. Бу юнәлештә туплаган мәгълүматын вузда әдәбият укытучыларына белем бирү барышында да куллана. Моннан тыш ул югары уку йорты галимнәре тарафыннан язылган күләмле хезмәтләрне өйрәнү, аларга бәя бирү, киң катлау укучыларга фәнни казанышларны күрсәтүгә дә зур игътибар бирә [13], [14].

Ф. Галимуллин минем дә әдәбият укыту юнәлешенә кереп китүемдә юлбашчы булды. Ул күрсәткән юлдан барып, ике дистә ел дәвамында әдәбият укытучыларына методик фикер үсеше, әдәби әсәр белән эшләү серләре, әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү турында белем бирдем.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Фоат Галимулла улы дәреслекләр, уку әсбаплары язу белән генә чикләнми, төрле журналларга, газеталарга, аерым җыентыкларга әдәбият укытудагы заманча алымнар, ысуллар турында мәкаләләр яза, төрле дәрәҗәле форумнарда чыгышлар ясый, үз тәҗрибәсен башкаларга тапшыра.

Ф.Г. Галимуллинның фәнн-методик, педагогик эшчәнлеген вакытлы матбугатта даими басылып барган мәкаләләреннән башка күз алдына китереп булмый. Аларның күпчелеге аерым шәхесләрнең эшчәнлеге, укыту-тәрбия эшенә бәя бирүгә багышлана. Галим тарафыннан аларның хезмәтләре өйрәнелә, бәяләнә, нәтиҗәләр ясала [8]. Бу төрдәге мәкаләләрнең кайберләрендә яңа басылып чыккан китап, уку әсбабы яки ярдәмлеккә бәя бирелә [9].

Милли рухлы галим буларак Фоат Галимуллович Татарстан районнарында һәм чит төбәкләрдә яшәүче татарлар язмышы, анда татар теленә өйрәтү мәсьәләләре белән кызыксына. Моның өчен төрле төбәкләргә йөреп кыен мәсьәләрне өйрәнә. Аннары республика матбугатында проблемалы мәкалә бастырып, киң җәмәгатьчелеккә хәбәр итә [10], [11], [12].

Моннан тыш әдәбият укытуның гомуми мәсьәләренә багышланган җыентыклар төзи, аларга кереш һәм йомгак яза. XXI гасыр башында профессор Ә.Н. Хуҗиәхмәтов җитәкчелегендә мәктәп балаларына, укытучыларга файдалану максаты белән җыеп, туплап бирелгән «Мәктәп китапханәсе» сериясендә Ф.Г. Галимуллин тарафыннан күренекле әдипләр Габдулла Тукай (2002), А. Гыйләҗев (2004), Нәкый Исәнбәткә (2007) багышланган томнарны эшли.

Шул рәвешле, күренекле әдәбият галиме Ф.Г. Галимуллинның фәнни-методик эшчәнлеге гаять киңкырлы: вузда һәм мәктәптә әдәбият укытуга багышланган әсбаплар, дәреслекләр төзүдә катнаша, фәнни-методик мәкаләләр яза, уку-укытуга бәйле фәнни казанышларны даими рәвештә вакытлы матбугатта яктыртып бара.

## Әдәбият


1. Әдәбият. (XX йөз башы һәм 20 нче еллар татар әдәбияты): Унберьеллык урта мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек / М.Х. Хәсәнов, А.Г. Әхмәдуллин, Ф.Г. Галимуллин, И.З.Нуруллин; А.Г. Әхмәдуллин редакциясендә – Казан: Мәгариф, 1994. – 367 б.

2. Әдәбият. (XX йөзнең 30–90 нчы елларында татар әдәбияты): Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек / А.Г. Әхмәдуллин Ф.Г. Галимуллин, Т.Н. Галиуллин, Ф.Ә. Ганиева; А.Г. Әхмәдуллин редакциясендә. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.

3. Әдәбият. Татар мәктәпләренең VII сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия / Ф.Г. Галимуллин, Ф.М. Хатипов– Казан: Мәгариф, 1997. – 302 б.

4. *Галимуллин Ф.Г.* Мәктәптә сәнгатьле уку. Студентлар өчен уку әсбабы. – Казан: КДПИ, 1984. – 102 б.

5. *Галимуллин Ф.Г.* Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. Мәктәп укытучылары өчен методик әсбаб. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 86 б.

6. *Галимуллин Ф.Г.* Хәзерге татар әдәбиятын өйрәнү буенча методик күрсәтмәләр. Студентларга мөстәкыйль әзерләнү өчен. – Казан: КДПИ, 1990. – 46 б.

7. *Галимуллин Ф.Г.* Рус мәктәпләренең X классында татар әдәбияты дәресләрен якынча планлаштыру // Мәгариф. – 1991. – № 9. – Б. 23–24.

8. *Галимуллин Ф.Г.* Шәхес, язмыш, хезмәт. Өлкән укытучы Габдрахман Хәмидов эшчәнлеге турында // Мәгърифәт. – 1993. – 26 июнь. – Б. 4.

9. *Галимуллин Ф.Г.* Тел ачкычы (Фираз һәм Чулпан Харисовларның «Мой первый татарский словарь» китабына бәяләмә) // Шәһри Казан. – 1997. – 17 январь. – Б. 4.

10. *Галимуллин Ф.Г.* Әле соң түгел, нәкъ вакыты (Арча мәктәпләрендә туган теле-безне һәм әдәбиятыбызны укытудагы кимчелекләр турында) // Ватаным Татарстан. – 1993. – 16 июль. – Б. 3.

11. *Галимуллин Ф.Г.* Хафаланып кайттык Чиләбедән: өлкәдә татар телен һәм әдәбиятын укытуны оештыруның мөһим мәсьәләләре турында // Шәһри Казан. – 1994. – 10 февраль. – Б. 3, 4.

12. *Галимуллин Ф.Г.* Җанга ятышлы адым: Пенза өлкәсендә татар теле һәм әдәбиятын укытуның торышы // Ватаным Татарстан. – 1994. – 26 август. – Б. 6.

13. *Галимуллин Ф.Г.* Җитди фәнни ачыш (Э. Галиеваның «Татар әдәбияты белемендә культура-тарих мәктәбе»нә бәя (2002) // Фәнни Татарстан. – 2002. – №2. – Б. 94 – 96.

14. *Галимуллин Ф.Г.* Шәркый рухыбыз тамырлары (Х. Миңнегуловның «Татар әдәбияты һәм Шәрык классикасы» китабына бәя (1993) // Казан утлары. – 1995. – № 1. – Б. 178–180.

15. *Мотигуллина А.Р., Ибрагимова И.М.* Экспериментальная программа по татарской литературе для русских школ (Обучение русскоязычных учащихся) – Казань: Изд. Просвещение. –2003. – С. 36–61.

**Г.Н. Мухарлямова**
Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова АН РТ, Казань

# ВЫРАЗИТЕЛЬНОЕ ЧТЕНИЕ КАК СРЕДСТВО УСИЛЕНИЯ ЭМОЦИОНАЛЬНОСТИ УРОКОВ РОДНОЙ (ТАТАРСКОЙ) ЛИТЕРАТУРЫ

**Аннотация.** Выразительная речь и выразительное чтение являются одними из наиболее эффективных средств усиления эмоциональности в процессе преподавания родной литературы. Без выразительного чтения правильно понять и усвоить литературное произведение сложно, так как оно является органической частью художественной литературы, эстетики. Выразительное чтение помогает проникнуть в самое ядро, суть произведения, понять мысли, поступки, чувства, переживания героев.

**Ключевые слова:** родная (татарская) литература, выразительное чтение, выразительная речь, эмоциональность, коммуникативная компетенция.

**Abstract.** Expressive speech and expressive reading are among the most effective means of enhancing emotionality in the process of teaching native literature. Without expressive reading, it is difficult to properly understand and assimilate a literary work, because expressive reading is an organic part of fiction, aesthetics. Expressive reading helps to get into the very core, the essence of the work, to understand the thoughts, actions, feelings, experiences of the characters.

**Keywords:** native (Tatar) literature, expressive reading, expressive speech, emotionality, communicative competence.

Создавая психологическую атмосферу на уроке родной литературы, предполагающую эмоциональную настроенность, можно добиться от учащихся активного самостоятельного усвоения новых знаний. Для этого необходимо эмоционально изложить новый материал. Одним из основных средств повышения эмоциональности на уроках литературы является выразительная речь и выразительное чтение литературных произведений. Действительно, «звучащее слово гораздо лучше воспринимается, чем напечатанное» [Найденов, 1969: 73]. Кроме того, «слово живет в звуках голоса, в этом его природа, и поэтому рассказ и декламация имеют все законные права на внимание словесника» [Рыбникова, 1985: 147].

Следует различать два понятия – выразительное чтение и выразительная речь. Учитель на примере своей речи добивается выразительного чтения учащихся, совершенствуя тем самым их речь.

Первый этап изучения литературного произведения связан с выразительным чтением, «чтобы оно воплотилось в звуке голоса музыкально и логически» [Рыбникова, 1985: 147], когда происходит более полная и точная передача мыслей автора, его замыслов, где мы опираемся на средства выразительности, которые уже есть в самом литературном произведении. «Выразительно прочесть произведение – значит найти в устной речи средство, с помощью которого можно правдиво, точно, в соответствии с замыслом писателя, передать идеи и чувства, вложенные в произведения» [Горбушина, 1965: 3]. Кроме того, учащиеся через чтение вслух могут проникнуть в самое ядро, суть произведения, где есть свои герои со своими мыслями, поступками, чувствами, переживаниями. У них дети учатся жить, находят ответы на свои вопросы. Чтец отвлекает их от жизненных проблем, создает другой мир, увлекает, через художественное слово он воздействует на их эмоции, вызывает искренние чувства, живой интерес, стремление к действию. «Если при чтении текста рождается представление образности произведения, такое чтение оказывает сильное влияние на слушателей, затрагивает струны их сердца, способствует рождению у них глубокого волнения и мыслей» [Нигматуллин, 1968: 4]. В это время должны сохраняться

тон и стиль писателя, композиция произведения, его эмоциональная окраска. Выразительное чтение «всегда включает в себя отношение автора к изображаемым им явлениям жизни, его оценку явлений, идейно-эмоциональное их осмысление» [Найденов, 1969: 73]. Чтобы произведение было «как можно лучше понято слушателем, эмоционально воспринято, чтец использует весь комплекс выразительных средств: главным образом интонацию, в известной степени мимику и жест» [Горбушина, 1965: 5].

Таким образом, выразительное чтение преследует следующие цели: достижение глубокого понимания содержания, основной идеи произведения; способствование представлению учащимися образов произведения; возможность прочувствовать через себя всю гамму чувств и эмоций, данных в произведении, передать их слушателям.

До чтения литературного текста детям, учитель сам должен осмыслить его, проникнуть в идейный и художественный смысл произведения, найти его пафос, подумать над тем, какие эмоции и чувства может вызвать то или иное произведение. Ведь выразительное чтение – «это, прежде всего, эмоциональное чтение. Его задача – влиять на разум человека не впрямую, а через психику, говоря другими словами, это обучение читателя, слушателя не только с идейной стороны, но и с эстетической, т. е. переживать такие чувства как восхищение, презрение, радость, горе, любовь, ненависть и др., уметь видеть и различать прекрасное» [Нигматуллин, 1968: 13]. М.А. Рыбникова, считая выразительное чтение одним из самых важных факторов в системе литературного чтения, пишет: «Стремясь донести произведение до сознания учащихся, учитель старается прочитать его перед классом как можно ярче, эмоциональнее, художественнее, выразительнее» [Рыбникова, 1985: 147]. Конечно, каждый учитель литературы должен стремиться к этому.

Итак, чтобы чтение было выразительным, оно должно в первую очередь доносить до учащихся определенные эмоции и чувства. Но по системе К.С. Станиславского, тонкость и глубина человеческого чувства не поддаются техническим приемам [Станиславский, 1938]. Действительно, учитель может дать задание учащемуся читать с чувством. Однако он не понимает, что ставит перед учащимся не совсем выполнимое задание, тем самым неосознанно «подталкивает его к бесчувственной игре, к обману» [Галимуллин, 1984: 89]. Ведь мир чувств – это эмоциональная область, а чувствами нельзя руководить, «вегетативная часть эмоций не может создаваться по нашей воле» [Галимуллин, 1984: 90]. В то же время, как считает Ф. Галимуллин, «равнодушное отношение к произведению и к своей речи становится причиной появления холодной интонации», поэтому «научить выразительному чтению – это значит красиво воспитать внутренний мир будущей личности» [Галимуллин, 1994: 23].

Выразительное чтение – это «чтение текста эмоционально образно и логически правильно. Интонация связана с содержанием, идеей произведения и с задачами донесения до слушателей. Выразительное чтение активизирует восприятие текста, помогает его пережить, прочувствовать, рождает в учащихся чувство прекрасного, иными словами, является одной из ступеней анализа произведения. Оно бывает связано с интонацией, ритмом, обращает внимание на звучание слова, рождает эмоциональное волнение» [Загидуллина, 2000:80]. Кроме того, выразительное чтение – «искусство синтетическое, органически включающее в себя музыку и пение, живопись и даже элементы скульптурного изображения» [Петрова, 1969: 135].

Обучение выразительному чтению помогает воспитать, во-первых, у читающего, во-вторых, у слушателя художественный вкус, правильно воспринимать жизнь, литературу и искусство с точки зрения прекрасного, так как «человек, который может красиво читать художественные произведения с необходимой эмоцией и при разговоре с другими может излагать свои мысли интонационно правильно» [Нигматуллин, 1983: 148]. А это является одним из основных факторов формирования у учащихся коммуникативной компетенции.

Определяя роль выразительного чтения, Ф. Галимуллин пишет: «На каждом уроке, в объеме и степени, которые позволяет тема, учитель обязан найти время для выразительного чтения. Как для понимания музыки необходимо прослушивать ее несколько раз, так и для того, чтобы почувствовать звучание слова, если так можно сказать, его музыку, почувствовать красоту литературного произведения, нужно выработать навыки выразительного чтения и выразительной речи» [Галимуллин, 1984: 5]. Очень важно, чтобы эта работа велась параллельно с определением чувств и переживаний, имеющих место в литературном произведении.

Рассмотрим на конкретном примере. Так, стихотворение великого татарского поэта Г. Тукая «Пар ат» («Пара лошадей») проникнуто многообразными чувствами, которые можно выявить в процессе выразительного чтения данного произведения. «Лирика передает впечатления, переживания, настроения, мысли и чувства, которые возникли в душе поэта под влиянием тех или иных жизненных обстоятельств. Другая ее особенность – многозначность поэтического слова, которое в стихе является образом. Поэтическая мысль всегда эмоциональна, так как автор воспринимает мир обостренно, личностно. Переживания могут принадлежать как самому поэту, так и другим лицам» [Шелестова, 2016: 70]. Здесь поэт – лирический герой – переживает эти чувства в связи со своим возвращением в Казань. Сам тон стихотворения напоминает равномерную скачку лошадей:

Лошадей в упряжке пара, на Казань лежит мой путь,
И готов рукою крепкой кучер вожжи натянуть.
Свет вечерний тих и ласков, под луною все блестит,
Ветерок прохладный веет и ветвями шевелит… (Тукай, 1986: 54).

Поэта одолевают разные мысли и чувства: то он грустит, волнуется, то радуется встрече, то его одолевает страх перед неизвестностью, он чувствует некоторое беспокойство, тревогу, но в то же время он предается мечтаниям, в его душе просыпается надежда, он стремится к своей цели. Все указанные здесь чувства, можно определить в процессе чтения стихотворения. В связи с этим можно предложить следующие вопросы: 1. Что описывается в первой части стихотворения? Как чувствует себя лирический герой? Волнуется ли он, или же он, напротив, спокоен? 2. Как изображена природа этого края?3. Как меняется настроение лирического героя в четвертой строфе? Какие мысли и чувства его одолевают? С каким чувством должны произноситься эти строки? 4. К кому герой обращается в пятой-шестой строфе? Какими чувствами проникнуты эти строки стихотворения? 5. Почему тоскует лирический герой? В чем причина этой тоски? 6. Какой страх одолевает героя? Чего он боится? В чем причина его тревоги? С какой интонацией нужно читать эту часть стихотворения? 7. В какой строфе чувства резко меняются? С чем это связано? С какой интонацией нужно читать слова кучера и слова лирического героя? 8. Какие мысли и чувства наполняют душу главного героя в конце стихотворения?

Все эти вопросы могут содействовать выяснению чувств лирического героя, способствуя в то же время возникновению тех же чувств у учащихся в процессе чтения стихотворения.

При чтении произведений прозы выразительное чтение также помогает вникнуть в содержание произведения, найти его идею, прочувствовать жизнь героев, научиться сопереживать им, понять их мысли и чувства, мечты и желания. Так, на уроках родной (татарской) литературы при изучении главы из повести Ш. Камала «Акчарлаклар» («Чайки») следует обратить внимание на следующие моменты. Несмотря на то что здесь описывается нелегкая судьба простого народа, несправедливость по отношению к нему, с другой стороны, именно здесь мы находим всю гамму чувств и переживаний героев произведения, связанных со страшными событиями на море. Писатель мастерски описывает бушующее море, волнение людей, их смелость, решительность и стойкость. В отрывке много мгновений, раскрывающих переживания, чувства людей, это и опасения за свою жизнь, безвыходность положения, это и риск, и смелость и отвага.

Важно донести до учащихся все эти моменты в соответствии с тем, как показывает их автор произведения. Этому может способствовать выразительное

чтение. В связи с этим целесообразно будет предложить учащимся прочитать отрывок по ролям, с целью раскрыть характер каждого отдельно взятого героя. Прежде всего, здесь нужно охарактеризовать каждого персонажа, участвующего в диалоге. Это поможет представить учащимся человека, чьим голосом он будет говорить и найти правильную интонацию в отдельной реплике. Особое место отводится словам автора, которые занимают большую часть отрывка. Слова автора помогают сохранить и воспроизвести тон, который присутствует в произведении. Кроме того, здесь очень много описаний природы, которые отражают настроение людей, что также немаловажно.

Таким образом, выразительное чтение текста помогает учащимся живо, наглядно и эмоционально представлять себе образы и картины, данные в художественном произведении, раскрывает красоту произведения, его смысл и эмоциональную окрашенность.

### Литература

1. *Галимуллин Ф.Г.* Аһәңле сүз һәм шәхес тәрбияләү // Мәгариф, 1994. – № 5. – Б. 20–24.

2. *Галимуллин Ф.Г.* Мәктәптә сәнгатьле уку. – К.: Тат.кит. нәшр., 1984. – 102 б.

3. *Горбушина Л.А.* Выразительное чтение и рассказывание учителя. – М.: Просвещение, 1965. – 160 с.

4. *Заһидуллина Д.Ф.* Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 336 б.

5. *Найденов Б.Г.* Выразительность речи и чтения. – М.: Просвещение, 1969. – 264 с.

6. *Нигъмәтуллин Ә.З.* Сәнгатьле укырга өйрәник. – К.: Тат. кит. нәшр., 1968. – 174 б.

7. *Нигъмәтуллин Ә.З.* Урта мәктәптә татар әдәбиятын өйрәнүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1983. – 232 б.

8. *Рыбникова М.А.* Очерки по методике литературного чтения. – М.: Просвещение, 1985. – 288 с.

9. *Шелестова З.А.* Выразительное чтение в школе и вузе. – М.: МПГУ, 2016. – 210 с.

**Е.А. Найденова**
Федеральный институт родных языков народов РФ, Москва

# ЭТНОКУЛЬТУРНОЕ И ЯЗЫКОВОЕ РАЗНООБРАЗИЕ РФ В УЧЕБНЫХ КОМПЛЕКТАХ ДЛЯ НАЧАЛЬНОЙ ШКОЛЫ «НАРОДЫ РОССИИ: ДОРОГА ДРУЖБЫ», «ЛИТЕРАТУРА НАРОДОВ РОССИИ»

**Аннотация.** Учебный комплект для учащихся 1–4 классов начальной школы «Народы России: дорога дружбы», выпущенный под общей редакцией академика В.А. Тишкова» (издательство «Просвещение», 2020 г.) и учебный комплект для учащихся 1–4 класс начальной школы «Литературное чтение. Литература народов России / дополнительный модуль» (издательство «Дрофа», 2014 г.) можно рассматривать как взаимодополняющие. Основной целью обоих учебных комплектов является формирование у школьников позитивной общероссийской, этнической и глобальной идентичности.

**Ключевые слова:** этническая идентичность, историко-этнографическая область, этническая информация, литература народов России, межкультурная коммуникация.

**Abstract.** Educational kit for pupils of 1–4 grades of primary school “Peoples of Russia: the road of friendship”, published under the general editorship of Academician V.A. Tishkov” (publishing house “Prosveshchenie”, 2020) and an educational kit “Literary reading. Literature of the peoples of Russia / additional module” (publishing house “Drofa”, 2014) for pupils of 1–4 grades of primary school can be considered as complementary. The main goal of both educational kits is to form a positive all-Russian, ethnic and global identity in schoolchildren.

**Keywords:** ethnic identity, historical and ethnographic area, ethnic information, literature of the peoples of Russia, intercultural communication.

В 2020 г. издательство «Просвещение» выпустило в свет учебные пособия для учащихся 1–4 классов «Народы России: дорога дружбы» под общей редакцией академика В.А. Тишкова» [Найденова Е.А., Журавлева О.Н., Мартынова М.Ю. и др., 2020]. В число авторов вошли: Е.А. Найденова (1 класс), М.Ю. Мартынова (2–3 класс), С.В. Рудник, В.И. Власенко (4 класс), О.Н. Журавлева (1–4 класс). В пособиях учебного комплекта речь идет:

– об уникальном культурном многообразии и духовной общности народов РФ;

– об интеграции лучших достижений разных культур в единую российскую культуру;

– об общности исторических судеб народов России;

– о защите общего Отечества;

– о сохранении памяти предков;

– об уважении самобытных традиций и языков населяющих Россию народов;

– о сохранении национальных языков, о русском языке как о государственном языке РФ;

– об опыте межкультурного и межрелигиозного общения;

– о роли государства в укреплении дружбы между народами;

– об укреплении чувства патриотизма, гражданской идентичности;

– о предупреждении межнациональных конфликтов.

Дети знакомятся с удивительным миром этнографии. Благодаря введению в методические материалы к пособию для 1 класса стихотворения-игры «Что означает слово “народ”» [Найденова Е.А., 2015], младшие школьники узнают о ведущих признаках народа-этноса (по теории Ю.В. Бромлея): название, язык, антропологический тип, этническая территория, культура, этническое самосознание. Понимание значения слова «этнос», умение выделять его составляющие, владение основами межкультурной коммуникации уменьшает степень риска формирования у детей негативных типов этнической идентичности, нередко основанных на манипуляции эмоциональной сферой человека, связанной с его этничностью [Стефаненко Т.Г., 1999].

Несколькими годами ранее в издательстве «Дрофа» был выпущен учебный комплект для учащихся 1–4 классов начальной школы «Литературное чтение. Литература народов России / дополнительный модуль» с похожей направленностью (автор концепции учебников для 1–3 классов – Е.А. Найденова, автор концепции учебника для 4 класса – Р.З. Хайруллин) [Найденова Е.А., Хайруллин Р.З., Чумакова Е.А и др., 2014].

Два указанных учебных комплекта можно рассматривать как взаимодополняющие. Фольклорные тексты, рассказы и стихи выдающихся национальных писателей, представленные в учебном комплекте «Литературное чтение. Литература народов России / дополнительный модуль» (далее – «Литература народов России»), могут стать яркой иллюстрацией тем, затронутых в учебных пособиях комплекта «Народы России: дорога дружбы». Знакомясь при изучении этих тем с произведениями национальных писателей, насыщенными этнографической информацией и личностным отношением авторов – носителей культуры, дети еще раз «проживут» их, пропустят через себя.

Учебные пособия для 1 класса в обоих комплектах структурируются с опорой на классификацию этносов РФ по историко-этнографическим областям (географическую) и предполагают работу с картой. «Историко-этнографическими

областями называются территории, где в результате длительного соседства народы, порою разные по происхождению, переняли друг у друга элементы культуры» [Пименов В.В., 1994]. К сожалению, объем того и другого учебных пособий, учитывающий возрастные особенности первоклассников, не смог вместить в себя все административные субъекты РФ и обеспечить знакомство детей с культурой всех российских этносов (численность российских народов превышает 190). Однако обращение к классификации народов РФ по историко-этнографическим областям помогло авторам показать общие элементы в этнических культурах, выделить универсальное и специфическое в них. Опора на нее будет содействовать формированию у младших школьников целостного образа большой страны с разнообразной природой, поможет познакомить их с историческим и современным опытом приспособления людей к особым природно-климатическим условиям регионов. В ситуации необнаружения детьми в содержании пособия рассказа о своей малой родине (в частности, о субъекте РФ, в котором находится их образовательное учреждение), авторы показывают способы выхода из нее. Данный факт надо интерпретировать ребятам как проявление особого доверия к ним и приглашения к сотворчеству – проектной деятельности по сбору материалов и написанию в дополнение к имеющимся разделам своего рассказа о регионе и его народах.

Главными персонажами пособия для 1 класса в учебном комплекте «Народы России: дорога дружбы» выступают ровесники учащихся – представители разных национальностей, приехавшие в Москву на Праздник Дружбы. Вымышленные персонажи предлагают детям присоединиться к этому мероприятию. В ходе изучения разделов пособия идет последовательное представление гостей Праздника Дружбы, приехавших из разных уголков России – от Дальнего Востока до Калининграда (с востока на запад, вслед за солнцем): Чукотка, Камчатка, Сахалин, Сибирь, Предуралье, Поволжье, Северный Кавказ, Центральная Россия, европейский север и северо-запад РФ. При этом в соответствующие места карты добавляются фигурки персонажей. Задача всех участников праздника – рассказать о своей малой родине в ее сегодняшних реалиях. Каждый такой рассказ, идущий от первого лица, является визиткой региона, содержащей сведения о местных природно-климатических условиях, главных достопримечательностях, о проживающих на его территории этносах, об их традициях, о событиях, судьбоносных как для региона, так и для страны в целом (например, Великая Отечественная война). Особое внимание уделяется приветствиям детей на родных языках (чукотском, ительменском, нанайском, якутском, ненецком, татарском, башкирском и др.), расшифровке значения национальных имен.

В книге для 1 класса учебного комплекта-побратима «Литература народов России» главным принципом в отборе фольклорных произведений,

прозаических текстов и стихов является разнообразная природа России, любовь к родной земле, традиционные хозяйственные занятия, связанные с окружающей природой и формирующие на протяжении веков культуру народов. В сегодняшнем глобальном мире понятие «родина» часто трансформируется, но осознание школьниками того, что край, где живешь, надо знать, любить и стараться быть для него полезным, важно. Эта мысль доносится им через произведения таких авторов, как Ю. Анко (эскимосская литература), А. Тымнечайвун (чукотская л-ра), Г. Поротов (ительменская литература), А. Дятала (нанайская литература), В. Санги (нивхская литература), Ю. Шесталов (литература манси), О. Аксенова (долганская литература), М. Юдалевич (алтайская литература), Салават Юлаев (башкирская литература), С. Чавайн (марийская литература), Д. Кугультинов (калмыцкая литература), Н. Хубиев (карачаевская литература), З. Александрова (русская литература), А. Волков (карельская литература) и др. Большое внимание в пособии уделяется проблемам двуязычия – использованию родного языка и русского (общегосударственного) языка.

В пособии для 2 класса учебного комплекта «Народы России: дорога дружбы» географический принцип структурирования (по историко-этнографическим областям) сменяется «сезонным» – его стержневой темой становится современное бытование традиционных календарных праздников народов России, часто основанных на их религиозно-мифологических представлениях. Среди этих праздников выделяются те, что приходятся на *зимний период:* Новый год, Цаган Сар и Сагаалган; *весенний период*: Масленица, Навруз, Пурим, Пасха, День рождения олененка, Ураза Байрам (подвижный), Сабантуй, Гербер; *осенний период*: Рош а-Шона, праздники урожая и др. Детям предлагается стать участниками песен, танцев, национальных спортивных игр-состязаний, послушать игру на музыкальных инструментах, сказки народов России о дружбе.

В учебном комплекте «Литература народов России» этой теме также уделяется значительное внимание. О народных праздниках и сопровождающих их песнях, танцах, играх и т. д. учащиеся узнают, изучая литературные тексты, представленные в книге для 3 класса. Кроме того, из них можно почерпнуть сведения о народных ремеслах, промыслах. Тему праздников здесь раскрывают стихи и проза: З. Неклюмкиной (эскимосская литература), А. Кымытваль (чукотская литература), В. Коянто (корякская литература), В. Новикова (якутская литература), А. Кривошапкина (эвенская литература), Р. Минуллина (татарская литература), Мусы Гали (башкирская литература), Р. Гамзатова (аварская литература), Г. Юдина (русская литература) и др.

Если же обратиться к пособию для 3 класса учебного комплекта «Народы России: дорога дружбы», то в нем традиционные ремесла и промыслы народов России являются стержневой темой. В основе структуры данного пособия

лежит классификация ремесел и промыслов по материалу и технике. Авторы приглашают детей побывать на ярмарке мастеров. В результате ребята оказываются в музее под открытым небом, где можно заглянуть в каждый дом – ярангу, чум, русскую и татарскую избу, курень, юрту, саклю, а еще узнать, чем эти жилища отличаются друг от друга. Щедрые хозяева в национальных костюмах угощают их традиционными блюдами и показывают игрушки, в которые играли дети их народов в древние времена.

В учебном комплекте «Литература народов России» категории *дом и семья* – главные в книге для 2 класса. Они рассматриваются авторами как безусловная ценность. Младшие школьники усваивают мысль, что дом, это не только стены, но и люди, живущие в нем. О традиционных жилищах, кухне, транспорте, образе жизни детей – представителей разных народов, их играх и игрушках, отношениях между собой и со старшим поколением, о способах передачи традиционных знаний между поколениями им рассказывают писатели. Также с помощью художественных образов учащимся приводятся примеры позитивного взаимодействия детей разных национальностей. Своими знаниями и оценками происходящего с ними делятся: М. Вальгиргин, А. Кымытваль (чукотская литература), Н. Курилов (юкагирская литература), М. Приходько, О. Приходько (ненецкая литература), Л. Кокышев (алтайская литература), А. Гонтарь (еврейская литература), Б. Сыренов (бурятская литература), Муса Гали (башкирская литература), Я. Пинясов (мордовская литература), Г. Ладонщиков (русская литература), Е. Пиятеляйнен (карельская литература) и др.

В пособии для 4 класса учебного комплекта «Народы России: дорога дружбы» происходит завершение изучения курса. На первый план в нем выходит тема гражданственности, общая история многонационального российского народа, его трудовые и ратные подвиги, литература, искусство, приводятся имена и биографии людей разных национальностей, в том числе представителей литературного цеха, прославивших Россию во всем мире.

Тема гражданственности является заключительной и в учебном комплекте «Литература народов России», где она также представлена в книге для 4 класса. В соответствии с концепцией комплекта, эта тема вновь раскрывается через литературные произведения. В книге собраны произведения о национальных героях разных эпох, заслуживших общероссийскую признательность, – участниках войны 1812 года, Великой Отечественной войны, деятелях науки и искусства. Кроме того, еще раз акцентируется внимание на роли родного и государственного языков, важности ответственного отношения к большой и малой Родине.

Таким образом, в основе обоих учебных комплектов стоит «формирование позитивной общероссийской и глобальной идентичности («мы – россияне»,

«мы – граждане мира») при одновременном развитии у представителя любой национальности чувства самоуважения, мотивации к изучению родного языка, литературы и культуры, восприятия их как ценности, что выступает важной составляющей его этнической идентичности.


**Литература**

1. *Найденова Е.А., Журавлева О.Н., Мартынова М.Ю. и др.* Народы России: дорога дружбы: учебные пособия для общеобразовательных организаций (1–4 класс) / под редакцией Тишкова В.А. – М: Просвещение, 2020.
2. *Найденова Е.А., Хайруллин Р.З., Чумакова Е.А. и др.* Литературное чтение. Литература народов России / Дополнительный модуль (1–4 класс). – М: Дрофа, 2014.
3. *Найденова Е.А.* Что означает слово «народ». – М: ГАО ВПО МИОО, Этносфера, 2015.
4. *Пименов В.В.* Этнология: предметная область, социальные функции, понятийный аппарат // Этнология / под ред. Г.Е. Маркова, В.В. Пименова. – М.: Наука, 1994.
5. *Стефаненко Т.Г.* Этнопсихология / учебник для вуза. – М.: Институт психологии РАН, «Академический проект», 1999.



**Г.Ә. Нәбиуллина**
Казан федераль университеты, Казан


## ТЕЛЕВИДЕНИЕ СӨЙЛӘМЕНДӘ ЛЕКСИК-ГРАММАТИК ИНТЕРФЕРЕНЦИЯ КҮРЕНЕШЕ


**Г.А. Набиуллина**
Казанский федеральный университет, Казань


## ЯВЛЕНИЕ ЛЕКСИКО-ГРАММАТИЧЕСКОЙ ИНТЕРФЕРЕНЦИИ В ТАТАРСКОЙ РЕЧИ ТЕЛЕВЕДУЩИХ


**Аннотация.** Одним из существенных вопросов культуры татарской речи в условиях двуязычия является вопрос о границах употребления иноязычной лексики. В данной статье рассматривается проявление лексико-грамматического интерферентного влияния русского языка на татарскую речь телеведущих. Выявлено, что интерференция на лексико-грамматическом уровне приводит к следующим нарушениям языковых норм: нарушение сочетаемости слов, субституция слов неродного языка, употребление в речи русских слов вместо татарских.

**Ключевые слова:** интерференция, татарский язык, речь телеведущих, лексические нормы.

**Abstract.** One of the essential questions of the Tatar speech culture in the conditions of bilingualism is the question of the boundaries of the use of foreign language vocabulary. This report examines the manifestation of lexical and grammar interference influence of the Russian language on the Tatar speech of TV presenters. It is revealed that interference at the lexical-grammar level leads to the following violations of language norms: violation of word compatibility, substitution of words of a non-native language, the use of Russian words instead of Tatar in speech.

**Keywords:** interference, Tatar language, speech of TV presenters, lexical norms.

Телевидение, радиотарихына кереп калган шәхесләр Әминә Сафиуллина, Рөстәм Нәбиуллин, Эльмира Хамматова, Наилә Ногманова, Флера Бикмурзина, Айрат Арсланов, Камал Саттарова, Фоат Галимуллин, Тәлгат Хаматшин хәзерге буын алып баручыларга өлге, эталон булып торалар. Юрий Левитан мәктәбен узган профессиональ диктор булуыннан тыш, галим, әдәби тәнкыйтьче һәм язучы Фоат Галимуллин бүгенге телевидение, радио алып баручыларыныңсөйләм эшчәнлеге хакында болай дип белдерә: «Микрофон алдында утыручылар инде дикторлар түгел, ә тапшыру алып баручылар. Бу очракта аларга бик зур вазыйфалар өстәлә. Аларның белеме, дөньяга карашы, фикерләү дәрәҗәсе киң булырга тиеш. Алар нәкъ журналистлар дәрәҗәсендә фикерләргә бурычлы. Әзер текстны матур итеп уку гына түгел, үзеңнең карашларыңны булдырып, шуны халыкка җиткерергә омтылып сөйләргә тиеш ул» [Галимуллин: 2020]. Телевидение аша халык теленә, сөйләмгә бик күп сүзләр килеп керә. Тамашачы тапшыруларны карап, үзенә үрнәк ала. Тапшыруларда сөйләмгә куелган таләпләр сакланмаса, ул аны «шулай тиеш» дип кабул итә. Сөйләмнең дөрес, матур булуына ирешү өчен, җөмләләрне, сүзләрне гомум кабул ителгән тел кагыйдәләренә нигезләнеп урнаштыра белү һәм куллану әһәмиятле.

Бүгенге шартларда журналист иҗади осталыкның барлык чараларын җигә белергә тиеш. Шул чараларның берсе – туган тел. Журналист сүз белән эш итә, аның коралы – сүз. Тик ул катлаулы, үзенчәлекле корал. Ышанычлы, оста эш итү өчен аны җентекле өйрәнү таләп ителә. Безнеңчә, бу өйрәнү үзе үк тәртип белән оештырылырга һәм үз эченә бер-берсеннән аерылгысыз түбәндәге өлешләрне үз эченә алырга тиеш:

1) Журналисттан туган теленең сүз байлыгын фәнни нигездә төпле үзләштерү сорала, моның өчен телнең төрле чыганакларын, ягъни халыкның сөйләү телен, борынгы язма истәлекләребезне, хәзерге һәм классик язучыларыбыз әсәрләрен, рус телен җентекле өйрәнү, барлык функциональ стиль

үзенчәлекләрен һәм төсмерләрне сиземләү, туган телгә хөрмәт белән карау, аны чын-чынлап ярату таләп ителә.

2) Журналист тел гыйлемен, аның законнарын, үсү һәм камилләшү тәртипләрен, тарихын яхшы белергә тиеш.

3) Телнең профессиональ яктан бөтен нечкәлекләрен белү сорала [Низамов: 1995].

Телевидение сөйләменә куелган таләпләр, үзенчәлекләр фәндә шактый өйрәнелгән. Мисал өчен О.Б. Сиротинина, И.П. Смирнова, Л.Г. Павлова, М.М. Канчер, татар галимнәре М.З. Зәкиев, Ф.С. Сафиуллина, И.М. Низамов, Г.С. Нуриев, Р.А. Юсупов хезмәтләрен атап үтәргә мөмкин. Татар теле стилистикасы, риторика, татар грамматикасы, сәхнә теле мәсьәләләренә кагылган кайбер хезмәтләрдә дә күпмедер мәгълүмат бирелә.

Яңа Гасыр телерадиокомпаниясетелебезне үстерүдә гаять зур эш башкара. «Татарстан-ЯҢа Гасыр», «ТНВ-Планета» телеканаллары, «Болгар», «Татар», «Китап», «Тәртип» радиостанцияләре республикабызга, Россия регионнарына, БДБ илләренә, Европа һәм Азиянең күп өлешенә тарала. Телевидение, радиобөтен дөнья буйлап сибелеп яшәгән татарларның милли-мәдәни үзаңын үстерүдә зур эш алып баралар. Милли рухлы тапшырулар мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне аңларга, татар телен кулланучыларның санын, даирәсен арттырырга ярдәм итә.

Кызганыч ки, бүгенге көндә телевидение һәм радио тапшыруларында ана телебездәге дөрес сөйләм нормаларының шактый еш бозылуы күзәтелә, һәм бу, нигездә, безнең татар-урыс шартларында яшәвебез белән бәйле.

Телевидение сөйләмендә рус-европаалынмалары киң файдаланыла. Алынмалар белән эш итү, әлбәттә, уңай күренеш. Ләкин, алып баручыларыбыз сөйләменең сүзлек составы, лексик-семантик нормалары еш кына кирәксезгә рус теле сүзләре кулланылу аркасында бозыла. Тапшыруларда татар теленең тиешле төшенчәне белдерерлек үз сүзләре яки телдә алар кебек үзләштерелгән гарәп һәм фарсы алынмалары була торып та, рус сүзләрен кушып сөйләү очраклары еш күзәтелә.

Телгә бөтенләй кирәксезгә һәм урынсызга рус теленнән йөзләрчә сүзләр кертү алып баручыларның сөйләмен «чүпли». Мәсәлән, «*Бу – бәхәссез әйбер. Гадәттә, алар ияләшкән, алар карыйлар, алар аның подшивкаларын эшлиләр*; *Комплектовать итеplә балалар*; *Просто обсуждение бу; Берәр результаты бармы соң?*; *До конца өйрәнеп беттем*; *Но шулай да бу мәсьәлә гаиләдән тора; Айрат бит приемный семьядан чыгып китте*; *Башкаларның высокая кулинариясеме бу?; Нарушение ясала бит!* Монда алынма сүзләр куллануның төп принцибы бозыла. Р.А. Юсупов сүзләре белән әйткәндә, «туган телнең тиешле төшенчәне белдерә алырлык үз сүзлек хәзинәсе булганда яки үз лексик байлыгыннан

яңа сүз ясау мөмкинлеге булганда, чит тел сүзләре кулланылырга тиеш түгел» [Юсупов: 2000, 191].

Бер үк мәгънәдәге рус һәм татар сүзләрен урынсызга кабатлау очраклары күзәтелә: *Сезгә спрос бармы, гомумән ихтыяҗ бармы?Рүзәл, ихтыяҗ бар, дисең. Синең үз тирәлегеңнән чыгып караганың бармы?*

Тапшыруларны алып баручылар сөйләмендә паразит, ягъни әдәби нормага туры килмәгән сүзләр дә килеп керә. Мәсәлән, *Уртача хакы ну сезнең арзан дип әйтмәс идем*; *Ну мин шигырь язмадым Рафис аб*ый; *Ну катыкны татар гына эчми инде, башкортлар да казахлар да эчә.*

Татар теленең бөтен нечкәлекләрен белеп җиткермәү һәм аңа карата саксыз булу бик аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Тапшыруларда грамматик хаталарның китү юллары төрле.

1) Туры сөйләмдә автор сүзләрен ике тапкыр куллану очрагы:

*Ә мәдәният министры Зилә Вәлиева әйткән иде: «Фестивальне оештырганда, без мондый нәтиҗәләргә ирешербез дип уйламаган да идек», – дигән иде. Менә сез әйттегез, Кадрия ханым: «Балалар белән чаралар уздырырга кирәк!» – дидегез.*

2) Кушымчаларны куллануда хаталар очрый: *Кадрия ханым, сез гомергомергә халыкка милли үзаң тәрбияләргә тырышасыз. Менә милли үзаң тәрбияләү ...Алар белән ничек эшләргә кирәк, нинди чаралар уздырырга кирәк?; Хөрмәтле дуслар, музыкаль мизгелләргә тыңлап алыйк әле бергә*; *Шулай итеп, уникесе, унөчесе, ундүртесе көннәре ял итәчәкбез.*

3) Сөйләмнең дөрес яңгыравына ирешү өчен, җөмләләрне гомум кабул ителгән кагыйдәләргә нигезләнеп төзү, сүзләрне кирәкле тәртиптә урнаштыра белү, гомумән, синтаксик нормаларны үтәү әһәмиятле. Мондый синтаксик хаталар телевидение сөйләмендә еш күзәтелә: *Әгәр без балалар бакчасында ук сабантуй ул машина оту урыны, бу промысел урыны итеп тәрбияләсәк, безнең бу сабантуйларыбыз һәм балаларыбызның шушы сабантуйга булган фикере ничек формалашыр икән? Чын сабантуйлары һәм безнең бабаларыбыз оештырган һәм гасырлар буенча килгән сабантуйларны без күрә алырбыз микән? Син башкаруыңда җыр тыңлыйк инде, әйеме?*

Икетеллелек шартларында татар теленең сафлыгын, төзеклеген, әдәби дөреслеген, сөйләм культурасын саклау гаять әһәмиятле. Бу җәһәттән, тел сагында торучы журналистлар аеруча игътибарлы булырга тиешләрдер.

### Әдәбият

1. *Низамов И.* Уем тел очында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 287 б.

2. *Юсупов Р.А.* Икесен дә яхшы бел: Икетеллек шартларында дөрес сөйләм мәсьәләләре. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б. 15–17.

3. *Фоат Галимуллин*. «Язучылар берлеген таркатырга тырышучылардан саклап кала алды». – URL: https://intertat.tatar/news/tatar_world/24-11-2020/foat-galimullin-yazuchylar-berlegen-tarkatyrga-tyryshuchylardan-saklap-kala-aldyk-5787563.

**Ә.Н. Нәҗипова,**
филология фәннәре кандидаты, доцент

## ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ РӘИСЕ БУЛАРАК ӘДӘБИЯТ ҮСЕШЕНӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

**А.Н. Назипова,**
кандидат филологических наук, доцент

## ВКЛАД ФОАТА ГАЛИМУЛЛИНА В РАЗВИТИЕ ЛИТЕРАТУРЫ КАК ПРЕДСЕДАТЕЛЯ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ

**Аннотация.** В статье оценивается вклад Фоата Галимуллина в развитие литературы на посту председателя Союза писателей. Оцениваются достижения личности в области литературной критики.

**Ключевые слова:** исследование, национальная особенность, традиция, новый подход, концепция.

**Abstract.** The article evaluates Foat Galimullin’s contribution to the development of literature as chairman of the Writers’ Union. The individual’s achievements in the field of literary criticism are assessed.

**Keywords:** research, national peculiarity, tradition, new method, conception.

1999 ел. Җәмгыять инде дистә еллап үзгәрешләр чорында яши. Бу елның май аенда башланган Татарстан Язучылар корылтае өзелеп калды. Буталчык һәм авыр чорда берлекне әйдәп барырлык җитәкче сайланылмады. Язучылар үзләре дә шактый кыен хәлдә калдылар. Чөнки озакка сузылган тартышу бер кем файдасына да сөйләми иде. Тиз арада татар әдәби хәрәкәтенең башында тора алырдай, татар иҗтимагый аңына юл күрсәтердәй зат җилкәсенә авыр йөкне салырга кирәклеге кискен рәвештә килеп басты. «Ризалашу – Синнән, сайлау – бездән!» диләр Фоат Галимуллинны бу җитди эшкә кодаларга дип «Аккош күле»нә килгән язучылар бертавыштан. Үзенә йөкләнәчәк эшнең бөтен җитдилеген күз алдында тоткан Фоат Галимуллин менә тагын бер сынау алдында. Милләтебезнең могтәбәр кешеләренең күзе өмет һәм теләктәшлек

белән аңа төбәлгән. Ничек шуны аңламыйсың да акламыйсың инде?! Һәм әлегә кадәр дә төрле җитәкче урыннарда эшләп тәҗрибә туплаган галим-тәнкыйтьче шул ук елның 23 июлендә бу олы вазифага керешергә ризалыгын белдерергә карар кыла.

Бер срокка сайланган Фоат Галимуллин ике чакырылыш дәвамында Татарстан Язучылар берлеге рәисе вазифасын башкара.

Язучы, әдәбият галиме һәм җәмәгать эшлеклесе Фоат Галимуллинга нәкъ менә шушы кызыклы һәм кызганыч, өметле һәм аяныч елларда, иске гасыр яңа гасырга, үткән меңьеллык килгән меңьеллыкка эстафета тапшырган дәвердә, татар әдәби хәрәкәтенең башында торырга һәм аптыраšта калган татар иҗтимагый аңына юл-юнәлеш эзләшергә туры килде. Ул җитәкчелек иткән чорда галим әдәбият тәнкыйтьчесе генә түгел, ә татар әдәбияты агымы өчен җаваплы кеше дә. Шуңа да ул җитәкче булып торган елларга йомгак рәвешендә басылып чыккан «Эзләнү вакыты» дип исемләнгән мәкаләләр җыентыгы үзенең кыйммәтлелеге белән бай, тирән хезмәт булып тора. Татарстан язучылар союзында җаваплы кеше буларак Ф. Галимуллин әлеге хезмәтендә тәнкыйть мәкаләләре белән беррәттән үзенең җитәкче булып торган елларга карата нәтиҗә дә чыгара. Алай гына да түгел, үзе җитәкчелек иткән чорга анализ гына ясап калмыйча, борынгы әдәбияттан бүгенге көннәргә чаклы кызыл җеп суза. Соңгы меңьеллыктагы татар әдәбиятының үсеш дәверен билгели» [Галимуллин, 2005:3].

Язучылар берлеге рәисе итеп билгеләнгән Фоат Галимуллин әдәбиятка бары тәнкыйтьче буларак кына карый алмый инде, ул инде шул әдәбият агымы өчен җаваплы кеше дә. Проза үсеше өчен кирәкле бик көчле стимуллар да нәкъ менә ул идарә иткән чорларда барлыкка килде. Иң беренче чиратта, яңа әдәбиятның башында торган, ләкин онытылырга дучар ителгән Гаяз Исхакый мирасының әдәбиятка кайтуын билгеләп үтәргә кирәк. Фоат Галимуллин үзе рәислек иткән елларга йомгак ясап, әдәби сүз осталарының каләме милли мәнфәгатьләргә, кешенең табигый ихтиярларына инаныбрак хезмәт итә башлауларын билгеләп үтә.

Туксанынчы еллар әдәбиятын, егерменче гасырның бер генә унъеллыкларына да охшамаган, үзәнчәлекле булуы белән аерып күрсәтә Фоат Галиммуллин. «Ул – чын мәгънәсендә азат әдәбият. Социалистик реализмның тынны кысып торган кыршауларыннан арынып, күңел кушуы буенча иҗат ителә торган әдәбият. Халкыбызның олы тарихын, затлы асылын булганынча сурәтләү – шулай ук аның иң күркәм сыйфатларыннан. Кешенең күңел дөньясы, иң тирән интим хисләре матур рәвештә, шактый иркен, шул ук вакытта, халкыбызга хас булганча, тыйнак, оялчан итеп сурәтләнә торган хасияте дә – төп үзенчәлекләрнең берсе. Дини эчтәлек, кеше рухының бай катламын тәшкил иткән ислам тәгълиматына бәйле хис-кичерешләр бирелешенең торган саен

киңрәк урын ала баруы турында да шуны әйтергә мөмкин. Детектив әсәрләр турынына җинаять кылуның бөтен эзлеклелеген күрсәтүгә корылган әсәрләр барлыкка килү дә – заман билгесе», – дип бәяләмә бирә әлеге чор әдәбиятына җитәкче [Галимуллин, 2005:3].

Бу чорда Фоат Галимуллин прозада берничә теманы өстенлек итә дип саный. Алар:

1. Тарихи сәхифәләрне яктырту. Моңа Р. Әмирханның «Бәйсезлек өчен көрәш», В. Имамовның «Яшерелгән тарих», Ә. Кәримуллин, М. Госманов, С.Җ. Алишев һәм башкаларның хезмәтләре керә.

2. Тарихи теманың икенче юнәлеше – шәхес культы елларында халыкка карата кулланылган явызлыкларны күрсәтеп бирү. Бу өлештә И. Салихов, Г. Тавлин, А. Гыйләҗев, Р. Мөхәммәдиев әсәрләрендә, Р. Кәраминең «Каргышлы этаплар», Л. Бадыйкшаның «Мөртәт» әсәрләре, Р. Мостафинның һәм Р. Даутовның «Репрессияләнгән татар язучылары» дип аталган материаллары тупланган.

3. Җәмгыятьтәге җинаятьчел күренешләрнең әдәби әсәрләрдә урын алуы (детектив жанрның үсүе) М. Насыйбуллин, З. Фәтхетдинов әсәрләрендә, З. Хәкимнең «Гөнаһ» романы, Ф. Бәйрәмованың «Кара урман» әдәби-документаль романында карала, дип билгеләнә.

4. Авыл хуҗалыгы фәнендә хезмәт итүчеләр турында Ф. Зыятдиновның «Изге йорт» һәм М. Юнысның «Соңгы сулыш» әсәрләрендә табарга була, диелә бу хезмәттә.

5. Фантастик повестьләргә Ф. Латыйфи белән Р. Якушның «Тамга» исемле китаплары кертелә.

Галим тугызынчы дистәнең икенче яртысында Н. Гыйматдинова, З. Хәким, З. Зәйнуллина, Т. Галиуллин, Р. Сибатның чын мәгънәсендә талантлы каләм осталары булып танылуын һәм бу язучыларның әсәрләре сүз сәнгатенең табышы булуын күрсәтә.

Ф. Галимуллин прозаның стиле турында да кызыклы гына фикерләр әйтә. Әдәбиятның җитлеккәнлеген күрсәткән фәлсәфи-аналитик фикерләүнең фәннилеккә таба юнәлеш алуы, психологизмның төрләләнә төшүе җитди сыйфат үзгәрешләре алып килергә мөмкин дип саный Ф. Галимуллин.

Мәгълүм булганча, 1995–1999 елга кадәр Фоат Галимуллин Язучылар союзы идарәсе әгъзасы була, ә 1999–2005 Язучылар союзына җитәкчелек итә, оештыру эшләрен алып бара. Татарстан язучыларның XVI корылтае уңаеннан ясалган чыгышында татар әдәбиятының күп кенә тармакларының җайга салынуы, язучыларга уңайлы шартлар тудырылу галимнең нәтиҗәле эшчәнлеге турында сөйли.

Фоат Галиммуллин эшләгән чорда төрле дәрәҗәдәге премияләр: Г. Державин исемендәге бүләк һәм район күләмендә премияләр булдырыла.

Фоат Галиммуллин җитәкчелек иткән вакытта, язучыларның матди хәлен дә кайгыртты. Ул чорларда бик күп кенә язучы фатирлы булды. Шулай ук каләм әһелләренә акчалата да күп кенә ярдәм күрсәтелде. Фоат Галимуллин тырышлыгы белән Язучылар берлеге бинасы төзекләндерелә. Җыеп кына әйткәндә, Фоат Галимулиин җитәкчелек иткән чорда әдәбият эшчәнлеге алга китте. Яшь язучыларны барлау, туплау буенча җаваплы кешеләр билгеләү эшнең сыйфатын арттырды. Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятлары белән элемтәләр әдәбиятыбызны тулы канлы итте. Ике корылтай арасында әдәбият зур югалтулар кичерә Н. Исәнбәт, М. Мәһдиев кебек зур осталар артыннан Ә. Еники, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев кебек язучылар мәңгелеккә китеп бара. Фоат Галимуллин әдәбиятта үз урыны, үз жанры, үз йөзе булган егерме ике язучының югалтуын ачынып искә алса да, кырык бер яңа каләм әһеле килүенә сөенә.

Әдәбият тормышы тулы канлы барсын дисәк, безгә башка әдәбиятлар белән бәйләшенләрне дә ныгыта барырга кирәк. Ф. Галимуллин җитәкче булып торган елларда чит башка әдәбиятлар белән элемтә тагын да ныгыды. Истанбулда «Ауразия диологы» дип аталган журнал дөнья күрүендә татар әдәбиятчыларының да өлеше булу моның ачык мисалы. «Әлеге журналда төрле ил шәхесләренең, бигрәк тә аларның галимнәре, язучылары, сәнгать әһелләре, зыялылары якыннан аралашуы таләп ителә. Әлеге журналда Албаниядән алып Монголиягәчә булган киңлектәге илләр катнаша, алаларның саны егермедән артып китә. Алга таба тагын да ишәер дип көтелә» [Галимуллин, 2005:13]. «Ауразия диологы» журналының редакция составында Татарстаннан Ф. Галимуллинның һәм Р. Вәлиевның һәм башка язучыларның булуы куанычлы хәл.

Соңгы ун-унбиш елда әдәбиятыбызда күңелгә куаныч китергән әсәрләр байтак язылуына һәм укучыларга барып ирешүенә сөенә галим. Милләтебезнең үзбилгеләнүгә, дәүләтчелеген торгызуга, хакыйкый тарихын булдыруга омтылып хәрәкәткә килүе дә каләм көчләренең активлашуына бер сәбәп икәнлеген дәлилли.

«Чөнки ул, идеологиягә буйсынып эш итүче узгынчы тарихчылар язганча, ниндидер кыргыйлык, вәхшилекне тәшкил итүче хәл-әхвәлләр чылбырыннан тормый, менә ни өчен язучылар тарихи мәүзугларга аеруча игътибарлы булдылар», – дип тарихыбызны дөрес күз алдына китерүне мөһим аспект булуын билгели галим [Галимуллин, 2005:15]. М. Хәбибуллинның «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Сөембикә-ханбикә һәм Иван Грозный», «Батый хан һәм Ләйлә», «Атилла», Р. Батулланың «Сөембикә», Ф. Латыйфиның «Хыянәт», Җ. Рәимовның «Батырша» кебек романнары халкыбызның тарихи фикерләвендә тиешле юнәлешне тәэмин итүдә аеруча мөһим хезмәт буларак бәяләнә.

Егерменче гасырның вәхшилек чоры шәхес культы котырган унъеллыкларның афәтен күрсәтеп бирүдә үткен мәсьәләрнең берсе сыйфатында чагыла. Мисалга Г. Тавлинның «Афәт», Р. Кәраминең «Каргышлы этаплар», А. Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!», Л. Бадыйкшанның «Мөртәт», Г. Ахуновның «Идел кызы» һәм башка әсәрләрне мисалга китереп булыр иде.

Галим алда әйтеп кителгән «Эзләнү вакыты» дигән хезмәтендә йөзьеллык ахырындагы татарларның гасыр башындагы милләттәшләребездән бик нык аерылуына игътибар итеә.

1917–1980 елларда әдәби әсәрләрдә, юл араларына яшереп булса да, яшәп килүче җәмгыятькә тәнкыйть карашлары үткәрелүен тоемлый галим. Совет хакимияте елларында мондый әсәрләрне бәяләү өчен махсус иҗат ысулы буларак – тәнкыйди реализм күрсәтелә.

Бу фәнни хезмәтендә галим язучылар иҗатына да бик җитди якын килә, тирән анализлый.

Мәсәлән, Әбрар ага Кәримуллинның «Язмыш, язмыш...» дигән китабын укыгач татар халкы башыннан үткән бөтен четерекле вакыйгалар күз алдына килеп баса, – ди автор.

Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы тирән анализлана. Авторның да төп кыйбласын да игътибар итә галим. «Әйбәт гамәлләре күп иде Гариф абыйның. Иң әүвәл халыкның бәхетле, ирекле яшәвен теләде. Бу хакта борчылып язды, кызып-кызып сөйләде. Икенчедән, әдәбиятыбызның элеккеге зурлыгына ирешүен күрергә омтылды. Моның өчен, ихлас бакчачы кебек, һәр талантлы кеше турында кайгыртты. Әдәбиятның төп үз бурычын үтәвен аның саф, әдәпле кешеләр тәрбияләргә тиешлеген изге кыйбла итеп санады», – диелә мәкаләдә [Галимуллин, 2005:3].

Хәсән Сарьян иҗатын анализлаганда галим каләм әһеленең «Әткәм һөнәре» повестенда игътибарны һөнәрнең нәселдән-нәселгә күчүенә юнәлтә. Бала тәрбиләүдә тәрбиянең мөһим роленә дә басым ясап әйтелгән.

Шуңа да автор үрнәк Сәрьян Акмановлар гаиләсенә контраст итеп Нух Хәсәншиннар гаиләсен таный. Галим әлеге гаиләдәге тәрбияләрнең контрастлыгын дәлилли.

Әлеге черек әхлакны бүгенге көндә дә таба мәкалә авторы, ул әле яшәүчән, ул үзенә үрчү җирлеге эзли, кайбер очракларда таба да, – ди ул. Аларга каршы актив көрәш алып бару – безнең намус эшебез. Әсәр төбендә дә әнә шул фикер ята, дип күрсәтә Фоат Галимуллин үзенең фәнни хезмәтендә.

Мәкаләдә Х. Сарьянның телгә, аның яңгырашына, аһәңенә бик тә игътибарлы булуы әлеге әсәрендә аеруча ачык чагылуына игътибар ителгән. Язучы халкыбызның фикерләү сәнгатен тирән белеп, сөйләме һәм язма стильләрне

оста үреп, аерым кешелер сөйләмен оста бирүдә рәссамнарча эш иткән, – дип билгели галим .

Автор әсәрдә күтәрелгән тагын бер проблеманы – эчүчелекне дә күрсәтә.

Ф. Галимуллин әлеге әсәрдә татар әдәбиятында сурәтләнгән аналар янында тагын бер ананы күрә – тыйнак, тавыш-тынсыз гына үзенең тормышын җайлап алып баручы, сабыр холыклы, үзендә милли характер сыйфатларын туплаган Мәһисәрвәр ана образы ул. Ана образын Х. Сарьянның зур уңышы итеп саный ул.

Әсәрнең конфликты әхлакый планда карала. Автор әсәрдә кешенең күңел тирбәнешләрен сурәтләү үзәктә тора, – ди. Әсәр бүгенге кешенең асыл сыйфатларын эзләүдә, күңел дөньясын ачуда уңышлы бер тәҗрибә буларак танылa.

Ф. Галимуллин Х. Сарьянның гомуми эшчәнлегенә күзәтү ясый, каләм әһеле «бервакытта да эпик киңлеккә, блоклы “эре” проблемаларга алынмады» дип бәяли Х. Сарьян иҗаты турында сөйләгәндә.

Х. Сарьян, проза төрендә иҗат итсә дә, күңеле белән чын мәгнәсендә шагыйрь иде, – диелә мәкаләдә. Язучыны тел остасы буларак таный Ф. Галимуллин. Аның тел осталыгын гап-гади әйберләрне дә күңелгә кереп урнашырлык итеп образлы әйтә белүендә, – дип күрсәтә.

«Таза орлыклар» мәкаләсендә А. Гыйләҗевның «Йәгез, бер дога!», «Безнең авыл кешесе», «Үги ана яфраклары» хикәяләренә игътибар ителгән. Сүз бара торган сәнгатьчә камил әсәрләрдә бер генә нәрсә дә артык булмавын тәгъбир итә галим.

Әлеге әсәрләргә таянып А. Гыйләҗевнең каләме турында мондый нәтиҗә чыгара: «Власть ике төрле була ул, берсе аның күзгә күренә, икенчесе куренми». Әлеге фикерне дәлилиләп авторның «өстен катлау гөнаһсыз сабый булып кылана, ә балта белән эш итүчеләр исә – исемсез», – дигән фикерләре китерелгән.

Әсәрләрдә вакыйгалар сиксәненче еллар башында бара. Бу – ил белән җитәкчелек итүдә гаять җитди ялгышлар җибәрелгән чор. Аның иң зур афәте итеп кешеләрне психологик һәм аң ягыннан гарипләндерү икәнлеге мәкаләдә ассызыклана.

А. Гыйләҗев әсәрләрен – совет хакимияте чорының сәнгатьчә тарихы, ахыр чиктә аның ни өчен җимерелеп төшүенең сәбәпләрен тирән итеп аңларга ярдәм итә торган әдәби елъязма буларак та билгели галим.

«Аны вакыт җитлектерде» мәкаләсендә Т. Галиуллин бүгенге көнебезнең асылын ачуда А. Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?», Ә. Баянның «Урланган ай» әсәрләре белән салынган традицияләрне уңышлы дәвам иттерүчеләрдән буларак танылa. Үзләре күләгәдә калып, чынлыкта җәмгыять белән идарә итүче көчләрнең пәрәвездәй чәбәләнгән лабиринтларын сүтеп күрсәтүдә иҗтимагый

файдалы эш буларак бәяләнелә. Бу «Тәүбә», «Элмәк» романнарында чагыла, – дип күрсәтә галим.

Бүгенге көннең гаять аска яшеренгән, әмма чынлыкта үзенең барлыгын, хәрәкәт итүен һаман сиздереп килгән әлеге кара көчләрнең торышын, эш итү алымнарын күрсәтеп биргән Т. Галиуллин, язучы буларак осталык күрсәтсә, гражданлык ягыннан үзенең кыюлыгын да раслаган, дип бәяли бу мәкаләдә Ф. Галимуллин Т. Галиуллин эшчәнлеген.

Галим тәнкыйтьчеләрдән Р. Мостафинның эшчәнлеген – чын мәгънәсендә рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятларына тәрәзә уйган татар тәнкыйтьчеләренең берсе буларак билгели.

Ф. Галимуллин Р. Мостафинның биредә методологик характердагы бик әһәмиятле фикерен аерып күрсәтә: катлаулы юлны үзе үткән кебек, һәр халык үз тарихын үзе язарга тиеш. Ләкин бу гадел эшләнсен. Менә ни өчен, ди автор Р. Мостафин да Казан ханлыгы чорының бөек шагыйре Мөхәммәдьяр, XIX гасыр галиме Ш. Мәрҗәни, күренекле мәгърифәтче К. Насыйри образларына, аларның күпкырлы эшченлегенә игътибар юнәлтә.

Р. Мостафин – шулай ук республикабызның М. Җәлил исемендәге бүләге лауреаты да. М. Җәлил, Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, М. Әмир, Р. Төхфәтуллин, М. Шабай, М. Юныс, И. Юзеев, Ш. Галиев һәм башкалар турында язылган хезмәтләре, йөзләрчә мәкалә-бәяләмәләре белән дә ул әдәбиятыбызны үстерүгә зур өлеш кертте, – дип бәяли аның хезмәтен Ф.Галимуллин.

Г. Тукай белән бер чордаш булган Г. Исхакый каләменең үзенчәлеге итеп Ф. Галимуллин: автор тарафыннан тудырылган үзәк образларның гадәттә зур гомумиләштерүләргә ия булаларын күрсәтә. Шәкертнең хәтта исеме дә булмау аның гомумилегенә ишарә булуында күренә, ди галим.

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» һәм «Тормышмы бу?» әсәрләрендә кеше образын сурәтләүнең үзенчәлеге очраклы рәвештә генә куеп карамый Фоат Галиммуллин. Г. Исхакыйның әлеге генә өземтә итеп китерелгән фикерләреннән күренгәнчә, геройлары, димәк, Г. Исхакый «хәл итә алмаган мәсьәләләр»не укучы алдына куя, дип саный галим.

Ф. Галимуллин Г. Исхакыйның 1909 елда татар әдәбиятында яңа герой тудыруына игътибар итә. Аның яңалыгы моннан гыйбарәт: тормышта да шундый кешелер була, ул дөрес уйлый, күңеле белән әллә ниләр эшләргә әзер, хыялларының иге-чиге юк. Әмма шул ниятләрен чынбарлык итү өчен гамәленә керешә алмавы күренә.

Ә инде 1899 елда язылып, 1903 елда Оренбургта басылып чыккан «Бай углы» романында ул бер үк катламда, ягъни байлар арасында, һәм әхлаклылар, һәм әхлаксызлар барлыгын күрсәтә. Моның сәбәбен, Ф. Галимуллин мәгърифәтчеләргә хас булганча, баланы дөрес тәрбия кылу белән генә аңлата.

Шул ук вакытта галим Г. Исхакый әсәрләрендә җитешсез якларга да күз йоммый һәм әлеге кимчелекләргә китергән сәбәпләрне дә ачыклый.

«Г. Ибраһимовның иҗат юлында» мәкаләсендә галим язучының иҗат ысулы хәрәкәтен билгеләгәндә «романтизмнан – реализмга» дип карауның тенденцион булуын билгеләп үтелә. Кайбер очракларда бу хәрәкәтне «тәнкыйди реализмнан – социалистик реализмга» дип конкретлаштыра.

Ә социалистик реализм методы басымы астында совет чорындагы язучыны зурлау өчен кулланылган иң көчле эпитетларның берсе итеп реалист сүзе булуы күрсәтелә.

Реализм турында сүз барганда, аның бер табигый тармагы сыйфатында натурализм ысулы яшәвен дә искә алып китә Ф. Галимуллин. Һәм моңа мисал итеп Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» әсәре күрсәтелә.

Ф. Галимуллин хәтта 1924 елда каләмдәшләренә киңәш рәвешендә язучының төп фикере итеп: «Сүз белән вәгазьләмә, фәлсәфә сатма, бәлки тасвир кылган күренешләрең, иҗат кылган типларың ясаган тулы каплы, җанлы сурәләрең аркылы үзеңнең төп фикереңне гәүдәләндер», – дигән фикерләре кителгән.

Галим, үз чиратында, Г. Ибраһимовның, язучы буларак, романтик сурәтләүне, ә тәнкыйтьче сыйфатында социологик юнәлешне хуплавы әле инкыйлабка кадәр үк булуы ачыкланганлыгын күрсәтеп үтә.

Г. Ибраһимовның хәрәкәттәге иҗат методы да тормышның үзе кебек эволюция кичерә торуын билгели галим.

Ә Ф. Әмирханның иҗат методын билгеләгәндә Ф. Галимуллин каләм иясен реалист язучы, дип таный. Ф. Әмирхан каһарманнарын биргәндә, аларның хәрәкәт, кыланыш, психикаларындагы бөтен ваклыкларынача күрсәтергә тырыша, ди галим. Шуның белән бергә язучы хикәяләрендә, каһарман тормышындагы обстановканы күрсәтеп, шуның аша каһарманның характеристикасын ачу алымнары да бар, диелә хезмәттә.

Ләкин Ф. Әмирхан иҗатын аның шәхесен бәяләүдә төрле чорда төрлечә аңлыйлар, төрлечә бәялиләр, – ди галим. «Г. Исхакый, Ф. Әмирхан кебек классик әдипләрне урынлы-урынсыз сүгү, башка каләм әһелләренә каршы кую утызынчы елларда иң югары ноктасын җиткән чор».

Һади Такташның иҗат дәвере турында сүз алып барганда, аны нигездә егерменче гасырның егерменче еллары шагыйре итеп карыйлар.

Галим Һ. Такташ иҗатын Сәгыйт Рәмиев, Габдулла Тукай белән янәшә куеп бәяли.

Ф. Галимуллин Һ. Т акташ иҗатына гадел бәя бирүчеләрдән Г. Рәхимне күрсәтә. Әлеге тәнкыйтьче Һ. Такташ шигырьләренең нәсер белән нәзым (проза белән шигырь) арасындарак торуын да бер кимчелек итеп күрсәтә.

Гали Рәхим егерме ике яшьлек Һади Такташның бик күпне вәгъдә итә торган шәхес булуын таный. Бер үк вакытта төрле дини тәгълиматлар буенча яхшы хәбәрдарлыгы да аның фикер сөрешенә ныклы терәк булып тора.

Һ. Такташ җатын Г. Нигмәти киләчәкнең геройлары булырга хәзерләнгән яшьләрне күрсәк тә, шахтада, завод-фабрикада, станок янында чыныгып үскән кешелерне күрмибез әле, дип шелтәли. Авылны тын итеп, шәһәр шау-шуына каршы куеп сурәтләү дә ошамый тәнкыйтьчегә.

Ф. Галимуллин Һ. Такташ иҗатын шулкадәр тармаклы, катлаулы, беренче карашка гади, – дип бәяли. Һәм моның белән әдәбиятчыларның аны теротик яктан төрле юнәлешләргә кертеп карарга омтыдуларын аңлата.

Ф. Галимуллин Һ. Такташның «Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр», «Мәңгелек әкият» әсәрләрен чын мәгънәсендә шагыйрь булып җитлеккән кеше генә иҗат итә ала ди.

Аның шигъри юлларын махсус ятлап утырырга кирәк түгел. Алар ничектер җайлы гына аңга кереп калалар. Сүз сөрешендә халыкның мәкальәйтемнәрен, тапкыр сүзләрен табигый генә әйтеп җибәргән шикелле, Һади Такташның шигъри юллары үзеннән-үзе телгә килә, – дигән сүзләр язучы иҗатына бирелгән иң югары бәядер.

Һади Такташ – татар халкының күңеленә тамырланып кереп урнашкан үз шагыйребез, халык шагыйре буларак күрсәтелә мәкаләдә.

Мәхмүт Галәү иҗатын анализлаганда галим язучының каләме беркайчан да халык мәнфәгатьләреннән аерылмавын ассызыклана.

– Халык дигәндә ул, әлбәттә, иң әүвәл хезмәт белән көн күрүче, тормыш итү рәвеше белән гади кешеләрне күздә тотты, – ди галим.

«Туры сүз таш яра» мәкаләсендә М. Гафури иҗаты күздән кичерелгән. Каләм әһеленең әүвәл язган әсәренең «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» дип аталуы да юкка түгелдер, – дип билгели Ф. Галимуллин. «М. Гафури, үзенең чордашлары Г. Исхакый, Г. Тукайлар кебек үк, нәкъ менә тормышны реалистик итеп, ягъни чынбарлыктагыча сурәтләү юлыннан китә».

Башта ул мәгърифәтчелек карашларыннан чыгып эш итә, дип күрсәтә галим. Ә соңрак М. Гафуриның үзенең төп байрагы итеп сыйнфый көрәшне алуы чагылдырылган.

М. Гафури бер үк вакытта көчле прозаик буларак та күрсәтеләгән. «Кара йөзләр», «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Тормыш баскычлары» повестьлары әдәбиятыбызның күренекле сәхифәләрен тәшкил итәләр.

– Повесть, социаль-психологик әсәр буларак, бүген дә укучыларның, әдәбият белгечләренең игътибарын җәлеп итә, – дип бәяли мәкалә авторы.

Гафури бездә беренче опера либреттосы тудыручыларның берсе. «Эшче» либреттосына Газиз Әлмөхәммәтов, Солтан Габәши, Василий Виноградовлар тарафыннан музыка язылды һәм сәхнәгә куелды.

Безнең татар язучыларына еш кына тарихи эзлеклелектә уйлану, теге яки бу вакыйганы, күренешне тарихи контекстына куеп бәяләү кебек сыйфат җитми.

Ләкин тарихи дөрес уйлаганы да сиксәненче еллар урталарына кадәр шул ихлас фикерләрен ачыктан-ачык яза алмый иде.

Ә менә «М. Галәү әсәренә килгәндә, “Канлы тамгалар” эпопеясының беренче һәм икенче кисәкләрендә дә татарларның һәм Россиядәге башка халыкларның күген милли һәм социаль изү дигән кара болыт каплаганлыгы бөтен аянычлыгы белән гәүдәләндерелә» [Галимуллин, 2005:72].

Шулай ук Ф. Галимулллин «Болганчык еллар» романының төп конфликты итеп татар халкының милли изелүен күрсәтә.

Х. Туфанны шагыйрь итеп танытуда «Урал эскизлары» җыентыгын күрсәтелә. «Иске Рәсәй үлде», «Башлана башлады», «Бигиевләр» кебек әсәрләре егерменче еллар татар шигъриятенең кыйммәтле асылташларын хәтерләтәләр, ди галим.

Ф. Галимуллин Х. Туфанның кумиры итеп Һади Такташны күрсәтә, алай гына да түгел татар шигырият тарихы Такташ белән Туфан дуслыгыннан да самимирәк, ихлас дуслыкны белми.

Анын иҗатында мәкалә авторы ике биек ноктаны күрсәтә: беренчесе – 1924–1927 еллар иҗатын. Нәкъ менә шушы чорда шагыйрьнең атаклы «Урал эскизлары», «Аягурә үлеп булыр микән», «Зәңгәр бүре» әсәрләре, «Ике чор арасында», «Башлана башлады», «Иске Рәсәй үлде», «Бигиевләр» кебек поэмалары язылды. «Әлеге елларда язылган «Аккордлар» – егерменче еллар ахырының шигъри әсәрдә теркәлеп калган фәлсәфәсе, ә «Ант» поэмасы – Х. Туфанның эзоп теле белән язылган иң көчле әсәре буларак күрсәтә галим.

Х. Туфан шигърияте үсешенең икенче югары ноктасы – илленче еллар. Моны Фоат Галиммуллин 1953 елдан соң Х. Туфан күңелендә ил күләмендә үзгәрешләр була дип аңлата.

Х. Туфанның шигъри бакчасында үскән җимешләр итеп галим Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ һәм башкаларны күрсәтә.

Ф. Галимуллин Г. Бәшировка бәяләмәсен «Ул чын мәгънәсендә – матурлык җырчысы», дигән сүзләр белән башлап китә.

Тормыштагы сәнгать күренеше итеп тасвирлау югарылыгына ирешү олы талантлар кулыннан гына килә. Г. Бәширов – шушы гаять нечкә эшнең остасы. «Намус», «Туган ягым – яшел бишек», «Җидегән чишмә» дигән исемнәрдә үк никадәр аһәңлелек, югары өслүп.

Нәфисә кебекләрнең хезмәтен эстетик ләззәт алырлык итеп сурәтләп бирүе белән Г. Бәширов әдәбиятта ачыш ясады, дип билгели галим. Нәфисәне бөтен барлыгы белән милли образ буларак күрсәтә Ф. Галимуллин.

Ә «Туган ягым – яшел бишек» исемле автобиографик әсәренең эстетик көче итеп халкыбызның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, энциклопедиясе буларак материалны һәйбәт, чын халык теле белән, гади, әмма бик тирән мәгънәле хәл-әхвәлләрне укучыга мавыктыра алырлык итеп сурәтләп бирүендә һәм, әлбәттә, бик күп кешелернең коеп куйган аерым-аерым холык ияләре булуларын күрсәтеп бирүендә, дип таный мәкалә авторы. Г. Бәшировның «Урман шаулый», «Бибек нигә елый?», «Сарут» кебек хикәяләренә дә анализ бирелә.

Татар әдәбиятында Фатихлар байтак. Фатих Әмирхан, Фатих Кәрими, Фатих Сәйфи-Казанлы, Фатих Кәрим... Аларның һәрберсе үзенә бер Фатих.

Шуларның берсе Ф. Хөсни әдәбият-сәнгатькә вульгар социологик караш өстенлек алган утызынчы еллар талкысы аркылы үтеп, Бөек Ватан сугышы чорында кырыс реализм белән тәрбияләнеп, илленче еллар башындагы конфликтсызлык теориясе шаукымын да сизеп, ахыр чиктә татар әдәбиятының йөзен билгеләрлек әсәрләр иҗат иткән язучы буларак күрсәтелгән.

Ф. Хөсни прозаның аркылысын-буйга иңләп иҗат итүче язучыларыбыздан иде, дип таный галим. «Ике роман, ике дистәдән артык повесть, йөзләрчә хикәя. Болар – сүз сәнгатенә ул алып килгән байлык.

«Җәяүле кеше сукмагы» романында автор әсәрдә күтәрелгән идеягә, образларның камиллегенә, психологик тирәнлегенә игътибар итә һәм әлеге әсәрне язучының югары казанышы, дип таный.

Ф. Хөснинең «Язмыш» дигән повесте әйбәт язылган, ләкин шулай да «Җәяүле кеше сукмагы»на өстәмә буларак кына килеп чыккан, дип билгели Ф. Галимуллин.

Ф. Хөсни иҗатында тагын бер аеруча уңышлы әсәрләрнең берсе итеп галим – «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» повестен күрсәтә. Мәгълүм булганча, әлеге әсәр һәм хикәяләр тупланган җыентык өчен Ф. Хөснигә 1972 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелде.

Мәкаләдә Гыйльмениса образына җентекле анализ бирелгән.

Ф. Галимуллин Ф. Хөснине прозада мәхәббәт кырлары иҗат итүче дип атый. Ярату хисләрен кешелекле, психологик дөрес һәм шул вакытта җорлык белән сурәтләүнең остасы, ди. Ф. Хөсни кавыштарган геройлар арасында без Сәфәргали һәм Зәйтүнә, Котдус белән Наҗия, Айдар белән Вәсилә, Айдар белән Тәзкирә, Заһри белән Мөнирә, Миңлегөл белән Фоатларны күрә алабыз.

Ф. Хөснинең мирасы аның үзе кебек киң колачлы, ул – әдәбият сөючелернең сөйкемле авторы итеп күрсәтә галим.

Шулай итеп, алып бара торган хезмәтенең киң колачлы булуы, әлегә кадәр дә әдәбият дөньясында танылган галимнең фәнни һәм иҗади эшчәнлеген тагын да киңәйтә, тагын да камилләштерә. Татар әдәбияты тарихының төрле чорларын чагылдырып язылган күпсанлы фәнни хезмәтләре (аларның саны бүгенге көндә алты йөздән артык), шулар арасында күренекле язучы Гариф Ахунов иҗатын яңа күзлектән бәяләгән «Инешләр Иделгә кушыла» китабы, 20–30 нчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социалогизм таләпләренең үзара мөнәсәбәтен тикшереп язган «Эстетика һәм социологизм» дигән монографиясе, төрле чорда яшәп иҗат иткән аерым язучыларның иҗатын өйрәнеп-тикшереп язган «Офыкларны алдан күреп» мәкаләләр җыентыгы, «Мәгъсүм Насыйбуллин: язучы турында био-библиографик китап» кебек хезмәтләре булган галим тагын бер җитди китабы – «Эзләнү вакыты» белән җәмәгатьчелекне куандырды. Әлеге китапта автор татар әдәбиятында күп кенә катлаулы мәсьәләләргә үз фикерен белдерә, яңа гасыр чигендә әдәби хәрәкәтнең үзенчәлекләрен билгели. Әлеге китап, иске гасыр үтеп, яңасы башланган чорда язылып, татар иҗтимагый аңы каршында торган шактый катлаулы, буталчык мәсьәләләргә җавап та. Галимнең «Эстетика һәм социологизм» китабында вульгар социологизм мәсьәләсе 20–30 нчы еллар әдәбиятына бәйле тикшерелсә, «Эзләнү вакыты»нда исә, бу күренешнең ике гасыр чигендә әдәбияттагы чиге ачыклана. Автор игътибар үзәгенә татар әдәбиятының башка әдәбиятлар белән бәйләнеше, халкыбызның бөек шәхесләре һәм татар милләтен күтәрүдә аларның роле, тел, сөйләм культурасының бүгенге халәте, яшь буынга әдәбиятны өйрәтү мәсьәләләрен дә куйган. Гомумән алганда, галимнең ныклы принципка корылган фәнни хезмәтләре татар әдәбияты белеме фәнендә җитди урынны алып тора.

**Әдәбият**

1. *Галимуллин Ф.Г.* Офыкларны алдан күреп: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 200 б.

2. *Галимуллин Ф.Г.* Эстетика һәм социологизм: 1920–1930 еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәте. – Казан: Мәгариф нәшр. – 1998. – 223 б.

3. *Галимуллин Ф.Г.* Эзләнү вакыты / Фоат Галимуллин. – Казан: Мәгариф, 2005.

**К.Р. Нургали**
Евразийский национальный университет
имени Л.Н. Гумилева, Нур-Султан
**С.В. Ананьева**
Институт литературы и искусства
имени М.О. Ауэзова КН МОН РК, Алматы

## СРАВНИТЕЛЬНОЕ ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ В КАЗАХСТАНЕ

**Аннотация.** В статье рассматриваются труды Ш.К. Сатпаевой, И.Х. Габдирова, К.Ш. Кереевой-Канафиевой, Р. Нургали, Л.М. Ауэзовой, Е.В. Лизуновой, ставших классическими исследованиями в литературоведении Казахстана.

**Ключевые слова:** компоративистика, монография, художественный перевод.

**Abstract**. The article examines the works of Sh.K. Satpayeva, I.Kh. Gabdirov, K.Sh. Kereeva-Kanafieva, R. Nurgali, L.M. Auezova, E.V. Lizunova, which have become classic studies in the literary studies of Kazakhstan.

**Keywords:** comparative studies, monograph, literary translation.

Расширение горизонтов научного мышления, активизация разного рода контактов между исследовательскими центрами, университетами, конкретными учеными привели к актуализации компаративистских исследований. Инонациональная тематика, литература путешествий, художественный перевод и другие категории компаративистики рассмотрены в научных трудах Ш.К. Сатпаевой, И.Х. Габдирова, К.Ш. Кереевой-Канафиевой, Р. Нургали, Л.М. Ауэзовой, Е.В. Лизуновой, ставших классическими исследованиями в литературоведении Казахстана.

Вторая глава книги-монографии Ш.К. Сатпаевой «Казахско-европейские литературные связи XIX и первой половины XX века» посвящена систематизации мнений, отзывов и откликов западно-европейских ученых и писателей XIX века о Казахстане. Автор пишет: «В XIX веке на казахской земле побывали многие западно-европейские ученые и писатели, в их записях и произведениях можно найти интересные описания нашего края… В свое время определенные сведения донесла до парижской общественности книга Г. Мейендорфа "Путешествие из Оренбурга в Бухарию в 1820 году через степи, простирающиеся на Восток от Аральского моря и древнего Яксарта"» [1, с. 30]. С этой книгой был знаком Ш. Валиханов, по мнению которого «Г. Мейендорф – один из немногих, кто с тщательностью и вниманием относился к описанию быта восточных народов» [1, с. 30].

Одно из первых упоминаний о казахском народе содержится в работе «Центральная Азия, исследования о цепях гор и по сравнительной климатологии» А. фон Гумбольдта, совершившего путешествие на Урал, Алтай и к Каспийскому морю, побывавшего в Омске, Семипалатинске, Усть-Каменогорске, Оренбурге, Астрахани. Большую роль в укреплении культурных связей Казахстана и Европы сыграли польские революционеры Г. Зелинский, А. Янушкевич и Б. Залесский. Подробно проанализировав поэмы Г. Зелинского, Ш.К. Сатпаева делает обоснованный и доказательный вывод о том, что «романтическая поэма “Казах” знакомила европейскую общественность со своеобразной, беспокойной, полной трагедий и надежд жизнью обитателей далекой казахской степи. Поэма “Степь” задумана Зелинским в несколько ином плане. Здесь отсутствует определенный сюжетный стержень. Она состоит как бы из отдельных песен-раздумий, в которых дана целостная, внешне спокойная, но полная жизни и величия картина казахской природы» [1, с. 43].

В 1903–1907 годах Мангышлак посетил фольклорист и этнограф из Германии Р. Карутц. Результатом поездки стала книга «Среди киргизов и туркменов на Мангышлаке», на страницах которой есть сведения об этимологии названий двух народов, подробно описаны «быт, обычаи, нравы казахов, устройство аулов, юрт, некоторые факты из области верований» [1, с. 56]. Но не только отдельные книги конкретных европейских ученых содержали сведения о казахском народе, но и «История человечества» (в 8-ми томах), «История XIX века» (в 9-ти томах), «Народы мира в нравах и обычаях» (в 3-х томах) и др.

Завершается монография главой «Казахская литература в зарубежной критике», в которой читаем: «Отзывы писателей, критиков и читателей зарубежных стран о произведениях казахских авторов дают яркое представление о современном международном звучании казахской советской литературы…» [1, с. 191]. Это направление в современной компаративистике вслед за Ш.К. Сатпаевой развивают в научных изданиях ведущие научные сотрудники Института литературы и искусства имени М.О. Ауэзова, профессорско-преподавательский состав Евразийского национального университета имени Л.Н. Гумилева и др.

В коллективной монографии «Международные связи казахской литературы в период независимости» [2] выявлено перспективное и прогрессивное в казахско-европейских, казахско-русских, казахско-украинских, казахско-белорусских литературных связях. Серию «Международные связи казахской литературы» продолжили «Мир Абая», «Мир Ауэзова», «Мир Нурпеисова», «Мир Олжаса Сулейменова».

Монографии доктора филологических наук, профессора, заведующего отделом русской литературы Казахстана Института литературы и искусства имени М.О. Ауэзова И.Х. Габдирова посвящены разработке теоретических

проблем русско-казахских литературных связей, художественному отражению русскими художниками слова казахской действительности, традициям и новаторству, обмену творческим опытом. «П. Кузнецов ставил в пример плодотворную и дружную работу М. Ауэзова и Л. Соболева. Он высказал верную мысль о том, что еще до выхода в свет переводимого произведения автор должен сказать свое мнение о переводе и в случае его низкого качества запретить издание… По свидетельству Н. Анова, М. Ауэзов оказал ему помощь в работе над “Крыльями песни”. Он прочитал рукопись и сделал ряд серьезных замечаний» [3, с. 200–201].

Большое внимание известный ученый-литературовед, труды которого высоко ценили Г. Ломидзе, Н. Тимофеев, З. Османова, З. Кедрина, И. Дзеверин, уделял освещению инонациональной тематики (имагологии) в монографиях «М. Горький и казахская советская литература», «Русские советские писатели и Казахстан», «О национальном и интернациональном в советской литературе», «Источник вдохновения», «Писатель и действительность».

Академик НАН РК, лауреат Государственной премии РК, премии имени Ш. Валиханова, академик Международной академии информатизации, Международной Айтматовской академии, Заслуженный деятель науки и техники РК Р.Н. Нургали, преемник великого наследия Алаш, своими научными исследованиями внес большой вклад в сравнительное литературоведение Казахстана, в развитие литературной критики, в изучение казахской драматургии в контексте мировой, в практику художественного перевода как аспекта компаративистики. «Художественное слово», «Искусство драмы», «Золотой век казахской литературы», «Эстетика словесного искусства», «Поэтика драмы», «Казахская драматургия», «Эпическая драматургия», «Ауэзов и Алаш», «Вершины возвращенной литературы», «Алаш» написаны на основе сравнительно-сопоставительного метода, широчайших параллелей казахской литературы, драматургии с мировой художественной мыслью. «Драматургия Ауэзова – драматургия социальных схваток, крупных характеров, больших идей. Разные периоды жизни казахского народа, караван поколений проходят перед глазами зрителей… Использование пейзажа, диалога, монолога как средства раскрытия внутреннего мира – одна из писательских особенностей Ауэзова. Мотивы первых рассказов затем снова появляются во многих его произведениях, но уже значительно расширенные и обогащенные» [4, с. 273].

По инициативе Р.Н. Нургали в Евразийском национальном университете имени Л.Н. Гумилева, когда известный ученый-литературовед возглавил кафедру казахской литературы вуза, был открыт Диссертационный совет по защите кандидатских и докторских диссертаций, одной из специальностей которого и

стало сравнительное литературоведение. Ведущий вуз страны готовил молодые педагогические кадры по казахской литературе и компаративистике.

Историю казахской прозы как историю изменяющейся системы драматизма, драматизм как общеэстетическую категорию, полнее и предметнее объясняющую причины перехода национальной прозы от одной эстетической системы к другой, исследует Т. Есембеков в монографии «Драматизм и казахская проза» [5]. Т. Есембеков встраивает казахскую литературу в русло движения мировой, анализируя мотивы, элементы поэтики импрессионизма, экспрессионизма, экзистенциализма и других систем модерна.

Книга М. Ауэзова «Времен связующая нить» включает научные монографии по сравнительному изучению национальных литератур и проблемам культурной интеграции. Сравнительное литературоведение «в числе других случаев сопоставления литератур предполагает изучение типологической общности явлений, возникающих в разных литературах при отсутствии конкретной связи между ними… Такой анализ становится чрезвычайно продуктивным, если в результате удается выявить существенные черты самой типологической общности» [6, с. 198].

Контактно-типологическим связям М.О. Ауэзова с русской литературой XIX и XX веков посвящены научные труды Н.О. Джуанышбекова, автора монографии «Пушкин и Казахстан», учебного пособия «Творчество Мухтара Ауэзова в контексте сравнительного литературоведения», в котором приходит к доказательному выводу о важности методологии сравнительно-типологического изучения литературы и намечает пути дальнейшего исследования произведений казахских авторов. Н.О. Джуанышбеков выступал против изолированного изучения отдельной, конкретной, национальной литературы и принижения «значения литератур других народов» [7, с. 15].

Научные идеи Ш.К. Сатпаевой развивали ее последователи и ученики доктора филологических наук, профессора Ж. Тлепов, Н. Сагандыкова, Б. Мамраев, М. Маданова, кандидаты филологических наук, профессора и доценты С. Корабай, А. Тусупова, Е. Тажибаев и А. Ментебаева, защитившая кандидатскую диссертацию по научному наследию Ш.К. Сатпаевой. В этом ряду изданные под редакцией Ш.К. Сатпаевой научные труды Б. Мамраева «Казахская литература первой четверти XX века», М. Мадановой «Путь Ауэзова в страну Бальзака», «Казахстан – Франция. Малоизученные страницы истории общения народов в XIX веке», «Актуальные вопросы литературной компаративистики» и т. д.

Б. Мамраевым на примере творчества Д. Мамина-Сибиряка, М. Пришвина, Г. Гребенщикова доказано, что «жизнь казахского народа, многовековая

культура, философско-эстетические традиции способствовали зарождению в русской литературе новых тем, образов, характеров» [8, с. 92].

Комплексно рассматривает материал на казахском, русском и французском языках по разным практическим и теоретическим проблемам сравнительного литературоведения М. Маданова, уделяя особое внимание общим закономерностям и особенностям развития межлитературных связей в XX веке, художественному переводу французской литературы на казахский язык и казахской литературы на французский, рецепции иноязычной литературы, выявлению типологических схождений и своеобразия художественных процессов. Суть и смысл сравнительного литературоведения она видит «в сборе, систематизации и обобщении фактического материала истории национальных литератур, научном изучении и обосновании процесса становления мировой литературы, определении методов и теоретических ориентиров, в постановке и исследовании разнообразных проблем взаимодействия литератур» [9, с. 4].

Зарубежные критики и писатели «воспринимают казахскую литературу с позиций своей культуры, проводя сравнения, которые позволяют выделить специфическое и общее в национальных культурах» [10, с. 216]. Важно, по мнению А. Машаковой, восприятие казахской литературы как равноправной и органичной части мировой литературы.

Обобщенно-теоретический и историографический характер носят главы коллективной монографии «Казахско-американские литературные связи: современное состояние и перспективы» [11]. Авторский коллектив Б. Мамраев, У. Калижанов, С. Ананьева, Р. Абазов, Н. Каффи, А. Тусупова, А. Хамраев, Ж. Бимагамбетова, К. Нарымбетова исследуют взаимодействие культур в художественном переводе, имагологический дискурс художественного текста, эволюцию жанровых форм в казахской и американской литературах, мультикультурализм как ведущую черту национальных литератур.

Идеологема сближения культур как актуальный тренд современности «намечает определенные условия диалога: признание общего рамочного пространства; ориентацию на понимание *другого*; установку на равноправие; суверенность позиций; открытость смыслам иной культуры» [12, с. 4]. В совместной монографии «Словесное искусство современных Кыргызстана и Казахстана в контексте культуры Евразии» литературоведов из Казахстана (У. Калижанов, С. Ананьева, А. Хамраев) и Киргизии (О. Тогусаков, Р. Стамова, Н. Акматова) освещены аспекты литературного сотрудничества в контексте компаративистики, культурфилософские идеи Ч. Айтматова и др.

Культурный и литературный диалог в монографиях «Национальные литературы в диалоге» [13] и «Духовные ценности как основа фундамента культуры народов» [14] является наглядным примером не только духовной близости

стран и народов, но и показателем высокого уровня взаимопонимания и сотрудничества. Современному исследователю доступен «любой инструментарий анализа: идеи феноменологии, герменевтики, структурной лингвистики, философской антропологии» [15, с. 9]. Проблемы художественного перевода, порой, вытесняют изучение мирового литературного процесса. Но в литературоведческой науке Казахстана этого не происходит. Нарастающая динамика международного сотрудничества Института литературы и искусства имени М.О. Ауэзова Министерства образования и науки Республики Казахстан способствовала реализации научных проектов с участием литературоведов и критиков зарубежных стран, итогом которых стало издание коллективных научных монографий, высоко оцененных отечественной и зарубежной научной общественностью.

В «Очерках по мировой литературе рубежа XX–XXI веков» (Алматы, 2006) определены главные, с точки зрения авторов разделов, тенденции и закономерности мирового литературного процесса рубежа веков. В книге представлено жанровое и тематическое многообразие европейских и восточных литератур, раскрыты их типологические особенности, даны краткие биографические сведения о ведущих мастерах художественного слова, проанализированы прозаические, поэтические и драматургические произведения.

«Новейшая зарубежная литература» (Алматы, 2011) презентована на XXIV Пуришевских чтениях. В 2012 году ее авторский коллектив стал лауреатом конкурса Совета по книгоизданию Национальных академий наук стран СНГ в номинации «Лучшая научная книга». Объект научного исследования – литературы стран Европы, США, СНГ. Постреализм, неомифологизм, экзистенциально осмысленная несвобода бытия, мотивы отчуждения и одиночества раскрыты на основе анализа художественных произведений, ставших заметным явлением в словесности.

Все ощутимее альянс книги и монитора, взаимодействие элитарной и массовой беллетристики.

Углубление и расширение этнокультурных и языковых контактов меняет языковую ситуацию XXI века, художественная литература адресована интеллектуальному читателю, на первый план выходит проблема *смысла* и *значения,* что доказывает авторский коллектив учебного пособия «Мировой литературный процесс: контент, направления, тренды». Современное литературоведение и литературная критика Казахстана «развивают традиции классического, академического литературоведения, заложенные представителями научных школ отечественных ученых, широко известных в мировой науке» [16, с. 165]. Продолжение диалога традиций – перспективное направление в компаративистике XXI столетия.

## Литература


1. *Сатпаева Ш.К.* Казахско-европейские литературные связи XIX и первой половины XX века // Классические исследования. Связь времен и сравнительное литературоведение. Т. 4. – Алматы: Әдебиетәлемі, 2012. – С. 16–195.

2. Международные связи казахской литературы в период независимости / отв. редактор Ш.Р. Елеукенов. – Алматы: Жибекжолы, 2008. – 464 с.

3. *Габдиров И.Х.* Русские советские писатели и Казахстан. – Алма-Ата: Ғылым – Наука, 1970. – 211 с.

4. *Нургали Р.* Алашординцы (Алаш и литература). – Алматы: Алаш, 2004. – 290 с.

5. *Есембеков Т.* Драматизм и казахская проза. – Алматы: Ғылым, 1997.

6. *Ауэзов М.* Хождения к колодцам времен // Ауэзов М. Времен связующая нить. – Алматы: ИД «Жибекжолы», 2016. – С. 178–210.

7. *Джуанышбеков Н.О.* Проблемы сравнительно-типологического изучения литератур. – Алматы: Казак университетi, 1995. – 253 с.

8. *Мамраев Б.* Казахские литературные связи начала XX века. – Алматы: Наука, 1991. – 95 с.

9. *Маданова М.Х.* Актуальные вопросы литературной компаративистики. – Алматы: Ғылым, 1999. – 268 с.

10. *Машакова А.* Казахская литература в современной зарубежной рецепции. – Алматы: Институт литературы и искусства им. М.О. Ауэзова, 2014. – 236 с.

11. Казахско-американские литературные связи: современное состояние и перспективы / отв. редактор С. Ананьева. – Алматы: Әдебиет Әлемі, 2016.

12. Словесное искусство современных Кыргызстана и Казахстана в контексте культуры Евразии / отв. редактор Т.А. Аскаров. – Алматы, Бишкек: Avrasya Press, 2017. – С. 31–64.

13. *Ананьева С.В., Нургали К.Р.* Национальные литературы в диалоге. – Яссы: PIM IAŞI, 2017. – 159 с.

14. *Мирзоев К., Ананьева С., Карлюкевич А., Абдрахманова К.* Духовные ценности как основа фундамента культуры народов. – Минск: Белпринт, 2020. – 174 с.

15. *Николаев П.А.* Типология и компаративистика // Сравнительное литературоведение: теоретический и исторический аспекты. Материалы Международной научной конференции «Сравнительное литературоведение» (V Поспеловские чтения). – М.: Издательство Московского университета, 2003. – С. 7–16.

16. *Ананьева С.В., Нургали К.Р.* Эволюция национальных литератур: от традиций к постмодерну // Мировой литературный процесс: контент, направления, тренды. Учебное пособие / под ред. С.В. Ананьевой. – Алматы: Ғылым ордасы, 2017. – С. 150–188.

**Р.С. Нурмөхәммәтова, Г.Ф. Җамалетдинова**
Казан федераль университеты, Казан

# МИЛЛИ МӘДӘНИ КОД БУЛАРАК ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ИСӘНЛӘШҮ ГЫЙБАРӘЛӘРЕ
(М. ГАЛИЕВ ӘСӘРЛӘРЕ МИСАЛЫНДА)

**Р.С. Нурмухаметова, Г.Ф. Замалетдинова**
Казан федераль университеты, Казан

# ФОРМУЛЫ ПРИВЕТСТВИЯ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ КАК НАЦИОНАЛЬНЫЙ КУЛЬТУРНЫЙ КОД
(НА ПРИМЕРЕ ПРОИЗВЕДЕНИЙ М. ГАЛИЕВА)

**Аннотация.** Правила этикета занимают особое место в произведениях художественной литературы, поскольку они создают условную модель повседневной жизни народа, отражают национальный менталитет, раскрывают особенности общения между людьми. А отношения, общение людей строятся на нормах этикета. В этой статье ставится цель выявить лингвокультурную специфику этикетных выражений, в частности формул приветствия в татарском языке по произведениям Марселя Галиева.

**Ключевые слова:** татарский язык, национальный менталитет, этикетные выражения, формулы приветствия.

**Abstract.**The rules of etiquette occupy a special place in the works of fiction, because they create a conditional model of the daily life of the people, reflect the national mentality, reveal the peculiarities of communication between people. Relationships, communication of people are built on the norms of etiquette. This article aims to identify the linguistic and cultural specifics of the etiquette expressions, in particular the greeting formulas in the Tatar language based on the works of Marcel Galiev.

**Keywords:** Tatar language, national mentality, etiquette expressions, greeting formulas.

Сөйләм этикеты гыйбарәләре милли үзенчәлекләрне ачык чагылдыра. Һәр халык сөйләм әдәбенең үз кагыйдәләрен булдырган. Гәрчә барлык милли сөйләм этикеты формаларында охшаш сыйфатлар булса да, һәр халык бу гыйбарәләр нигезенә әхлакый кыйммәтләрнең үз күзаллауларын салган. Алар исә халыкның милли мәдәнияте, тарихы, дине, көнкүреше һ. б. белән бәйле үзенчәлекләргә барып тоташа.

Татар халкының сөйләм әдәбе күп гасырлар дәвамында формалашкан һәм билгеле бер кануннарга нигезләнгән, нормаларга салынган. Боларны белеп аралашу, сөйләм кору – башкаларда үзеңә карата хөрмәт уятуның әһәмиятле шарты.

Күп кенә хезмәтләрдә сөйләм әдәбе гыйбарәләре материалларының түбәндәге тематик төркемнәре барлана: 1) мөрәҗәгатьләр, 2) игътибарны җәлеп итү сүзләре, 3) исәнләшү, 4) саубуллашу, 5) гафу үтенү, 6) яхшы теләкләр, 7) котлаулар, 8) юатулар, хәлгә керүләр, 9) үтенечләр, 10) чакырулар, 11) киңәшләр һәм тәкъдимнәр, 12) мактаулар [Формановская, 1979: 30].

Әлеге мәсьәләне махсус өйрәнгән А. Абдуллин татар телендәге этик гыйбарәләрнең түбәндәге тематик төркемнәрен күрсәтә: 1) исәнләшү; 2) хөрмәт белән эндәшү; 3) саубуллашу; 4) рәхмәт белдерү; 5) үтенеч; 6) үтенечне үтәүгә әзерлек; 7) гафу үтенү һәм гафу итү; 8) котлау; 9) теләк; 10) игътибарны җәлеп итү; 11) мактау; 12) танышу; 13) чакыру; 14) сыйлау; 15) киңәш һәм үгет-нәсыйхәт; 16) әйтелгәннәр белән килешү; 17) тынычландыру; 18) кайгыны уртаклашу; 19) шатлыклы хәбәр җиткерү [Абдуллин, 2006: 11].

Этикет гыйбарәләрен өйрәнгән галимнәрнең һәрберсе тәкъдим иткән бүленештә саубуллашу һәм исәнләшү кебек этикет формалары да бар. Алар кешеләрнең һәр көндәлек аралашулары вакытында мөһим роль уйный торган берәмлекләр. Башка төр этикет формаларыннан аермалы буларак, исәнләшү һәм саубуллашу гыйбарәләренең телдә синонимик рәте күбрәк.

Халкыбызга хас этикет кагыйдәләре матур әдәбият әсәрләрендә киң урын алып тора, чөнки алар шартлы тормыш моделен тудыралар, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачып бирәләр. Ә кешеләрнең мөнәсәбәтләре, аралашулары этикет нормаларына нигезләнә. Бу хезмәттә М. Галиев әсәрләрендәге исәнләшү гыйбарәләренең кайбер лингвомәдәни үзенчәлекләрен барлау максат итеп куела.

М. Галиевнең күпсанлы проза әсәрләрендә – повесть-хикәяләрендә исәнләшү формаларының артык катлаулы төрләрен күрмибез. Теркәлгән кадәр лингвомәдәни материал гадәти, без көн дә ишетеп күнеккән гыйбарәләрне үз эченә ала. Исәнләшү ситуациясе белән бәйле гыйбарәләр кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтен (танышлар яки таныш түгелләр, дуслар, төрле яшьтәге кешеләр, туганнар һ. б.) чагылдыра. Иң киң таралган һәм нейтраль гыйбарәләрдән язучы «исәнме»/«исәнмесез» формасын бик еш куллана. Беренче гыйбарә яшьләре, статуслары ягыннан бер-берсеннән аерылып тормаган яки бер-берсен җитәрлек белгән, шактый якын мөнәсәбәтләрдә булган кешеләр арасында кулланыла. Мәсәлән, ***Исәнме**, әллә йокыдан уяттыммы*? (Ак абагалар). Әлеге мисалда егете янына килгән кыз шулай дип исәнләшә.

Бер-берсен гомер буе белгән, бергә картайган өлкән яшьтәге кешеләр дә шул сүз белән исәнләшә алалар: ***Исәнме****, Зәйнәптәй. Ишеттеңме әле, пенсияләрне арттыралар икән?* (Хәтер).

Шулай ук төрле яшьтәге кешеләр дә, әгәр дә бер-берсе белән күптәннән таныш булсалар һәм аралашып яшәсәләр, «исәнме» вариантын сайлыйлар (аеруча бу авыл кешеләре арасында шулай): ***Исәнме****, Ризван абзый! Чалып ега яздың бит...*

«Исәнмесез» гыйбарәсе бер-берсе белән таныш булмаган кешеләр исәнләшкәндә, шулай ук башка кешегә карата хөрмәт белән дәшкәндә, җитәкчегә эндәшкәндә кулланыла. Мәсәлән, сәркатип кыз җитәкчесе белән исәнләшә:

*– Гафу итегез...* ***Исәнмесез****, – диде Марина, аның кискен хәрәкәтеннән каушый төшеп.*

– ***Исәнмесез****! Нигә гафу үтенәсез?* (Туйдан соң)

Бу этик ситуациядә хезмәттәшләр белән бер-береңне тоту нормаларын күзәтелә: буйсынучы гына түгел, җитәкче дә башкаларга карата «Сез» дип дәшә, рәсми әдәп саклый.

«Исәнмесез» сүзе кешеләрнең бер-берсен ят итүләрен, араларындагы мөнәсәбәтләрнең салкын булуын белдерү максатына да хезмәт итә. Мәсәлән, М. Галиевнең лирик хикәяләре арасында «Сиңа мин кирәк» дигән гаять тирән эчтәлекле, нечкә хисле әсәре бар. Ул унҗиде яшьлек Сөембикә исемле кызның әнисе белән аңа биш яшь ярым вакытта ук аерылышкан әтисе Рөстәмне эзләп килүе һәм ата белән кызның бер-берсе белән аңлашулары турында. Бу әсәрдә, ата белән баланың башта бер-берсенә ят кешеләр сыман булуларын автор бик тә үтемле психологик күренеш ярдәмендә – ул аларны бер-берсенә «Сез» дип эндәштерә:

*– Марат Уразов* ***сез*** *буласызмы?*

*– Сөембикә...* ***Исәнмесез****... Әйдә үтегез... (Сиңа мин кирәк).*

Әнә шулай, автор геройларының күңел халәтләрен нечкә психологизм белән ачып бирә. Ата белән кыз башта гына бер-берсенә «сез” дип дәшәләр, аннан соң «син»гә күчәләр, димәк, «исәнмесез» гыйбарәсенең нәкъ менә психологик әһәмияте ачык билгеләнә.

«Исәнме» / «Исәнмесез» гыйбарәләреннән тыш, М. Галиев «нихәл» дип исәнләшү формасын да еш куллана. Әлеге формада кешенең хәл-әхвәлен белешү нияте калкурак чагылыш таба, ул нейтраль яңгырамый төсле. Бу гыйбарә һәрвакытта да бер-берсен яхшы белгән һәм шулай дип дәшәрлек итеп бер-берсен якын иткән кешеләр арасында әйтелә: ***Нихәл****, Зәйнәп карчык, ял итәбезме?* (Хәтер) ***Нихәл****! – дип ул, кичә генә аерылышкан кебек, үрелеп, җилкәмә дә сугып алды* (Очрашу).

«Нихәл» гыйбарәсен кулланганда, еш кына аралашучыларның яше әһәмияткә ия түгел: хәтта яшьләр дә өлкән кешеләргә «нихәл» дип әйтергә мөмкин: ***Нихәл**, әби! Син борынгы җырлар, бәетләр беләсеңме?* (Үле диңгез ярында). Бу ситуациядә әбидән күпкә яшь егет аңа «син» дип эндәшә, әлбәттә, әлеге эндәшү формасы егетнең җилбәзәклеген, яшьлек кыюлыгын, шул ук вакытта карчыкны үз итүен дә күрсәтә.

Яшьләрнең беренче булып исәнләшүе, гомумән, М. Галиев әсәрләрендә еш очрый. Автор өлкәннәргә карата ихтирамлы булуның әһәмиятен шул рәвешле дә күрсәтеп бирә төсле:

– ***Сау гынамы**, Сания апа!*

*– И-ии, **шөкер генә,** улым, – диде ана, балкып торган ак күлмәкле, ак чалбарлы егеткә күзләрен кыса төшеп карады* (Ана).

М. Галиев әсәрләрендә рәсми тонда исәнләшү чарасы буларак «хәерле көн (иртә, кич)» гыйбарәсен еш файдалана. Алар нинди дә булса эмоцияләрдән азат, бары әңгәмәдәш белән этикет саклап сәламләшү өчен кулланыла:

*– Айдар Асанович, **хәерле көн**! Инженер Диниевның хатыны булам мин* (Туйдан соң).

Ә инде, киресенчә, артык этикет саклап тормыйча, кешегә карата беркадәр юмор белән эшдәшкәндә, автор «сәлам» гыйбарәсенә мөрәҗәгать итә:

*Кемдер кул болгады, кемдер ирененә бармагын тидереп «үбеп» узды, кемдер кычкыртып үтте:*

– ***Сәлам**, падишаһ!* (Ак абагалар).

Бу җөмләдә «сәлам» гыйбарәсе «падишаһ» дигән эндәшү формасы белән бергә кулланыла. Калган кешеләрнең сәламләве паралингвистик чаралар аша гына тормышка ашырыла: кул болгау, ирененә бармагын тидереп «үбеп» узу, кычкыртып үтү. Әлеге ситуациядә катнашучыларның яшьләр һәм бер-берсе белән бик якын таныш булулары ачык чагыла. Бу – үтә гади мөнәсәбәт белән, гади сөйләмгә тартым, әшнәләрчә-дусларча сөйләшү стиле.

М. Галиевнең без караган әсәрләрендә дини стильгә хас исәнләшү гыйбарәләре бөтенләй диярлек очрамый, әмма үзе белән исәнләшкән яшьләргә дини картның «вәгаләйкессәлам!» дип җавап бирүенә мисал табылды: ***Вәгаләйкемәссәлам**, оланнар. Әйдәгез, түрдән узыгыз. – Бабай салмак кына кузгалып, нәкышле сырма ябылган урындыкларны кымшата башлады. – Өйнең кадерләләре булыгыз* (Үле диңгез ярында).

Исәнләшү ситуациясе белән бәйле этик гыйбарәләр турыдан-туры башка этик төзелмәләр белән кушылып китә. Әйтик, исәнләшкәндә, хәл-әхвәл сорашу – татарлар өчен әһәмиятле әдәп кагыйдәләренең берсе. Мондый этик ситуацияләрдә М. Галиев төрле гыйбарәләрне куллана: алар арасында

традицион, шаблон «хәлләр(егез) ничек?» формасы да, үз итеп әйткән юмор белән сугарылганнары да бар. Мәсәлән:

*– Я, синең **хәлләр ничек** соң?* (Ак абагалар)

*– **Яшәреп буламы**, әби?!*

*– Кая инде ул, бер артка китә башлагач...* (Балачак әсирлегендә)

әдебиятын оқытыў методикасында бирқанша методикалық ҳәм теориялық мәселелер бойынша Қ. Йўлдошев: «Әдебият сабақларының сапасын жоқарылатыў, оқыўшылардың образлы сөйлеў уқыплығын раўажландырыў, сөз байлығын арттырыў барысында унамлы нәтийжелерге ерисиўде көбирек оқытыўшылардың методикалық қолланбалар менен қай дәрежеде тәмийинленгенлиги менен байланыслы» [2; 3-б.], Б. Тўхлиев: «Әдебияты оқытыў методикасы пәни өтмиштеги бай тәжирийбелерди үйрениў тийкарында ҳәзирги мектеплердеги әдебиятты оқытыў процессин улыўмаластырады» [3; 19-б.] ҳәм басқалардың мийнетлеринде методикалық пикирлер ҳәр тәреплеме билдирилген.

Сонлықтан оқыўшылардың жас ҳәм психологиялық өзгешеликлерин есапқа алып, қарақалпақ әдебияты, туўысқан халықлар ҳәм жәҳән әдебиятының сайланды үлгилери менен таныстырыў арқалы олардың қәлбинде ўатанға сүйиўшилик, миллийлик, әдеп-икрамлылық усаған пазыйлетлерди қәлиплестириў. Оқыўшыларда ўатанға сүйиўшилик, миллий мийрасларды қәдирлеў сезимлерин оятыў, көркем шығарма ҳәм оның поэтикалық өзгешеликлерин үйретиў арқалы оларда сын көз қарас пенен пикирлей алыў көнликпелерин ҳәм уқыплылықты пайда етиў тийис.

Оқыўшыларда еркин пикирлей алыў, дөретиўшилик қәбилетиниң пайда болыўы ҳәм раўажланыўы ушын имканият жаратыў, оларда ҳәр қандай руўхый жақтан саламат ҳәм күшли саўатлылықты пайда етиў, сөз өнери арқалы оқыўшылардың инсаныйлық идеяларын жетилистириў болып табылады.

Академиялық лицейлерде қарақалпақ әдебиятын оқытыў методикасы бойынша оқыўшылардың билим ҳәм көнликпелерине төмендеги талаплар қойылды: әдебият теориясы, әдебият тарийхы ҳаққында түсиникке ийе болыўы, бағдарламадағы берилген әдебий материаллар бойынша әмелий көнликпелерди терең ҳәм саналы түрде өзлестириў, өзлестирилген теориялық билимди, үйренген әмелий көнликпе ҳәм тәжирийбелерди әмелде қоллана билиў, алған билимлерин әдебияттаныў илиминиң тараўлары менен байланыстырып үйренип барыў, ҳәрбир сабақта билим ҳәм көнликпелерге ийе болыў тийис.

Қарақалпақ әдебияты пәнинен бағдарлама ҳәм сабақлықларды дүзиў принциплерин, оқытыў усылларын жаңаша бағдарда ислеп шығыў зәрүрлилиги келип шықты. Қарақалпақ әдебияты сабақлығының мазмуны бағдарламаларда көрсетиледи. Бағдарлама ҳәм сабақлықлар теориялық, методикалық ҳәм педагогикалық билимге ийе кадрлар тәрепинен дүзилиўи тийис. Қарақалпақ әдебияты пәни бағдарламасына киргизилген материаллар оқыўшылардың жас өзгешеликлерин есапқа алған ҳалда, тағы да тәрбиялық характерлерине қарап бериледи. Әдебияттан алынған материаллар сайланды материаллар болып, көркемлиги жағынан, тил өзгешелиги бойынша да, миллийлиги тәрепинен де оқыўшылардың психологиялық, педагогикалық талаплары есапқа алынған ҳалда ғана

дүзилиўи керек. Академиялық лицейлер ушын арналған пән бағдарламаларын дүзиўде төмендеги принциплер басшылыққа алыныўы зәрүр:

1. Бағдарламаға киргизилген әдебий шығармалар жоқары көркемлик, терең идеялық ҳәм тәрбиялық тәсир жасаў принциплери бойынша таңлап алыныўы тийис.

2. Таңланған ҳәрбир әдебий материал оқыўшылардың жас ҳәм психологиялық өзгешеликлерине ылайық болыўы керек.

3. Бағдарламаға киргизилген жазыўшылардың дөретиўшилик шеберлигине дыққат аўдарыў зәрүр.

4. Теориялық материаллар оқыўшылардың жас өзгешелигине қарап жеңилден қыйынға қарап сайлап алыныўы тийис.

5. Пән бағдарламасында қарақалпақ әдебияты тарийхы бойынша тарийхый-хронологиялық принциплер шәртли түрде сақланыўы зәрүр.

6. Бағдарламада берилген жазыўшылардың дөретиўшилиги мектеплерде ҳәм лицейлерде қайталанбаўы лазым. Олар избе-излик принципи бойынша берилиўи керек. Бирақ 10–11-класлар ушын арналған әдебият бағдарламасы менен лицей оқыўшыларына арналған әдебият бағдарламасы арасында мазмуны жағынан байланыслық, сәйкеслик болыўы шәрт.

Академиялық лицейлер ушын арналған сабақлықларды дүзиўде төмендеги принциплер басшылыққа алынса мақсетке муўапық болады:

1. Бағдарлама ҳәм сабақлық арасында тематикалық жақтан қатаң сәйкеслик болыўы тийис.

2. Сабақлық дүзиўде бағдарламада көрсетилген темалар тийкарында әдебий материаллар сәўлеленеди. Бағдарламадағы ҳәрбир тема бойынша сабақлыққа материал таңланып, бул темаларға жобалар, тапсырма ҳәм сораўлар исленип шығылады.

3. Сабақлыққа киргизилген әдебий материаллар бурын мектеп сабақлықларына киргизилген болса, оларды қайталаўға жол қойылмаўы керек.

4. Сабақлыққа киргизилген материаллардың тәрбиялық әҳмийети, сапасы ҳәм избе-излиги басшылыққа алыныўы зәрүр.

5. Сабақлыққа киргизилген материаллар бойынша жоба дүзилип, онда таяныш сөзлер, тапсырма ҳәм сораўлар, пайдаланылған әдебиятлар дизими берилгени мақсетке муўапық болады.

6. Сабақлықтағы материалларға дүзилген жобаға сәйкес ҳәрбир сораўға анық жуўаплар берилиўи шәрт. Тилекке қарсы академиялық лицейлер ушын арналған бағдарлама ҳәм сабақлықларды дүзиўде бул принциплер басшылыққа алынбағаны сезиледи [6; 6-б.].

Академиялық лицейлер ушын арналған қарақалпақ әдебияты бағдарламасына киргизилген әдебий материаллардың сапасы ҳәм мазмуны мәмлекетлик

билимлендириў стандарты талапларына жуўап бермейди. Бул мәселени «ХХ әсирдеги қарақалпақ әдебияты» пәни мысалында көретуғын болсақ, 2013-жылы дүзилген пән бағдарламасы менен 2018-жылы дүзилген пән бағдарламаларында берилген темалардың избе-излиги, сапасы, мазмуны ҳәм бағдарламаның дүзилиў принциплери бир-биринен өзгешеленип турады. Бул пикиримизди мысаллар менен дәлиллеп өтемиз. 2013-жылы дүзилген «ХХ әсирдеги қарақалпақ әдебияты» пәни бағдарламасында: «20–30-жыллардағы қарақалпақ әдебиятына шолыў, Қ. Әўезов, Ә. Өтепов, С. Мәжитов, М. Дәрибаев, Н. Дәўқараев, екинши дүнья жүзилик урыс дәўириндеги қарақалпақ әдебиятына шолыў, А. Дабылов, С. Нурымбетов, урыстан кейинги (1946–60-жыллар) қарақалпақ әдебиятына шолыў, Ә. Шамуратов, Ж. Аймурзаев, С. Хожаниязов, К. Султанов, Т. Жумамуратов, И. Юсупов, Т. Қайыпбергенов, М. Сейтниязов, 1970–80-жыллардағы қарақалпақ әдебияты Т. Мәтмуратов, К. Рахманов, Ш. Сейтов, қарақалпақ әдебияттаныў илими К. Мәмбетов, С. Баҳадырова, Ғәрезсизлик дәўирдеги қарақалпақ әдебиятына шолыў, дүнья әдебияты үлгилеринен «Ҳалила ҳәм Димна» дәстаны, Мырза Ғолиб лирикасы, Омар Ҳайям дөретиўшилиги, Ш. Айтматов дөретиўшилиги, Р. Ғамзатовтың «Мениң Дағыстаным», Г. Токай, Муса Жалил, Азиз Несин, Р. Токур, И. Крылов, А.С. Пушкин, Ж. Лондон, Э. Ҳемингуей дөретиўшилиги» ҳаққында темалар орын алған [6; 10–20-б.]. Бағдарламадағы бул темалар орынлы берилген болып, оқыўшылардың әдебий – теориялық билимин тереңлестириў ҳәм әмелий көнликпелерин қәлиплестириў ушын үлкен әҳмийетке ийе**.** Биринщиден, ХХ әсир қарақалпақ әдебиятына тийисли материаллар тарийхый хронологиялық принципте орын алған. Екинщиден, дүнья жүзилик әдебият ўәкиллериниң дөретпелеринен алынған үлгилер оқыўшылардың пикирлеў қәбилетин қәлиплестириў ҳәм олардың эстетикалық талғамын жетилистириў ушын хызмет етеди. Бул жыллардағы дүзилген бағдарламалар қойылған методикалық талапларға толық жуўап береди. Усы көзқарастан 2018-жылы дүзилген «ХХ әсирдеги қарақалпақ әдебияты» пән бағдарламасы менен салыстырсақ бир-биринен өзгешеленип турады [7].

Әдебият пәни бағдарламасында берилген көркем шығармаларды таллаў ҳәм оған қойылатуғын талаплар, текстти талқылаў, таллаўдың түрлери ҳәм усыллары сабақ барысында үйрениледи. Көркем шығарманы таллаў арқалы оқыўшыларға әдеп-икрамлық, эстетикалық, руўхыйлық тәрбия бериў мәселелери, оқыўшыларға ҳәрбир халықтың өзиниң жоқары мәденияты, руўхыйлығы менен күшли екенлиги жетерли түсиндириледи. Усы пән арқалы сабақ түрлери ҳәм оны шөлкемлестириў усыллары, оқытыў типлери, оқыўшыға сабақты түсиндирип, үйретип, көрсетип оқытыў типи, проблемалық оқытыў типи, дифференцияластырылған оқытыў типи, бағдарламаластырылған оқытыў типлери үйренип шығылды. Сабақ түрлери болған жаңа билим бериў, семинар, ойын,

жарыс, тест, конференция ҳәм пикирлесиў сабақлары арқалы бағдарламада берилген материаллар ҳаққында түсиник берилди. Қарақалпақ әдебиятын оқытыў барысында оқыўшыларды терең билимге үйрететуғын, сабақта қарақалпақ әдебияты бойынша материалларды үйретиўде муғаллимлерден педагогикалық ҳәм методикалық шеберликлер талап етеди. Ҳәрбир әдебият сабағы философия, тил билими, әдебияттаныў илими, тарийх, эстетика, педагогика, психология пәнлери менен байланыслы үйренилди.

Қарақалпақ әдебиятын оқытыў бойынша мәмлекетлик билимлендириў стандартларына муўапық оқыўшылардың билимин қәлиплестириў ҳәм раўажландырыў, сондай-ақ, олардың илимий-методикалық билим дәрежесин жетилистириў усаған методикалық мәселелер көрип шығылды. Қарақалпақ әдебиятының оқытылыўы, қарақалпақ әдебиятынан бағдарлама, сабақлық ҳәм оқыў қуралларының дүзилиў принциплери, әдебиятты оқытыўдың бир системаға түсиў жоллары, ғәрезсизлик дәўирдеги қарақалпақ әдебиятын оқытыў методикасы ҳәм оның раўажланыў бағдарлары үйренилди.

## Литература


1. Богданова О.Ю. Методика преподавания литературы / О.Ю. Богданова, С.А. Леонова, В.Ф. Чертова. – М.: Педагогика, 2002. – 162 с.

2. Юлдашев Қ. Бадиий таҳлил асослари / Қ. Юлдашев, М. Юлдашева. – Тошкент: КАМАЛАК, 2016. – С. 461.

3. Пахрадинов А. Методика преподавания каракалпакской литературы / А. Пахрадинов. – Нукус: Билим, 2004.

4. Исломов Ш. Изучение лиро-эпических произведений на уроках родной литературы в IX–X классах таджикской школы: автореф. дис. ... канд. пед. наук / Ш. Исломов. – М., 1990. – 26 с.

5. Хусанбоева Қ. Методика преподавания литературы / Қ. Хусанбоева, Р. Ниезметова. – Т.: Баркамал файз мадиа, 2018. – С. 352.

6. Юсупов К.А. Методика преподавания каракалпакской литературы / К.А. Юсупов. – Ташкент: Сано-стандарт, 2018. – С. 336.

7. Юсупов К.А. Методика преподавания каракалпакской литературы в академических лицеях (монография) / К.А. Юсупов. – Нукус: Каракалпакстан, 2019. – С. 112.

8. Юсупов К.А. Академиялық лицейлерде Т.Қабуловтың өмири ҳәм лирикасын үйрениў / К.А. Юсупов // Ilim ha’m ja’miyet. Нукус давлат педагогика институти журнали. – Нукус, 2020. – № 1. – Б. 106–110 (13.00.00. № 3).

9. Юсупов К.А. Академиялық лицейлерде лирикалық шығармаларды таллаў / К.А. Юсупов // Қорақалпоқ давлат университети ахборотномаси. – Нукус, 2020. – № 1. – Б. 181–184 (13.00.00. № 13).

10. Юсупов К.А. Академиялық лицейлерде Т.Қайыпбергенов дөретиўшилигин оқытыў методикасы / К.А. Юсупов // Ilim ha'm ja'miyet. Нукус давлат педагогика институти журнали. – Нукус, 2020. – № 2. – Б. 100–103 (13.00.00. № 3).

11. Yusupov K.A. Scientific and theoretical foundations of teaching Karakalpak literature at academic lyceums / Yusupov K.A. // Journal of Critical Reviews. – 2020. – Vol. 7. – Is. 7. – № 1. – P 349–354. – URL: https://www.scopus.com/sourceid/21100920227.

***

**И.И. Әхмәдуллин**
Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитетының мәгариф идарәсе, Кукмара

## ТЕЛ КҮРКЕ-СҮЗ (ФОАТ ГАЛИМУЛЛИННЫҢ ДИКТОР БУЛАРАК ЭШЧӘНЛЕГЕ)

**И.И. Ахмадуллин**
Управление образования Исполнительного комитета
Кукморского муниципального района, Кукмор

## ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ФОАТА ГАЛИМУЛЛИНА КАК ДИКТОРА

**Аннотация.** Фоат Галимуллин – знаменитый диктор радио Татарстана. Работал на радио в 1967–1975 годах. В 1969 году Галимуллина направили учиться в Москву. Ему посчастливилось попасть в группу Юрия Левитана. Большое внимание он уделял пропаганде татарской литературы.

**Ключевые слова:** диктор, профессор, академик, земляк.

**Abstract.** Foat Galimullin is a famous radio announcer of Tatarstan. He worked in radio 1967–1975. In 1969, he was sent to study in Moscow. He was lucky enough to get into the group of Yuri Levitan. He paid great attention to the promotion of Tatar literature.

**Keywords:** speaker, professor, academician, fellow countryman.

Быел март аенда күренекле галим, язучы, тәнкыйтьче, атаклы диктор, җырчы, күп педагогларның остазы, халкыбызның асыл егетләренең берсе,

якташыбыз Фоат Галимулла улы Галимуллинның гомер бәйрәме билгеләп үтелә: аңа 80 яшь тула.

Фоат Галимуллин – татар халкының мәшһүр шәхесе. Халкыбызның рухи дөньясына ул иң элек узган гасырның алтмышынчы еллар ахырында бәрхет тавышлы радио дикторы булып килеп керә. Аның күңелләрне рәхәтләндерә торган сирәк баритон тавышын тыңлап, кемнәр генә хозурланмый да, кемнәр генә сокланмый! Ул елларда тыңлаучылар радиотапшыруларны сагынып, көтеп алалар. Фоат Галимулла улы сөйләгән соңгы хәбәрләрне тыңлаганда, тыңлаучыларның җанына яңа мәгълүматлар белән бергә, ниндидер бер рәхәтлек, җылы бер тынычлык та иңә. Фоат Галимуллин алып бара торган «Соңгы хәбәрләр», «Тел күрке – сүз» һәм башка тапшырулар халык күңеленә май булып ята. Аның радиодан ишетелгән бәрхет тавышы күп еллар буе татар тормышына ямь биреп тора.

Якташыбыз Фоат Галимуллин 1941 елның 21 мартында Кукмара районының Арпаяз авылында туа. Бөек Ватан сугышы аны ата назыннан аерган. Әнисе Нурхәят апа улын тәрбияләү өчен бөтен көчен куя. Фоат 1952 елда Арпаяз башлангыч мәктәбен, аннан 1955 елда Пычак җидееллык мәктәбен тәмамлый. Озын буйлы, арык гәүдәле бу малайның мәктәптә уку елларында ук төрле яктан сәләте барлыгы күренә. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлсем апа, үзе ач булса да, тавышы көр булган малайның матур итеп шигырьләр укуына игътибар итсә, 1957 елда Кукмара районында Татарстан яшьләренең Беренче фестивалендә җыр белән катнашкан яшь егетне район мәдәният бүлеге мөдире, сугыш каһарманы Сәет Сәгыйтов күреп алып, «синең урының мәдәният юлында» дип, аңа хәер-фатихасын бирә һәм Арпаяз авылы клубына мөдир итеп билгели.

Радиога Фоат Галимуллин 1950 нче елларда, аның даими тыңлаучысы булганнан соң гашыйк була. Аңа ул вакытта диктор һөнәре иң әһәмиятле һөнәр булып тоела.

1967 нче ел 26 яшьлек Фоат Галимуллин өчен борылышлар елы була. Бу вакытта инде төрле фестивальләрдә катнашып, урыннар яулаган, әзме-күпме үз исемен мәдәният өлкәсендә ишеттерү бәхетенә ирешкән Фоат Галимуллин Татарстан радиосына дикторлык вазифасына конкурста катнаша һәм җиңеп чыга. Кайчандыр үзе сокланып тыңлаган Камал Саттарова белән бергә эшли башлый. Бу вакытта аңа Мәрьям Арсланова, аның ире Айрат Арсланов белән дә еш очрашырга туры килә. Аны Габдулла Шамуков, Фуат Халитов, Ибраһим Гафуров кебек сәхнә һәм сүз осталары матур итеп сөйләшергә, укырга өйрәтәләр. «Габдулла Шамуков гарәп һәм фарсы телләре сүзләрен дөрес итеп әйттерүгә аеруча әһәмият бирә. Мәрьям Арсланова исә - рус теле белгече, Наил Иртуганов – Казан университетында чит тел укытучысы - бер үк вакытта радиодан рус

телендә тапшырулар алып бара, шунда мине эш арасында инглиз, немец, француз, испан сүзләрен дөрес итеп әйтергә өйрәтә. Әнә шулай, бердәм тырышлык белән, миннән әйбәт диктор китереп чыгарырга тырышалар. Уйлавымча, аларның бердәм булышлыгы бушка китмәде. Радиотыңлаучылар мине диктор буларак кабул иттеләр шикелле. Рәхмәт остазларыма!..» – дип үзенә әлеге һөнәрнең нечкәлекләрен өйрәтүчеләрне рәхмәт хисләре белән искә ала Фоат ага.

Остазлары да Фоат Галимуллинның үз һөнәренә булган мөнәсәбәтенә зур бәя бирәләр.

«Дикторлык осталыгына ия булу белән бергә, Фоат аны сәнгать югарылыгына күтәреп, тыңлаучыларда мәхәббәт һәм ихтирам казанды. Студиягә тапшыру алып барырга керү алдыннан, ул үз-үзен рәткә кертә: галстугын төзәтә, чәчен тарап куя, тавышын тикшерә, сөйләшүне туктата. Әйтерсең, ул бер кеше дә күрми торган студиягә керми, ә халык алдына сәхнәгә чыга.

Микрофон фальшны, ясалмалылыкны бик тиз сизә. Дикторның эчке дөньясы, культурасы бай булса, аның чыгышларында дөрес интонация уңышлы яңгырый. Фоат тапшыруга әзерләнмичә керә алмый, аңлашылмаган сүзләрне сүзлектән эзләп, аны кат-кат кабатлап кына эфирга чыга иде», – дип яза Татарстан радиосының 1964–1980 еллардагы дикторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мәрьям Арсланова.

Фоат Галимуллинның Татарстан радиосында диктор хезмәтен башкарган елларын өлкәнрәк буын хәтерли, әлбәттә. Чөнки аның кебек гади генә бер сүз ярдәмендә дә кеше күңеленә юл таба алучы, сүзе белән юатучы, уйландыручы, сөенергә мәҗбүр итүчеләр ул вакытта да күп булмый, бүген дә күп түгел бит арабызда. Радиода эшләгән 1967–1975 нче елларда күпләрнең йөрәген сүз белән яулый алган кеше ул Фоат Галимуллин.

1969 нчы елның язында Фоат Галимулловичны Мәскәүгә Бөтенсоюз радиосына дикторлык осталыгын күтәрү өчен курсларга җибәрәләр. Шул вакытта аңа өч ай буена Мәскәү дикторлары белән аралашырга мөмкинлек туа. Педагог итеп Людмилла Кайгородованы билгелиләр. Ул көн саен Фоат Галимуллинга дәресләр бирә. Шулай да Юрий Левитанның тәэсире көчлерәк кебек тоела Фоат абыйга. Бервакыт Юрий Борисович шәкертләре арасында рәсми хәбәрләрне үзе сыман итеп уку буенча ярыш оештыра, татар егете Фоат Галимуллин җиңеп чыга. Остазы шуның өчен аңа Останкино башнясында урнашкан «Күкнең җиде каты» ресторанына чакыру билеты бирә. Матур тавышлы, вәкарь белән генә сөйләшүче, даны бөтен дөньяга танылган диктор Юрий Борисович Левитан татар егете Фоат Галимуллинны аеруча үз итүенең серен дә ача. «Сугыш вакытында минем тавышыма зыян килде. Күпме генә тырышып йөрсәләр дә, Мәскәү врачлары тавышымны төзәтә, ача алмадылар. Ә Казаннан махсус чакырып китерелгән бер татар докторы мине савыктырды. Хәзер мин аның исемен дә

белмим инде. Әмма ул татар иде. Шуңа күрә татарларга хөрмәтем бик зур», – дип, сөйли Юрий Борисович.

Шундый зур остазларның хәер-фатихасын алган, алардан осталыкка өйрәнгән Фоат Галимуллин – татар әдәби сөйләмен үстерүгә зур өлеш керткән шәхес. Аның аһәңле сөйләмендә тулы бер буын тәрбияләнеп үсә. Ул – татар әдәби сөйләмен классик дәрәҗәгә күтәрүчеләрнең берсе. Татар сөйләме үзенчәлекле аһәңгә, ритмик сурәткә ия бит. Моны Фоат Галимуллин, озак еллар гамәлдә эшләп, тыңлаучыларга ирештереп килә.

«Тел күрке-сүз» һәм тагын күп кенә әдәби тапшыруларда халыкны сүз сәнгатенең нечкәлекләренә төшендерә ул. Татарстан радиосында эшләгән елларында Фоат Галимуллин Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәргә лаек була. Озак еллар диктор булып эшләү тәҗрибәсен галим укытучылык хезмәтендә дә уңышлы куллана. Филолог студентлар инде соңгы өч дистә елда «Сәнгатьле уку» курсын нәкъ менә Ф. Галимуллин язган методик әсбаплар ярдәмендә үзләштерә.

Радио һәм телевидение аша әдәбиятыбызны пропагандалауга да Фоат Галимуллин зур әһәмият бирә. «Күп еллар дәвамында “Яңа китаплар” дип аталган тапшырулар циклын алып барды, “Тел күрке- сүз” дигән популяр тапшырулар аның актив катнашуы белән әзерләнде һәм эфирга чыкты. Әдәби чыганаклар буенча Ф.Галимуллинның якыннан катнашында язылган аудиокассеталар – урта мәктәп өчен бик тә файдалы ярдәмлекләр», – дип бәя бирә аның бу юнәлештәге эшчәнлегенә хезмәттәше, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы Азат Әхмәдуллин.

Татар яшәгән һәр йортка үзенчәлекле матур тавышы белән килеп кергән Фоатны халык та үз улы итеп таный.

«Татар халкы әтине диктор буларак бик ярата: әти белән урамда, поезд, трамвайда барганда, таныш булмаган кешеләр, исәнләшеп, үзләренең соклануларын белдерәләр. Шундый халык мәхәббәтенә лаек булса да, әти ул чакларда да, хәзер дә үзенең тыйнаклыгын, кече күңеллелеген, гадилеген югалтмый. Минем өчен аның бу сыйфаты бик зур үрнәк. Л.Н. Толстой әйткәнчә: «Кешенең бөеклеге гадилектә һәм дөреслектә күренә», – дип, үзенең истәлекләре белән уртаклаша Фоат Галимуллинның кызы, филология фәннәре кандидаты Әлфия Галимуллина.

Һәрвакытта да горур, көр тавышлы, мәһабәт гәүдәле, һәр татар кешесенә таныш Фоат Галимулла улы үзе дә: «Һәрбер сүзне йөрәк аша уздыргач кына шагыйрьнең, язучының әйтәсе килгән сүзләрен аңларга була», – дип саный.

Халыкара төрки академиясе академигы, Петровский исемендәге сәнгать һәм фән академиясенең хакыйкый әгъзасы, Россия Федерациясенең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, язучыларның Җамал Вәлиди исемендәге бүләге иясе профессор Фоат Галимуллин үзенең зур юбилеен иҗади

хезмəттə каршылый. Күренекле якташыбызны без дə гомеренең күркəм бəйрəме белəн чын күңелдəн котлыйбыз. Эфир дулкыннарыннан тавышының əле озак яңгыравын, калəменең тутыкмавын телибез!

**Əдəбият**


1. Əхмəдуллин А.Г. Киң карашлы галим һəм җəмəгать эшлеклесе / А.Г. Əхмəдуллин // Казан утлары. – 2016. – № 3. – Б. 122–125.

2. Дəрзаманов З.Х. Казан сөйли! (Говорит Казань!) / З.Х. Дəрзаманов, Н.Р. Акмалов. – Казань: Идел-Пресс, 2008. – 296 б.

3. Фикер һəм хис гармониясе (Фоат Галимуллин: шəхес, галим, остаз. 70 яшь тулу уңаеннан мəкалəлəр, докладлар һəм əдəби əсəрлəр җыентыгы) / төз. Ə.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов. – Казан: ТДГПУ, 2011. –192 б.

4. Хуҗин Рафаэль Шəйхуҗа улы (Рафаэль Сибат). Көлдəн күтəрелгəн Гөллəр (Əдəби-документаль кыйссалар). – Казан: «Матбугат йорты» нəшрияты, 2002. – 200 б.

5. Якташ язучылар (Рус мəктəбенең 5–11 сыйныфларында укучы татар балалары өчен программа). – Кукмара, 2003. – 107 б.



**Г.С. Галимуллина, Ч.Ф. Маткулова**
57 нче рус-татар урта мəктəбе, Казан


## ОЛЫ ХӨРМƏТКƏ ЛАЕКЛЫ ОСТАЗ


**Г.С. Галимуллина, Ч.Ф. Маткулова**
МБОУ «Школа № 57», Казань


## УВАЖАЕМЫЙ НАСТАВНИК


**Аннотация.** В статье раскрывается чувство гордости и уважения к педагогу с большой буквы, научному деятелю, профессору, диктору Ф. Галимуллину. Говорят, в судьбе нет случайностей. Человек скорее создает свою судьбу, нежели встречает ее. Упорное благоразумие – вот что определяет жизнь человека. Обычный деревенский мальчик из простой крестьянской семьи своим трудолюбием, упорством, знанием своего дела, безграничной любовью к своему народу и языку смог достичь таких высот в сфере образования. Известные литературоведы высоко оценивают его труды в области теории литературы, методики преподавания татарской литературы. Особым достоянием являются его методические разработки для книг, учебники для школ с татарским языком.

Когда мы встречаем на своем пути выдающихся ученых, учителей, мы всегда задумываемся над тем, каким насыщенным, интересным был их путь. Таким ученым, на наш взгляд, стал и наш Учитель – наставник Фоат Галимуллин.

**Ключевые слова:** заслуженный профессор, диктор, баритональный голос, уроки Левитана, студия.

**Abstract.** The article reveals the pride and respect for a teacher with a capital letter, a scientific figure, a professor, and an announcer. To Galimullin. They say there are no accidents in fate. Man creates his destiny rather than meets it. Persistent prudence is what defines a person's life. An ordinary village boy from a simple peasant family with his hard work, perseverance, knowledge of his business, with boundless love for his people, language, allowed him to reach such heights in the field of education. Well-known literary critics highly appreciate his works in the field of literary theory, methods of teaching Tatar literature. A special asset is his methodological developments for kegi, textbooks for schools with the Tatar language. When we meet outstanding scientists and teachers on our way, we always think about how rich and interesting their path was?! Such a scientist of selection, in our opinion, was our Teacher – mentor Foat Galimullin.

**Keywords:** distinguished professor, announcer, baritone voice, Levitan’s lessons, studio.

Еллар узган саен үткән гомернең, аралашкан кешеләрнең кадере арта бара. Тормышта хыялга илтә торган юлда җитәкләп баручыларга күңелдә туган рәхмәт, хөрмәт хисләре тагын да ныгый. Бу юлларны язганда күз алдына, быел 80 яшен тутыручы укытучыбыз Фоат Галимуллин килә. Татар халкының яраткан дикторы, меңләгән укучыларның хөрмәт иткән мөгаллиме, фән дөньясында танылган галим, әдәбиятта үткер сүзле тәнкыйтьче Фоат абый – безнең, ягъни мәктәпләрдә татар телен һәм татар әдәбиятын укытучылар өчен дә зур хәрефләрдән язылырга тиешле остаз. Галимуллинның шәкерте, дәвамчысы булу – дәрәҗә дә, шул ук вакытта зур җаваплылык та. Институт еллары һәрбер кеше гомеренең – яшьлекнең кадерле мизгелләредер.

Бүген безнең, әле хәзерге көнгәчә, татар халкы, аның милли аңы, мәдәнияты, сәнгате, тел язмышы өчен борчылудан туктамаган, үзенең төпле фикерләре, киңәшләре белән мәгариф өлкәсендә хезмәт куючы хөрмәтле остазыбызның үткәненә һәм бүгенгесенә кыскача күзәтү ясап, аның шәкертләре булу белән горурлануыбызны әйтәсебез килә.

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче Фоат Галимулла улы Галимуллин 1941 елның 21 мартында Татарстан Республикасының Кукмара районы Арпаяз авылында колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе Галимулла Ватан сугышында һәлак була. Фоат әнисе Нурхәят тәрбиясендә үсә. 1952 елда Арпаяз башлангыч мәктәбен, 1955 елда

Пычак җидееллык мәктәбен тәмамлый. Армиядә хезмәт иткән елларында Липецк өлкәсенең Грязи шәһәрендә урта белем ала.

Хезмәт юлын 1955 елда колхозда төрле эшләр башкарып башлый, тракторчы ярдәмчесе (сукачы) дә була. Үзешчәннәр белән концертларда, спектакльләрдә чыгыш ясый башлый. Һәвәскәрләрнең район күләмендә уздырылган бәйгеләрендә катнашып, татар халык көйләрен башкару буенча җиңүчеләр сафына чыга. 1957 елда Татарстан яшьләренең беренче республика фестивалендә катнаша. Шуннан соң аны шул ук елда Арпаяз авылы клубы мөдире итеп билгеләлиләр. Өч елдан район мәдәният йортында татар драма театрына сәнгать җитәкчесе итеп күчерәләр. 1962–1965 елларда ул армиядә хезмәт итә.

1965 елда, гаскәри хезмәт мөддәтен тутырып кайткач, аны эшкә фирканең Кукмара район комитетына инструктор итеп алалар. 1966 елда район мәдәният йортына директор итеп куялар.

Нәкъ шушы урында Г. Ибраһимовның танылган «Кызыл чәчәкләр» хикәясе искә төшә. «Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек. Кем күтәрде? Кайчан? Ничек?» – дип башланып китә хикәя. Бу җөмләләр, бүгенге көндә олуг әдибебез, остазыбыз булган Фоат Галимулла улы Галимуллин узган тормыш юлына бик тә туры килә дип уйлыйбыз. Чыннан да, гаилә тоткасы, әтисе Бөек Ватан сугышына киткәндә 4 айлык сабый гына булып калган бит ул. «Әтием, алып гәүдәле тимерче Галимулла, алма кебек хатынын һәм өч баласын калдырып, сугышның беренче көннәреннән үк яу кырына китеп, илебез азатлыгы өчен башын салган. Шулай итеп, дүрт айлык чагымда ук мине каһәр төшкән сугыш ятим калдырган. Әниләребезнең тырышлыгы, назы, мәхәббәте нәтиҗәсендә генә исән калган буын без», – ди галим, көрсенеп. Дәһшәтле сугыш еллары... Әтисезлек сугыш тәмамланганнан соң да үзен бик сиздерә. Бу турыда Ф. Галимуллин: «Укыйсы килә, ләкин урта мәктәп Кукмарада гына. Яшьтәш егет белән шунда киттек. Директор абый безне укырга алырга риза, ләкин тулай торак бирә алмыйм, ди. Бергә килгән егетне укырга да алдылар, торырга урын да бирделәр. Аның әтисе бар иде шул, ә минеке – юк! Яклаучым да, саклаучым да булмавын, үз көчемә генә ышанырга туры киләчәген шунда беренче тапкыр аңладым». – дип искә ала. Күп укырга, белемгә омтылышы, хезмәт сөючән, тырыш, тәрбияле, сабыр холыклы, үз – үзенә һәм тирә – юньдәгеләргә таләпчән булуы аңа тормыш юлында очраган каршылыкларны җиңәргә булышкандыр, мөгаен.

Табигатьтән килгән моң яшь егетне иҗат юлына чакырып сәхнәгә меңгерә, ә буыннан – буынга күчеп, аңа килеп җиткән «бәрхет» тавышны тагын да матур, яңгырашлы, аһәңле итү өстендә эшләү, Фоат Галимуллинны Татарстан радиосының профессиональ дикторы дәрәҗәсенә күтәрә. Әдип үзе бу хакта түбәндәгеләрне сөйләде: «Кечкенәдән мин җырга мөкиббән китә торган малай булганмын. Авылга кунакка кайткан Мостафа абыйның патефоны бар иде.

Шуны бакчага алып чыгып, җырлый иде. Патефон янына иң беренче булып барып, җырларны отып утырам һәм шуларны көйләп йөрим икән. Менә шул вакытта җырлау тавышны саклау һәм үстерү өчен яхшы күнегү булган. Мәктәптә укыганда да, яшүсмер чакта да җырлы спектакльләрдә катнашып, Кукмара районында җырчы егет булып танылдым. Гомерем буе үзем өчен генә булса да җырладым. Җырлау тавыш мөмкинлекләрен үстерергә нык ярдәм итә икән».

1967 елда Татарстан Министрлар Советының Телевидение һәм радиотапшырулар комитетына ир-ат дикторга конкурс игълан ителә. Ф. Галимуллин анда катнашып, сиксәнләп көндәш арасында җиңеп чыга. Казанга күчеп килеп, 1974 елга кадәр шушы өлкәдә хезмәт куя. Үзенең ничек итеп тавышын яхшырту өстендә эшләве, легендар диктор Левитаннан дәрес алуы хакында искә алып сөйләде: «1969 елда мине Казаннан Мәскәүгә дикторлар курсына җибәрделәр. Ул дүрт ай чамасы булды. Шунда дикторлык осталыгы буенча мине Левитанга беркеттеләр. Турыдан-туры аның җитәкчелегендә индивидуаль дәресләр алдым. Моның файдасы бик зур булды. Ул безгә, диктор эфир алдыннан 5–10 минут тавышны кыздырып алырга тиеш дип, бик күп күнегүләр өйрәтте. Мин зур студиягә кереп, 10–15 минут җырлап алам. Микрофон алдына утырганда минем тавышым инде җырлап тора. Шул рәвешле Аллаһы Тәгалә биргән тавышны сакларга, үстерергә кирәклеген аңладым».

Фоат Галимуллин Татарстан радиосында эшләү дәверендә рәсми хәбәрләрне һәм материалларны гына түгел, әдәби әсәрләрне күңелгә сеңдереп укуы белән бик күп радиотыңлаучыларның мәхәббәтен казана. Анда эшләү белән бергә, ул Казан дәүләт педагогия институтының Тарих-филология факультетында укый, чөнки бала вакыттан ук Фоат Галимуллин укытучы булырга хыяллана. Аны тәмамлагач, Фоат Галимулла улын шушы югары уку йортының татар әдәбияты кафедрасына укытучы итеп чакыралар.

1984 елда аңа доцент дигән гыйльми исем бирелә. Ул 1977–1986 елларда Тарих-филология факультеты деканының уку-укыту эшләре буенча урынбасары, 1986–1991 елларда декан булып эшли. Аннан соң татар әдәбияты кафедрасы мөдире итеп сайлана. 1990 елда, тәнкыйтьче буларак, СССР (Татарстан) Язучылар Союзына әгъза итеп алына. 2004 елдан Россия Язучылар союзы члены. 1999 елда Казан дәүләт университетындагы Гыйльми советта «1920–1930 еллар татар әдәбиятында эстетика һәм социологизмның үзара мөнәсәбәте» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. 2000 елда аңа профессор дигән гыйльми исем бирелә.

Татарстан язучыларының унөченче һәм ундүртенче корылтайларында (1999, 2002) Фоат Галимуллин Татарстан Язучылар берлеге рәисе итеп сайлана. 1999 елда Татарстан Халык депутаты, ә 2004 елда Татарстан Дәүләт Советы депутаты итеп сайлана. 2004 елдан бер үк вакытта Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире вазифаларын да башкара.

Фоат Галимуллинның әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшли башлавы узган гасырның җитмешенче елларына туры килә. Ул бигрәк тә татар прозасының үткәндәге һәм үз заманындагы торышын тикшерү белән мавыга. Шул ук вакытта шигърият һәм драматургия өлкәләрен дә читләтеп үтми. Аның әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә, публицистикага, уку-укыту тармагына караган тугыз йөздән артык төрле характердагы хезмәтләре бар: монографияләр, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре, мәкаләләр. Матбугатта әдәби әсәрләре дә дөнья күреп килә.

Ф. Галимуллин күп еллар буена Татарстан радиосыннан һәм телевидениесеннән «Яңа китаплар» дигән тапшырулар алып барды. Өч дистә елга якын «Тел күрке – сүз» тапшыруларында катнашып килә.

1974 елдан башлап Ф. Галимуллин фәнни-методик хезмәтләр язу буенча даими эш алып бара. Югары уку йортлары, мәктәпләр өчен программалар, дәреслекләр төзү буенча күп хезмәт куя. Татар мәктәпләренең җиденче, унынчы, унберенче сыйныфлары, рус мәктәпләренең алтынчы, тугызынчы, унберенче сыйныфлары укучылары утыз ел буена Ф. Галимуллин катнашында язылган дәреслекләр буенча укыдылар. Галим-педагог югары уку йортларында «1920–1930 елларда әдәби хәрәкәт үзенчәлекләре», «Әдәби иҗатта осталык мәсьәләләре», «Әдәби бәйләнешләр» һәм башка темаларга махсус курслар укый. Сәнгатьле сөйләм буенча аның тарафыннан язылган уку әсбаплары күп кенә мәктәпләрдә һәм башка уку йортларында файдаланыла. Аның укуында язылган аудиокассеталар безнең өчен, ягъни татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен, ярдәмлек хезмәтен үтиләр.

Туган телебез буларак, татар теленең бөеклеге, киләчәктә дә дәрәҗәле булуына зур өметләр баглап, Фоат Галимуллин тарафыннан әйтелгән фикерләрне алтын хәрефләр белән язып куярлык: «Дөньяга шундый бөек шәхесләр биргән (Җәлиле генә дә ни тора!) бөек, зур халык теленең киләчәге булмавына ышанмыйм мин. Дөрес, безгә үз телебезне саклап, яклап көрәшергә (сөйләшергә дип укыгыз) туры килер. Балаларыбыз, оныкларыбыз белән. Аларны өйрәтә, дөресрәге, яраттыра алсак, туган телебез киләчәккә дә барыр. Юк икән инде, үзебезгә үпкәләргә калыр. Үземнең ул яктан йөзем якты. Кызым да, улым да, ике оныгым да туган телебезне беләләр. Бер күрүдә гашыйк булып, 53 ел бергә аңлашып-санлашып яшәгән хатыным Фәйрүзәгә дә рәхмәт – балалар күңеленә туган телне ул иңдерде. Юкка гына, Ана теле димиләр ич!»

Олы юбилее алдыннан ниндирәк эшләр белән кайнаша икән, галим? Сер итеп кенә әйтәбез: фән өлкәсендә 40 елдан артык эшләгән. Бик күп хезмәтләре басылган. Аларны системалаштырырга кирәк. Ул шуларны барлап, китап рәвешенә китерә.

Фоат Галимуллин гомер буе әдәби әсәрләр дә язган. Матбугатка чыгарыр өчен түгел, бары тик үзе өчен генә. Бик күп шигырьләре җыелган. Ул аларны туплап, иң җитлеккәннәрен сайлап, шулай ук бер китап хәленә китерергә ниятли.

Шул ук вакытта повесть, хикәя җыентыклары да эшли. «Бу яшемдә шул эшләрне алып бару, шуңа мөмкинлегем булу – зур бәхет. Моның өчен мин Аллаһы Тәгаләгә чиксез рәхмәтемне әйтәм», – ди галим.

Бүген дә Казан федераль университетында татар әдәбияты профессоры вазыйфаларын башкара.

Ф.Галимуллинның фән һәм мәгариф, мәдәният өлкәсендәге фидакарь хезмәтләре хөкүмәтебез тарафыннан да югары бәяләнде: 1996 елда Татарстанның, 2006 елда Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелде. 2004 елда аңа М. Шолохов истәлегенә булдырылган медаль бирелде. 2011 елда «Фидакарь хезмәт өчен» медале, 2016 елда «Татарстан алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләнде. Әдәби тәнкыйть өлкәсендәге күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен, 2005 елда аңа Татарстан Мәдәният министрлыгының һәм Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге премиясе, ә 2018 елда, Ф. Кәрим иҗатын озак вакытлар буена пропагандалаганы өчен, шушы ватанпәрвәр шагыйрь исемендәге премия тапшырылды. Ул – Петровский сәнгать һәм фән академиясе (С.-Петербург), Халыкара төрки академиясенең хакыйкый әгъзасы (академигы). 2016 елда аңа Казан (Идел буе) федераль университетының атказанган профессоры дигән исем бирелде.

Тагын шунысын да әйтеп китәсебез килә, 2020 елда гомумдөнья күләмендә «Татарча диктант» акциясе узды. ТНВ каналыннан яраткан мөгаллимебез Бөтендөнья татарларына диктант яздырды! Без дә телевизор каршысына утырып, шатланып, тырышып диктант яздык.

Шушы көннәрдә генә бик матур яңа җыр ишеттек. Фоат Галимуллин сүзләре, Фәридә Фәйзуллина көе «Яшерен сөю» дип атала. Җырны Айгөл Сагеева башкарды.

Зур гомер бәйрәме алдыннан хөрмәтле остазыбызга имәндәй ныклы сәламәтлек телибез һәм чиксез рәхмәтләребезне белдерәбез.

**А.М. Гарипов**
Олуязская средняя школа им. Г.Х. Хабибрахманова
Кукморского муниципального района РТ

## ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН – ХАЛКЫБЫЗНЫҢ РУХИ БАЙЛЫГЫН ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕРЕН ҮСТЕРҮ ӘЙДӘМАНЫ

**Аннотация.** В статье рассматривается жизненный и творческий путь видного литературоведа профессора КФУ Фоата Галимуллина. Анализируются отдельные научные труды.

**Ключевые слова**: духовные богатства, общественные мысли, литературовед, преподаватель вуза.

**Abstract.** The article examines the life and creative path of a prominent literary critic, Professor of KFU Foat Galimullin. Separate scientific works are analyzed.

**Keywords:** spiritual riches, social thoughts, literary critic, university teacher.

Җыйнак, пөхтә, ап-ак мичле авыл өе. Стенада күкеле сәгать һәм радио. Шул радиодан салмак, аһәңле, тыңлап туеп булмаслык тавыш агыла. Бу тавыш сине үзе артыннан ияртә, һәрбер әйтелгән сүз синең күзәнәкләреңә кадәр үтеп кереп, сүзнең көчен, тәмен белергә, тел дигән дәрьяның тирәнлеген тоярга өйрәтә. Бу тавыш иясе – татар халкының яраткан дикторы, күпләгән студентларның хөрмәт иткән укытучысы, фән дөньясында танылган галим, үткен сүзле тәнкыйтьче – Фоат Галимуллин.

Еллар үткән саен, кеше үзенең хәтер «көндәлекләрен» ешрак барлый, «укый». Күңел төпкелләрендә гомер буена рәхмәт хисләре белән искә ала торган кешеләр торган саен ешрак искә төшә. Хыялга илтә торган юлда җитәкләп баручыларга күңелдә туган рәхмәт, хөрмәт хисләре тагын да ныгый. Бу юлларны язганда, күз алдыма студент тормышында якты эз калдырган, бүгенге көндә дә үзенең төпле киңәшләре белән ярдәм итеп торучы укытучым Фоат ага Галимуллин килә.

Институт еллары һәрбер кеше гомеренең – яшьлекнең иң кадерле, гомергә истә кала торган мизгелләредер. Казан дәүләт педагогия институтының филология факультетында Фоат ага Галимуллин укыган лекцияләргә йөрү без – студентлар өчен үзе бер көтеп алган бәйрәм иде. Фоат ага сөйләгән лекцияне, әллә темасы кызыклыктан, әллә сөйләүчесенең тавышына әсир булып, рәхәтләнеп тыңлый идек. Сәнгатьле уку дәресләрендә чын артист – диктор Фоат ага Галимуллинның гади генә шигырьне күңелләрнең иң нечкә кылларын тибрәтеп укуы, төркемдәге һәрбер студентның күңеленә шигырьне, шигъриятне ярату, аңларга тырышу орлыгы салгандыр... Шәхсән үзем өчен шулай булды.

Хәзер студент чаклар шактый гына еллар артында калгач, күңелдә кайта-кайта сорау туа: бу кадәр моң, аһәң, туган телгә чиксез мәхәббәт Фоат аганың күңеленә ничек сыйды икән? Шул сорауга җавап эзләп, остазымның тормыш юлын, иҗат эшчәнлеген барлыйм.

Һәрбер төбәк үзенә генә хас булган үзенчәлекле яклары белән аерылып тора. Кукмара ягы элек-электән эшкә батыр, уңган, җыр-моңга гашыйк кешеләре белән горурлана. Баскан җирендә ут чыгара, сандугачлар көнләшерлек итеп җыр суза торган һәрбер кеше олы хөрмәткә лаек. Ә Фоат ага Галимуллинның Кукмара егете булуы тагы да зур горурлык.

Тормыш Фоат аганы  башыннан сыйпап кына үстермәгән. 1941нче елның 21нче мартында Кукмара районы Арпаяз авылында дөньяга аваз салган сабыйның балачагы, нәкъ менә яз кояшы кебек көләч, балкып барырга тиеш кебек. Ләкин шул заманның иң дәһшәтле сынавы – сугыш афәте балачакны юкка чыгара. Сугыш аның 30 яшьлек әтисен дә аямый. Әтисе Галимулла хатыны Нурхәятне, өч баланы ятим итеп һәлак була. Заман ничек кенә сындырып сынарга тырышса да, шул чорга хас булган үҗәтлек, тырышлык, тормыш арбасына чытырдатып ябышып яшим дигән өмет адәм баласын алга илтә. Ятимлек, ачлык, ялангачлыкка бирешергә теләмичә, сабый, соңрак яшүсмер Фоат киләчәккә өмет белән алга атлый. Алдагы гомерендә шул чакның самими, үзенә генә хас булган матурлыгын аерым бер җылылык белән искә алачак әле Фоат ага. Башлангыч белемне туган авылында алганнан соң, күрше авылга йөреп укый. 1955нче елда Пычак җидееллык мәктәбен тәмамлый. Колхозда тракторчы ярдәмчесе була, төрле эшләр башкара. Ә шулай да иң яраткан шөгыле – китап уку. Авыл китапханәсендә инде барлык китаплар укылып беткән, ә китапка булган сусау әле басылмаган һәм юл район китапханәсенә салына. Дөньялар сугыштан соң әле яңа җайланып килә, сугыш тирән эз калдырып киткән тормыш мәшәкатьләрен җайларга кирәк, бер яктан карасаң, китап кайгысы да түгел кебек. Ә юк, китапка, әдәбиятка булган мәхәббәт әле нәни Фоат тәүге адымнарын ясаганда, беренче сүзен әйткәндә, әбисе Сәрбиҗамал тарафыннан күңеленә орлык итеп салынган. Еллар үткән, нәни Фоат үскән саен үсә генә бара. Киләчәктә әдәбият фәне, әдәби тәнкыйть бакчасында мул җимешләре белән сөендерәчәк әле ул. Әбисенең өйрәткән шигырьләре, аның канатлы, үткен сүзләре Фоатка әдәбиятның чишмә башы булып тора һәм ул, бик мул сулы булып, киләчәк буын кешеләренең дә күңелләрен сафландырып, озак еллар сугарып торачак.

Яшьлекнең күңелле вакыйгаларының берсе – авыл яшьләре һәм укытучылары белән концерт-спектакльләр кую. Сәнгатькә омтылыш Алабуга мәдәният–агарту училищесына алып килә. Ә аннары инде тормыш дигән мул сулы дәрья үзендә колач салып йөзәр, ашкынып яшәр һәм эшләр өчен, Фоат аганы үзенә бөтереп алып кереп китә.

Алда армия хезмәте. Анда радиомеханик һәм радиотелеграфист белгечлеге алып, радиостанция начальнигыбула. Армиядә шулай ук комсомол комитеты секретаре итеп сайлана. Армия хезмәтен тәмамлап, туган якларга кайтканнан соң, Кукмара райкомында һәм мәдәният өлкәсендә хезмәт куя. 1967 нче ел Фоат аганың тормышында яңа үрләрнең башлангычы була. Фоат Галимуллин, зур конкурс үтеп, Татарстан Министрлар Советы каршындагы радио һәм телевидение комитетының дикторы итеп раслана. Дикторлык хезмәтендә булган истәлекләре белән уртаклашканда, аның бик еш искә ала торган хатирәсе бар. Бөтен Советлар Союзыннан Мәскәүгә дикторлык курсына утызлап укучы җыела.

Әлеге курсларны Юрий Левитан җитәкли. Шулай беркөнне дәрес барган вакытта Ю. Левитан курсантларга: «Кайсыгыз нәкъ минем кебек итеп, «Внимание! Внимание! Говорит Москва!» дип әйтә ала, шул курсантка Останкино телевидение манарасындагы «Җиденче күк» ресторанына күтәрелергә ике билет бирәм, – дип мөрәҗәгать итә. Утыз кеше арасыннан бары тик мин генә әлеге сүзләрне аныңча яңгырата алдым, ди Фоат абый.

Алтмышынчы – җитмешенче елларда һәр көнне радио тыңлаучыларны бәрхеттәй йомшак тавышы белән Фоат Галимуллин сәламли. Бүгенге көндә дә татар телендә эшләүче радио һәм телевидение алып баручылары аның үрнәгендә милләтебезнең телен, гореф-гадәтләрен саклап, алдагы буынга тапшыра. Билгеле, соңгы вакытта төрле ешлыкта, төрле кешенең зәвыгына, ихтыяҗына туры килгән берничә радио барлыкка килде. Алардагы кайбер алып баручыларны тыңлагач, остазым Фоат ага Галимуллин күз алдына килә, аның һәр сүзнең тәмен белеп, логик басымны дөрес куеп сөйләгән лекцияләре күңелдә яңара. Шулчакта күңелдән «Эх, боларны сүзнең кадерен аңларга өйрәтер өчен, Фоат ага Галимуллин мәктәбе аша уздырасы иде», – дигән уй йөгереп уза.

«Дикторлык элек бик җитди һәм кирәкле һөнәрләрнең берсе иде. Диктор турыдан-туры халык белән аралаша, рәсми карашларны ышандырырлык итеп халыкка җиткерә. Ә монда инде тавышның көче, аһәңе әһәмиятле рольне уйный. Башка һөнәр ияләренә, үз эшләрен башкарганда, махсус бурычлар куелган кебек, безнең һөнәргә дә таләпләр куела иде. Бигрәк тә турыдан-туры эфирга чыгып сөйләгәндә, җаваплылык нык арта. Хәзергеләр кебек теләсә нәрсә сөйләп утырып булмый», – ди ул үзе бу турыда. Чыннан да, авызы әйткәнне колагы ишетми торган сөйләүчеләрне тыңлавы рәхәт түгел.

Яңадан еллар аша юбилярның тормыш юлын, эшчәнлеген барлыйм. Гомернең бер генә көне дә эзләнүләрсез, тырыш, максатчан хезмәттән башка узмаган. Радиода эшләү белән беррәттән Фоат ага Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында укый. Шушы елларда аның фәнни эшчәнлеге башлана. 1999нчы елда Фоат ага Галимуллин профессор исеменә лаек була. Бу исемгә ирешер өчен, никадәр саллы хезмәтләр, эзләнүләр, алда куелган максатка тырышлык һәм омтылыш ята.

Фоат ага тугыз йөздән артык фәнни хезмәт авторы. Алар арасында фәнни-методик әсбаплар, күп санлы фәнни-теоретик, методик мәкаләләр бар. Күп еллар буена Татарстан радио һәм телевидениесеннән «Яңа китаплар» дигән тапшырулар циклын алып барды, «Тел күрке-сүз» дигән тапшыруның даими катнашучысы, Татарстан Язучылар берлеге рәисе вазыйфасын башкарды.

Иҗади эшчәнлегенең тагын бер зур өлешен – Фоат аганың урта мәктәпләр өчен әдәбият дәреслекләре, программаларын язуын күрсәтергә кирәк. Без, татар мәктәпләрендә эшләүче укытучылар, әдәбияттан ничә еллар буе авторлар составында Фоат Галимуллин булган дәреслекләр ярдәмендә белем

һәм тәрбия бирдек. Дәреслекләр төзү эше һәрвакыт барлык милләтпәрвәрләрнең дә алдында торган төп бурычлардан саналган. Фоат ага тарафыннан төзелгән дәреслекләр заман куйган төрле катлаулы хәлләрне чишә ала торган буын тәрбияләргә ярдәм итә дип саныйм. Шулай ук аның тавышы белән яздырылган дисклар мәктәп тормышында, әдәбият дәресләрендә куллану өчен бик зур ярдәмлек булып торалар. Уйлап карасак, татар дөньясындагы күпме әдәби әсәрләр аның тавышы белән халкыбыз күңеленә кереп урнаша бара.

Ф. Галимуллин – бүгенге көндә бик күп дәүләт бүләкләренә ия булган олпат шәхес. Бу язмада аның башкарган эшләрен дә, мактаулы исемнәрен дә бик озак санарга булыр иде. Чыннан да, Фоат аганың эшчәнлеге саф, мул сулы чишмә сыман. Чишмәләр дә бит тирә-якны үзләренең шифалы сулары белән сафландырып торалар. Фоат ага да нәкъ менә шул чишмә сыман: үзенең армасталмас эше, бетмәс-төкәнмәс энергиясе, тарихыбызга, туган телгә карата булган чиксез мәхәббәте белән инде озак еллар милләт яшәешен сугарып яши. Заманның кырыс җилләре туган телне, халык язмышын камчылаганда, шуларны кайгыртып, саклап һәм яклап калу өчен, көрәшнең алгы сафында нәкъ менә аның көрәштәшләре басты. Фоат аганың хезмәте, башкарган эшләре югары бәяләнә. Ә иң зур бәя – татар халкының аңа карата булган мәхәббәте, аны олылавы. Бу шунсыз мөмкин дә түгел: гомер буе милләткә, халыкка, фәнгә армый-талмый хезмәт итү, бөек, мәгърур татар телен бөтен камиллеге белән дөнья аренасында биеклектә тоту өчен, бар көчен биргән шәхес иң олы мәртәбәгә лаек. Фоат аганы һәр очрашуга сагынып көтеп алалар, аның белән төрле темага иркенләп сөйләшеп, киңәш сорап, сөйләмен йотлыгып тыңлап, күңелләрен сафландыралар.

Ә Фоат Галимуллович шундый зур дәрәҗәләргә ия булуына да карамастан, үзен беркайчан да өстен куймый, бик ипле, итәгатьле, гап-гади кеше. Шәхсән мин үзем Фоат ага белән бүгенге көндә дә элемтәдә торам, хәл-әхвәл белешәм, аннан киңәшләр алам. Аның белән аралашкан саен мин Фоат абыйның искитмәле хәтеренә таң калам. Ул һәрбер студентының, хезмәттәшенең язмышыннан хәбәрдар булып тора. Татарстан Республикасында 43 ләп район, һәр районда күпме авыл бар. Ул һәр авылның, аңа өстәп авыл тирәсендәге атамаларның да исемнәрен белә.

Бүгенге көндә олпат галим үзенең олуг юбилеен каршылый. Бу уңайдан меңләгән студентларының, татар халкының бер вәкиле буларак, Фоат агага олы рәхмәтемне, чиксез хөрмәтемне җиткерәсем килә.

Рәхмәт сезгә, Фоат ага! Милләтне, телне яратырга, аны заманның зәһәр җилләре камчылаганда да сакларга, якларга кирәклеген аңлатканыгыз өчен. Туган як дигән изге якны күңелнең иң нечкә кыллары аша яратырга өйрәткәнегез өчен. Еллар чәчләргә ак бәсләр салса да, күңелегез белән самими булып, кешеләргә рәхмәт хисләре һәм ышаныч саклап калганыгыз өчен рәхмәт Сезгә.

Киләчәктә дә мондый матур гомер бәйрәмнәрен әле озак еллар каршыларга язсын. Без, Фоат Галимуллин мәктәбен узган укучыларга, Сезнең белән әле озак еллар очрашулар насыйп булсын. Рәхмәт Сезгә, кече күңелле олуг галим!

**В.Г. Назмиева**
МБОУ «Кукморская средняя школа № 3»,
г. Кукмор, Республика Татарстан

## СӘНГАТЬЛЕ УКУ –МИЛЛИ КУЛЬТУРАБЫЗГА БЕР АДЫМ

## ВЫРАЗИТЕЛЬНОЕ ЧТЕНИЕ – ШАГ К НАЦИОНАЛЬНОЙ КУЛЬТУРЕ

**Аннотация.** Выразительное чтение – умение с помощью интонации, паузы, акцента и других средств выделить мысли и чувства, заложенные автором в содержание текста, выразить голосом в процессе чтения понимание идеи произведения. Только при выразительном чтении ребенок понимает текст.

**Ключевые слова:** интонации, паузы, акценты, мысли, чувства, идеи.

**Abstract.** Artistic reading is an ability to use intonation, pause, accent and other means to highlight the thoughts and feelings embedded by the author in the content of the text, to express the understanding of the idea of the work in the process of reading. Only when reading fiction does the child understand the text. Summing up, we can only say that art training is hard work, patience, and great diligence.

**Keywords:** intonation, pauses, accents, thoughts, feelings, ideas.

Туган тел – һәркемнең рухи байлыгы. Һәркайсыбыз үз баласын яхшы яктан гына булдыклы, акыллы итеп күрергә тели. Мондый нәтиҗәләргә бары тик туган телдә тәрбияләгәндә генә ирешеп була. Бары тик үз телендә, үз гореф-гадәтләрен күреп, белеп үскән бала гына шундый сыйфатларга ия булып үсә. Димәк, тәрбия кылганда уңышлы нәтиҗәләргә ирешүнең төп асылы ул – баланы туган телдә тәрбияләү, үз телендә матур итеп сөйләшергә, аралашырга өйрәтү. Күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри башка телләрне өйрәнгәнче кешеләрнең үз туган телен яхшы белүенә зур игътибар биргән: «Кеше ...үзенең туган телен кагыйдәсез дә белер һәм һич тә ялгыш әйтмәс һәм хата сөйләмәс. Ләкин башка телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кагыйдәләрнен белү бик кирәк. Чөнки кеше үзенең туган телен яхшы белмәсә, башка телгә төшенә алмас, бик озак вакытлардан соң гына аңа күнегә алыр». Баланың киләчәк тормышына, иң беренче чиратта, гаиләдә, балалар бакчасында нигез салынса, мәктәп елларында ул тагын да үстерелә, камилләштерелә. Бу ва-

кытта үз телеңне белү генә түгел, ә үз туган телеңдә дөрес итеп сөйләшә, сәнгатьле итеп укый белүгә зур игътибар бирелергә тиеш.

Тел – фикерләү һәм культурага ирешү коралы. Әгәр бала менә шул корал белән оста эш итә белми икән, ул үз фикерләрен ачык һәм төгәл итеп башкаларга җиткерә алмаячак. Җанлы сөйләмдә телебезнең матур яңгырашын саклауга, аның хисси, тасвирый һәм тәэсирлелек көчен арттыруга игътибар бирелергә тиеш. Бүгенге көндә әдәбият һәм тел укытучыларының төп бурычларыннан берсе ул – мәктәптә укучыларын сөйләмнең мәгънәви ягына игътибарлы булырга өйрәтү белән бергә, аларның бер үк вакытта әйтелгәннәргә бәрабәр хис-кичерешләрен, мөнәсәбәтләрен дә җиткерергә күнектерү. Сәнгатьле итеп сөйләшү өчен, укучы иң башта сәнгатьле итеп укый белергә итеш.

Сәнгатьле уку – интонация, пауза, басым һәм башка чаралар ярдәмендә текст эчтәлегенә автор тарафыннан салынган фикерләр һәм хисләрне аерып күрсәтә алу, әсәр идеясен аңлавыңны уку процессында тавышың белән белдерә белү. Сәнгатьле укыганда гына бала текстны аңлый. Нәтиҗә ясап, шуны гына әйтәсе кала: сәнгатьле уку ул – авыр хезмәт, түземлелек, зур тырышлык.

Матур һәм сәнгатьле итеп уку бик катлаулы эш. Ул махсус әзерлек, тиешле теоретик белем һәм гамәли күнекмәләр булдыруны таләп итә. Сәнгатьле уку дикция һәм интонациянең үзара эшчәнлеге турындагы тәгълимат та. Дикция сөйләү органнарының эшчәнлеген, авазларның дөрес әйтелешен, ә интонация сүзләрнең, җөмләләрнең, текстның ачык, матур, тәэсирле яңгырашын тәэмин итә. Кызганычка каршы, мәктәп программасында дикция өстендә эшләү каралмаган. Бу очракта зур ярдәм булырдай түбәндәге хезмәтләрне атап китү урынлы булыр: алар – Фоат абый Галимуллинның «Мәктәптә сәнгатьле уку: Студентлар һәм укытучылар өчен уку әсбабы» [Казан: КДПИ, 1984. 101 б.] һәм «Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү» [Татар әдәбияты укытучылары өчен методик кулланма. Казан: Таткитнәшр., 1988. 86 б.].

Сәнгатьле укырга өйрәнүнең сөйләү теле культурасын үстерүдә дә роле бик зур. Әсәрне тиешле эмоция белән матур итеп укый белгән кеше башкалар белән сөйләшкәндә фикерләрен интонацион яктан җиренә җиткереп әйтә ала.

Сәнгатьле уку – сүзләрне һәм авазларны да дөрес итеп әйтү дигән сүз дә әле ул. Моңа ирешүдә дәресләрдә укытучының укуы гына түгел, ә аудио һәм видео язмалар да теге яки бу артистның, күренекле шәхесләрнең укуларын тыңлауны отышлы кулланырга мөмкин.

Әгәр без, туган тел укытучылары, укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтә алсак, милли культурабызга бер адым дип әйтә алабыз. Чөнки, сөйләм – кешенең гомумкультура дәрәҗәсен күрсәтүче билгесе. Бүгенге конкурентлык шартларында үз һөнәреңне яхшы белүдән тыш, аралаша белү мөмкинлегеңнең зур

булуы, төрле проектлар төзи һәм аларны башкаларга «матур кәнфит кәгазенә төреп» сөйли белү зур әһәмияткә ия.

Укучыны сәнгатьле укырга өйрәткәнче, бүгенге дөньяда – мәгълүмәт технологияләре үсеш алган заманда – баланы китап укырга җәлеп итү шактый катлаулы проблемага әверелә бара. Ни кызганыч, бүген кәгазь китап укыган бала, ата-аналар еш очрамый. Чөнки китапны телевизор, компьютер, планшет алмаштыра. Ә китап уку – ул буш вакытны файдалы үткәрү генә түгел, ә хәтерне яхшырту, күзаллауны киңәйтү һәм дөрес язарга өйрәнү чарасы да. Цифрлашуга күчеп барганда заманда «китап укы», «китап укырга кирәк» дигән сүзләр белән генә балада китап укуга кызыксыну тәрбияләп булмый.

Менә шундый проблемаларны хәл итү юлларын эзләү чарасыннан, минем тарафтан район туган тел укытучылары өчен төзелгән «Фикердәшләр» сайтында эшчәнлекне дәвам итеп, «Китап уку – кирәкле шәядер» исеме астында яңа мәйданчык булдыруны максат итеп куйдым. Әлеге мәйданчыкта күренекле якташыбыз Фоат абый Галимуллинның диктор буларак эшләгән чорларындагы, шигырьләрне сәнгатьле укуны чагылдырган аудиоязмаларны да урнаштыру төп максат булып тора.

Бүгенге көн мәктәп укучылары программа буенча кирәкле әдәби әсәрләрне дә сирәк укый. Алар интернет челтәреннән әсәрнең кыскача эчтәлеге белән танышалар да, шуны укытучыга килеп сөйлиләр. Күпчелек әсәрләрне кыскартылган вариантта бирелгән фильмнар яки видеоязма аша карыйлар Димәк, бу үзе өчен түгел, билге өчен генә укыйлар дигәнне аңлата. «Нигә китап укымыйсың?» дигән сорауга «Нәрсәгә кирәк ул?», «Китап уку “модно” түгел» дип җавап бирәләр. Әгәр программа буенча укырга кирәкле булган әдәби әсәрләр, ниндидер яңа китаплар чыгу турында кызыклы мәгълүматлар булса, матур әдәби әсәрләр күренекле шәхесләр тарафыннан да пропагандаланса, китап укуга кызыксыну артыр дип уйлыйм. Шулай ук, әлеге мәйданчыкта укучыларга үз тавышларын ишетергә мөмкинлек тудыру да эзсез калмас. Бу очракта, укучы теләге буенча, үз тавышы белән ошаткан, кызыклы, үтемле дип тапкан өзекне, шигырьне яисә башка әдәби әсәрне аудио, видеоязма рәвешендә урнаштыру мөмкинлеген булдыру күздә тотыла. Ә мондый эшкә тартылу – үзеннән үзе китап укуга тарлылу дигән сүз. Әгәр бала әлеге эшкә алына икән, әлбәттә, ул сәнгатьле укуга игътибар итәчәк, сайлаган өлешен мөмкин кадәр матур итеп укырга тырышачак. Бу эшчәнлеккә эти-әниләрне җәлеп итү, тагын да уңышлы нәтиҗә бирәчәк, дип уйлый мин. Әлеге эшчәнлек туган тел укытучылары, укучылар, эти-әниләрне хезмәттәшлек итәргә, татар телендә фикер алышырга, телне үзләштерергә, китап уку белән кызыксындыруы чараларын оештыру мөмкинлеге тудырырга ярдәм итәр.

Китап ул – мәгърифәт тупланган өй. Шундый нурлы өйдә яшәр, тарихны өйрәнер өчен, һәрдаим кирәк булган төрле мәгълүмат белән хәбәрдар, аңбелемле булу, әдәплелек серләренә төшенү өчен китапка якынаерга кирәклеге укучылар күңеленә юл ярыр һәм кирәкле эз калдырыр. Билгеле, китап укыган, белем алырга омтылган кешенең начар уйларга, начар эшләргә вакыты калмый. Әлеге сыйфатлар бүгенге яшәешебез өчен бик мөһим. Билгеле, китап укуны сәнгатьле укудан башка күз алдына китереп булмый. Белемсез, бигрәк тә, китапсыз халык – тарихсыз халыкка әйләнә, ә тарихын оныткан халыкның киләчәге өзелгән, диләр. Киләчәгебез өзелмәс, дәвам итәр.

**Әдәбият**


1. Галимуллин Ф.Г. Мәктәптә сәнгатьле уку: студентлар һәм укытучылар өчен уку әсбабы / Ф.Г. Галимуллин. – Казан: КДПИ, 1984. – 101 б.

2. Галимуллин Ф.Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. Татар әдәбияты укытучылары өчен методик кулланма / Ф.Г. Галимуллин. – Казан: Таткитнәшр., 1988. – 86 б.



**Нәҗипова Г.Ш., Шәйхетдинова Р.Г.**

Кукмара ш.т.п. Ч.Т. Айтматов исемендәге 1нче гимназия, Кукмара


## КИЛӘЧӘК БУЫННЫ КҮРЕНЕКЛЕ ЯКТАШЛАРЫБЫЗ ҮРНӘГЕНДӘ УКЫТУ ҺӘМ ТӘРБИЯЛӘҮНЕҢ ИННОВАЦИОН АЛЫМНАРЫ


**Назипова Г.Ш., Шайхутдинова Р.Г.**

Гимназия № 1 имени Ч.Т. Айтматова пгт Кукмор, Кукмор


## ИННОВАЦИОННЫЕ МЕТОДЫ ОБУЧЕНИЯ И ВОСПИТАНИЯ ПОДРАСТАЮЩЕГО ПОКОЛЕНИЯ НА ПРИМЕРЕ ВЫДАЮЩИХСЯ ЗЕМЛЯКОВ


**Аннотация.** В сегодняшней ситуации, когда судьба родного языка зависит от каждого из нас, как привить нашим ученикам любовь к родному языку, как формировать у них национальное самосознание? Эти проблемы привели к тому, что обучение родному языку необходимо вывести на более высокий уровень. О наших земляках, окончивших татарскую школу и достигших больших высот в жизни, в музее нашей гимназии есть немало материалов. Мы стараемся воспитывать наших учеников на примере этих личностей.

В данной статье рассказывается о методах работы в данном направлении.

**Ключевые слова:** тест-тренажер, национально-региональный компонент, писатели-земляки, внеклассные мероприятия, методы воспитания.

**Abstract.** In today's situation, when the fate of the native language depends on each of us, how to instill in our students a love for their native language, how to form their national identity? These problems have led to the fact that the teaching of the mother tongue must be brought to a wider area. There is a lot of information about our fellow countrymen, who graduated from the Tatar school and achieved great success in life, in the museum of our gymnasium. We try to educate our students on the example of these personalities. This article describes the methods of working in this direction.

**Keywords:** test-simulator, national-regional component, fellow countrymen writers, extracurricular activities, educational methods.

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары төрле яклап үскән шәхесләр тәрбияләүгә юнәлдерелгән һәм укыту эшчәнлегендә милли-региональ компонентны файдаланырга мөмкинлек бирә. Укыту стандартларының берничә пунктында милли, региональ һәм этник үзенчәлекләрне өйрәнү турында сүз бара. Үз тамырларын белмәгән балада гражданлык хисләре туа алмый.

Бүгенге вәзгыятьтә, туган телнең язмышы кыл өстендә торганда, укучыларыбызда туган телгә карата ничек мәхәббәт уятырга, аларны ничек милли җанлы шәхесләр итеп тәрбияләргә? Әлеге проблемалар туган телгә өйрәтүне мәктәп стеналарында гына калдырмыйча, киңрәк мәйданга алып чыгарга кирәклегенә төшендерде. Татар мәктәбен тәмамлап, тормышта зур үрләр яулаган якташларыбыз хакында гимназиябез музеенда шактый эчтәлекле материаллар бар. Укучыларыбызны әлеге шәхесләр үрнәгендә тәрбияләргә тырышабыз. Чыгышның максаты – шушы юнәлештәге эш алымнары белән таныштыру.

Татарстан Республикасы Кукмара төбәгенең шифалы туфрагында туып ускән һәм хәзер исемнәре Татарстанга гына түгел, хәтта башка милләтләргә дә билгеле булган данлы якташларыбыз шактый. Алар арасында милләтебез язмышы, аның киләчәге турында уйланып, халкыбызның рухи дөньясын баетуда, матурлауда зур хезмәт куючы, әдәбиятыбызга намуслы хезмәт итүче әдипләребез дә лаеклы урын били. Татар мәдәниятендә җуелмас эз калдырган, дистәләгәнфәнни, әдәби китаплар авторы, фольклорчы, тәрҗемәче Мөхәммәттаип Гыйльман улы Яхин; язучы, журналист, юрист Мәгъсүм Нәҗип улы Насыйбуллин; тәнкыйтьче, галим, филология фәннәре докторы, профессор Фоат Галимуллин; танылган шагыйрь, нечкә күңелле лирик Әхмәт Юныс; язмыш сынавына бирешмичә иҗат итүче Рәниф Шәрипов; хәзерге поэзиябез күгендә якты йолдыз булып кабынган талантлы шагыйрьләр Газинур Морат, Рүзәл Мөхәммәтшин;

балалар әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеге белән сөендерүче Рәшит Бәшәр, шигырь һәм хикәяләре белән киң катлау укучыларга таныш булган Рифә Рахман; әдәбият мәйданына кыю адымнар белән керә баручы Халисә Нигъмәтуллина, Заһид Мәхмүди һәм Кукмара төбәгеннән чыккан башка әдипләр белән хаклы рәвештә горурланабыз.

Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту программасы шактый бай һәм катлаулы. Әмма укучыларны туган якта туып үскән каләм һәм сәнгать әһелләренең иҗаты, журналистларыбызның эшчәнлеге белән таныштырмый торып, мәктәптә әдәбият укытуны тулы дип әйтеп булмас иде. Якташларыбыз иҗаты белән танышу барышында, укучының кызыксынучанлыгы арта, ул үзе дә эзләнә башлый, алар хакында материаллар туплый, презентацияләр ясый. Шул ук вакытта укучыда туган төбәгеннән чыккан күренекле шәхесләр белән горурлану, үзе дә аларга охшарга тырышу хисе туа.

Безгә телне өйрәтүдә бүгенге замана балаларын кызыксындырырлык, нәтиҗәле алымнарны сайлый белергә кирәк. Шуны күздә тотып, якташ язучыларыбызның тормыш һәм иҗат юлы буенча тест-тренажер эшләдек.Әлеге тренажер укытучыга укучының эшен бәяләргә һәм шул ук вакытта хаталарын анализларга да ярдәм итә. Барлык биремнәрне эшләгәннән соң, экранда укучының эше бәяләнә: баллы чыга, билгесе куела, эшнең үтәлеше процентларда бирелә. Шулай ук кайсы биремнәрнең хаталы үтәлүе дә экранда күрсәтелә. Тәкъдим ителгән тренажерларның өстенлеге шунда: алардан югары сыйныфта укучылар гына түгел, ә түбән һәм урта сыйныф укучылары да мөстәкыйль рәвештә файдалана, үз белемнәрен бәяли, хаталарын күрә һәм төзәтә алалар. Моның өчен төп битне ачып, тәкъдим ителгән якташ язучыларыбыз арасыннан үзеңә кирәкле әдипнең исеме язылган төймәгә генә басарга кирәк. Сораулар, нигездә, язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән бәйле.

Бу урында татар әдәбиятында үзенең лаеклы урыны булган Фоат Галимуллинның тормыш һәм иҗат юлы буенча төзелгән тест-тренажердагы берничә сорауга тукталып үтүне урынлы булыр дип саныйбыз:

1. Якташыбыз Фоат Галимуллин Кукмара районының кайсы авылында туган?

а) Күкшел;

б) Арпаяз;

в) Мәчкәрә;

г) Уразай.

2. Фоат Галимуллин Татарстан радиосында нинди тапшыруны алып барган?

а) «Тел күрке – сүз»;

б) «Татарлар»;

в) «Яңалыклар»;

г) «Милләттәшләр».

3. Түбәндәге җыентыкларның кайсысы Фоат Галимуллинныкы түгел?

а) «Инешләр Иделгә кушыла»;

б) «Офыкларны алдан күреп»;

в) «Инешләрдән иңгән моңнар бар»;

г) «Әле без туганчы».

4. Фоат Галимуллин нинди зур бүләккә ия була?

а) Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе;

б) Муса Җәлил исемендәге дәүләт бүләге;

в) Җамал Вәлиди исемендәге әдәби премия;

г) Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия.

Укучыларны якташларыбыз иҗаты белән кызыксындыруда безгә learningapps.org. сервисы да ярдәмгә килә. Әлеге программа Швейцария һәм Германия университеты белгечләренең гыйльми тикшеренү проекты буларак барлыкка килә. Аның ярдәмендә укучыларга якташ әдипләребез иҗаты буенча таблица тутыру, кроссворд чишү, интерактив викторина, онлайн-тест кебек эш төрләре тәкъдим итәргә мөмкин.

Сайтта, интерактив дидактик материаллар эшләү өчен, 34 макет тәкъдим ителә. Ресурс укытучыга үз классы өчен аккаунтлар төзергә ярдәм итә. Биремнәрнең дөреслеген укытучы «Статистика» бүлегеннән карап бара ала.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә, сыйныфтан тыш чараларда якташларыбыз иҗатына мөрәҗәгать итү укучының дөньяга карашын киңәйтә, туып-үскән төбәге белән кызыксынуын арттыра, туган җиренә карата мәхәббәт хисләре тәрбияли. Җирле материалларны кулланганда, тест-тренажердан яки learningapps.org. сервисы мөмкинлекләреннән файдалану дәреснең нәтиҗәлелеген, укучыларның туган тел белән кызыксынучанлыгын арттыра, аларны белем дөньясына җәлеп итә, шул ук вакытта фән буенча өлгереш күрсәткечен һәм уку сыйфатын да яхшырта.

**Әдәбият**

1. Авзалова М. Кайда да синүзкеше / М. Авзалова // Шәһри Казан. – 1995 ел, 3 февраль.

2. Гыймадиева Л. Кече күңелле олыгалим / Л. Гыймадиева // Сабантуй. – 2001, 23 март.

3. Рахман Р. Ниләр эшләмәс бу милләт, әгәр керешсә? / Р. Рахман // Мәгърифәт. – 1999, 11 декабрь.

4. Җиһаншина З.Н. Якташ язучылар / З.Н. Җиһаншина. – Кукмара, 2003. – 108 б.

**В.С. Кудрякова**
Средняя общеобразовательная школа
с углубленным изучением отдельных предметов № 62,
Казань

# ПСИХОЛОГИЗМ КАК АКТУАЛИЗАЦИЯ ВНУТРЕННЕЙ ЖИЗНИ ЧЕЛОВЕКА В РАССКАЗЕ ЗАКИРА ХАДИ «МАГСУМ»

**Аннотация.** В статье рассматриваются элементы психологизма в рассказе З. Хади «Магсум» (1906). Обращая внимание читателя на устои, сформированные в некоторых татарских медресе, автор поднимает проблему образованности, влияния внешних факторов на развитие образования, на состояние шакирдов, степень их образованности. В этой связи автор призывает родителей обращать внимание на своих чад, учитывать момент влияния семейных отношений, традиций на развитие детей.

**Ключевые слова:** рассказ, повесть, герой, психологизм.

**Abstract.** The article deals with the elements of psychology in the story Z. Hadi “Magsum” (1906). Drawing attention of the reader on the foundations formed by some Tatar madrassas, the author raises the issue of education, the influence of external factors on the development of education, the state shakirds, the extent of their education. In this regard, the author encourages parents to pay attention to their children, to take into account the time influence of family relations and traditions on the development of children.

**Keywords:** story, story, character, psychology.

«Психологизм в литературе (греч. *psyche* – душа, *logos* – понятие) – глубокое и детальное изображение внутреннего мира героев: их мыслей, желаний, переживаний, составляющее существенную черту эстетического мира произведения» [Литературная энциклопедия, 2003: 834–835]. По мнению Ф. Хатипова, в татарской прозе настоящие зачатки психологизма начинают проявляться в начале XX века. Основоположниками его считаются Ф. Амирхан, Ш. Камал и Г. Ибрагимов [Хатипов, 1984: 93]. В этот ряд писателей можно также отнести и имя З. Хади, с его рассказом «Мәгъсум» («Магсум»). Закир Хади в начале творческого пути считал, что болезни общества происходят в основном от невежества и необразованности. Его первые рассказы родились под знаком просветительских идей. З. Хади выступал с резкой критикой старометодных медресе, поднимал вопросы обновления и реформирования учебных программ, призывал народ к изучению светских наук. В своем творчестве он всегда ставил актуальные проблемы, беспощадно критиковал застой в области образования, оторванные

от жизни кадимистские медресе, невежественных мул и ишанов, горячо приветствовал просветительские идеи. Вопросы морально-этического воспитания современной молодежи и освобождение женщин стали важными темами его творчества. Например, в нравоучительном рассказе «Официант» автор поднимает злободневные проблемы открытия новых мечетей в деревнях, выбора в приходские имамы образованных мулл, авторитетных среди населения. А в таких произведениях, как «Магсум» и «Новые обитатели пещеры», он критикует устаревшие правила кадимистских медресе. В своем рассказе «Магсум» (1906), в повестях «Новые обитатели пещеры» («Яны асхабе кахаф», 1908) и «Благочинный Зиганша» («Зиганша хазрет», 1911) автор убедительно показал пагубность для шакирдов веками устоявшихся жестоких порядков и старых методов обучения в медресе, смело разоблачал реакционное духовенство. Например, некогда честный подросток Магсум, главный герой одноименного рассказа, попав в ужасающие условия обучения и воспитания схоластического медресе, постепенно стал злым, жестоким человеком, драчуном и задирой. Описав процесс нравственного падения шакирда, писатель хочет напомнить читателям, что дурное окружение и старые порядки, царящие во многих учебных заведениях, оказывают пагубное воздействие на подрастающее поколение. Рассказповествует о том, как юноша со светлой как чистый лист бумаги душой, переступив порог медресе, попадает в руки коварных людей и тем самым превращается в жалкое существо как в духовном, так и физическом плане. С этой стороны следует остановиться на названии произведения. С одной стороны, оно обозначает имя молодого человека. С другой, стоит обратить внимание на смысловую нагрузку данного слова. В арабско-татарско-русском словаре заимствований слово «магсум» переводится как безгрешный, без недостатков, незапятнанный; приводится при обозначении безгрешного подростка [Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге, 1993: 296].

В медресе главный герой рассказа оказывается учеником безграмотного учителя. Свою систему обучения он организует очень странно, обогащая ее бессмысленными учениями. Таким образом, он старается любыми путями не допустить того, чтобы его ученики его превзошли. Естественно, такому учителю и в голову не приходит, что творится в жизни его учеников. «Таким образом Магсум от такой «расположенности» обстановки в медресе попадает под воздействие распустившихся шакирдов», – отмечает литературовед Ф. Баширов [1: 168]. Медресе, которое должно было служить местом получения знаний, превращается в нечто обратное. Из-за всяческого рода оскорблений, унижений, душа Магсума, которая еще только переживает переход из юношества во взрослую жизнь, постепенно начинает черстветь, затвердевать, в ней зарождаются мысли и побуждения к порочным действиям.

Проходит время, и Магсум привыкает к подобному порядку вещей. Даже в некоторые моменты он начинает скучать по повседневной обстановке в медресе. Ему кажется, что смысл жизни заключается в жизни этого медресе. Он начинает чувствовать наслаждение от того, что сам обижает младших, бессильных. Основные события, которые происходят в жизни героя, З. Хади тесно переплетает с душевными перипетиями Магсума, уместно использует приемы психологизма.

Произведение начинается с описания одной деревни и плавно преподносит картину дома, в котором проживает герой. Здесь автор рассказа подробно останавливается на каждой детали, на каждой мелочи. Здесь можно явно проследить изображение внутреннего мира путем передачи внешних зарисовок.

Далее автор произведения знакомит читателя с главными героями рассказа – Хаятабыстай и Магсумом. З. Хади подробно преподносит ее портрет, из которого явно вытекает социальное положение героини. Если она когда-то и была богатой, то сегодня уже лицо ее опечалено. Соответственно, вновь через внешний портрет передано внутреннее состояние. Это естественно и для повествования от третьего лица. Несмотря на это, нельзя сказать, что здесь автор дает полноценный психологический портрет. Такой портрет является своего рода итогом естественного течения событий, и не более. Он не появился в результате каких-то сверхъестественных жизненных коллизий. Это можно подтвердить и высказываниями автора из текста.

Вторая часть рассказа воспринимается как некое воспоминание о прошедших событиях, ретроспективный взгляд на прошлое. Здесь обращает на себя внимание образ отца Магсума – Фахерелислам. Авторның Авторская позиция ярко чувствуется именно в его критических высказываниях. Остановимся лишь на одном моменте, когда присутствуют размышления о предназначении в жизни. Автор-рассказчик не только перечисляет приметы внешних и внутренних переживаний, но и пытается раскрыть раздумья героя, сопереживает ему, проникая в его духовный мир. Все это стоит близко к внутреннему монологу. Показана манера размышления героя, через слова выражено его внутренне состояние.

Также можно проследить быструю смену этого состояния. Например, так сильно воздействует на героя письмо от Хаятабыстай. В дело вступают психологические детали при чтении письма: шевелятся усы шакирда, губы улыбаются, глаза смеются. Автор не описывает внутреннее состояние, а дает читателю почувствовать самому. Шакирд также радуется красивому почерку. Детали способствуют и для понятия переживаний матери. На ее лице вспыхивает румянец, или появляется бледнота. Состояние постоянно меняется. Особенно интересен в произведении диалог Хаят и Ислама и пояснения к нему автора. Писатель

ярко изображает состояние влюбленности своих героев. Молодые общаются не только через слова, но и душами.

Магсум, который вырос под попечительством матери, вынужден ее покинуть с целью получить образование. Однако его пугает неизвестность. Он утешает себя тем, что все будут по нему скучать. Ему кажется, что даже животные смотрят на него с грустью. И самовар, и кошка с двумя котятами, и Хаятабыстай, как ему кажется, опечалены. Все эти представления происходят в душе Магсума, но не переданы через речь остальных героев. После застолья все спешат попрощаться с будущим шакирдом.

События дальнейшей жизни Магсума складываются достаточно грустно. Он вынужден переживать множество трудностей, в результате которых у него возникает желтизна на лице и от такого горестного положения часто кружится голова. Внешние события напрямую находят отклик в его душевном состоянии. Радостная встреча с матерью вызывает у него слезы. Нужно отметить, что в этом месте З. Хади больше останавливается на событиях, несколько уклоняясь от описания душевного мира героев. Однако, с другой стороны, это оправдывается, так как эти событийные изменения сами позволяют представить внутреннее сотояние Магсума.

После встречи с Хаятабыстай сердце Магсума пылает «огнем без очага» – именно так описывает переживания героя автор. Это в свою очередь позволяет напрямую судить о психологическом состоянии героя. Герой переживает, беспокоится. К тому же, Гариф, Шариф и Валид еще более усиливают эти страдания, тревожат его сердце. И все же коварство шакирдов преломляют душу Магсума, и он вступает в ряды подобных низких людей. Таким образом, внешняя среда, атмосфера медресе способствовали внутреннему изменению уклада характера рассказа З. Хади. Сейчас он и сам не прочь дать «наставления» младшим шакирдам. Это воспринимается читателем и как своего рода отместка за содеянное над ним. Не тянет его к себе и родимый дом. Однако, за летний отдых, он возвращается к прежнему состоянию непорочности, осознает своих настоящих врагов. Но все же и новые друзья Магсума – Амир и Султан – не явили собой эталон поведения, также не наставляя его на путь истины, а лишь вводя в безнравственность. Хаятабыстай осознает, во что превращается ее сын. Болезнь же Магсума воспринимается как возмездие за совершенные Магсумом грехи. Нужно сказать, под влиянием окружения Магсум озлобился, ожесточился, ввязываясь в драки, конфликты. Однажды зимой он сильно простудился. Так и не оправившись от болезни, умер в двадцатилетнем возрасте. Таким образом, З. Хади в своем рассказе, описав процесс нравственного падения некогда чистого ребенка, подчеркивает тот факт, что тяжелые моральные условия жизни в некоторых медресе оказывают трагическое воздействие на шакирдов.

Обратим внимание, что перед смертью героя автор сравнивает радость на его душе со светом солнца. Магсум понял смысл, цену жизни. Да, он ошибся, однако показом судьбы этого шакирда автор надеется, что подобную ошибку не совершат его последователи-шакирды. За содеянное в столь раннем возрасте герой расплачивается жизнью.

Для того, чтобы передать внутренние переживания, состояние героя, его размышления, желания и побуждения, писатель обращается к повествованию внешней среды, описанию портрета, внутреннему монологу. Естественно, эти приемы психологизма еще только первые проблески, которые полностью не соответствуют поставленным требованиям. Передача внутреннего через внешнее, общение взглядами – безусловно, это находки автора. Внешнее автор зачастую пытается объяснить сам. Наряду с эти есть примеры, где автор побуждает домыслить читателя. В таком русле объясняются и умышленные умалчивания. В череде событий, которые преподнесены очень быстро, невозможно не прочувствовать их влияние на героев рассказа.

Подытоживая можно сказать, что произведение З. Хади можно рассматривать в татарской литературе как наглядный пример отражения психологических приемов. Обращая внимание читателя на устои, сформированные в некоторых татарских медресе, автор поднимает проблему образованности, влияния внешних факторов на развитие образования, на состояние шакирдов, степень их образованности. В этой связи автор призывает родителей обращать внимание на своих чад, учитывать момент влияния семейных отношений, традиций на развитие детей [Һади, 1957: 178].

**Литература**

1. Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы / Ф.К. Бәширов. – Казан: Фикер, 2002. – 287 б.

2. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: 2 т. – Казан: Иман, 1993. – Т. 1. – 448 б.

3. Литературная энциклопедия терминов и понятий / под. ред. А.Н. Николюкина. – М.: Интелвак, 2003. – 1600 с.

4. Хатипов Ф.М. Духовный мир героя. Психологизм в современной татарской прозе / Ф.М. Хатипов. – Казань: Татарское кн. изд-во, 1984. – 296 с.

5. Һади З. Сайланма әсәрләр / З. Һади. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 188 б.

**Н.К. Курбанова**
ГБОУ «Школа № 508», Москва

# ИННОВАЦИОННЫЕ ПОДХОДЫ В МЕТОДИКЕ ПРЕПОДАВАНИЯ РУССКОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ В ПОЛИКУЛЬТУРНОМ КЛАССЕ

**Аннотация.** Поликультурный класс для творчески работающего учителя русского языка и литературы – это возможность видеть ребенка через его восприятие слова. Ученик, тонко чувствующий слово, не может не интересоваться историей происхождения этой единицы языка и готов создавать свой текст, имея определенный опыт знакомства с текстами мастеров художественного слова. Русский язык для детей разных национальностей – это окно в большой мир, где есть взаимопонимание и взаимоуважение. Важно делать это окно ярким, по-разному привлекательным. Это достигается при умелом использовании ИКТ. Русский язык участвует в процессах языковой глобализации не только как язык-реципиент, но и как язык-донор.

**Ключевые слова:** слово, русский язык, ИКТ, глобализация.

**Abstract.** A multicultural class for a creative teacher of Russian language and literature is an opportunity to see the child through his perception of the word. A student with a fine sense of the word cannot help but be interested in the history of the origin of this unit of language and is ready to create his own text, having some experience of acquaintance with the texts of the masters of the artistic word. The Russian language for children of different nationalities is a window into the big world, where there is mutual understanding and mutual respect. It is important to make this window bright and attractive in different ways. This is achieved with the skillful use of ICT. The Russian language participates in the processes of language globalization not only as a recipient language, but also as a donor language.

**Keywords:** the Word, the Russian language, information and communication technology, globalization.

Московская школа – большая поликультурная среда, где дети разных национальностей  не только овладевают русским языком, но и учатся уважительно относиться друг к другу.

Методика проведения этих уроков должна основываться на знании культур народов России.

Много лет работая в школах Москвы, не могу не отметить необходимость в оказании помощи учащимся разных национальностей не только в успешном

овладении русским языком, но и в развитии способностей этих детей вступать в успешный диалог друг с другом. Этот диалог естественен, так как у воспитанников общая история, общая родина.

Готовность общаться друг с другом, или коммуникативная компетенция, проявляется при выполнении словарной работы как на уроках русского языка, так и литературы: дети знакомятся с лексическим значением, историей происхождения слов, используя толковый и этимологический словари.

Это делается с учетом возможности использования информационных технологий. И это вполне оправдано тем, что век нынешний – это век информационный. Свою задачу вижу не только в том, чтобы дать детям знания, но и в том, чтобы научить своих воспитанников искать их и осваивать самостоятельно. Умение обрабатывать информацию на сегодняшний день является весьма ценным достоянием.

Компьютер может использоваться на всех этапах обучения: при объяснении нового материала; закреплении; повторении; контроле знаний и умений.

При этом для ребенка он выполняет различные функции: учителя, рабочего инструмента, объекта обучения, сотрудничающего коллектива, игровой среды. В функции учителя компьютер представляет источник учебной информации (частично или полностью заменяющий учителя и книгу); наглядное пособие (качественно нового уровня с возможностями мультимедиа и телекоммуникаций); индивидуальное информационное пространство; тренажер; средство диагностики и контроля.

Характер словарной работы зависит от процессов языковой глобализации и влияния этих процессов на развитие современного русского языка, первое и, может быть, последнее, что приходит на ум, – огромное количество слов, заимствованных из английского в последние 20–25 лет. Действительно, легко предположить, что старшеклассник сразу же припомнит десятки заимствованных слов, которые особенно широко распространены в таких сферах, как бизнес (фрилансер, франчайзинг), компьютеры (принтер, апгрейдить), молодежные субкультуры (боди-арт, тверкинг) и секс (секс, гей).

Не все новые слова, вошедшие в русский язык в последние годы, имеют прямую или косвенную связь с английским. Вот некоторые примеры, заимствованные из разных европейских языков: барсетка/борсетка (итал.), гастарбайтер (нем.), люстрация (чеш.), мундиаль (исп.), путана (итал.), штрихкод (нем.).

Русский также обогатился значительным количеством слов, пришедших из разных восточных языков. Некоторые из этих слов можно считать интернационализмами, например ваххабит, джихад; айкидо; фэншуй, дацзыбао.

Здесь стоит отметить, что русский язык участвует в процессах языковой глобализации не только как язык-реципиент, но и как язык-донор.

В постсоветский период русских слов, вошедших в другие европейские языки, не так много, но можно упомянуть «олигарх» (в значении «сверхбогатый россиянин, обладающий огромной яхтой, футбольным клубом и недвижимостью в Лондоне») и, может быть, «силовик».

На каждом уроке я нахожу время для словесного творчества ученика. В этом значительную помощь оказывает эпиграф к уроку, настраивающий детей на размышление о нравственных ценностях: о любви к родной земле, об уважительном отношении к человеку, к какой бы национальности он ни относился, о трудолюбии…

В роли эпиграфов используются пословицы разных народов России, высказывания известных деятелей культуры, выдержки из произведений. Вот некоторые из них:

Бери в работе умом, а не горбом. Русская.
Дело путь укажет. Русская.
Дело учит, и мучит, и кормит. Русская.
Алмаз остается алмазом, даже если бросить его в грязь. Татарская.
Бесконечно только небо, всему есть предел. Мордовская.
Будешь злым – повесят, будешь мягким – раздавят. Татарская.
В беду попадешь – хороший друг придет, а плохой отойдет. Мордовская.
Вернуться с полпути – тоже смелость. Татарская.
Где дыра – там ветер, где лодырь – там и разговоры. Башкирская.
Где любовь – там свет. Чувашская.
Избалованный ребенок – не кормилец. Мордовская.
Когда бой кончился, появляется много батыров. Татарская.
Когда голод узнаешь, тогда и работать научишься. Удмуртская.
Малый крепок ногами, старый – головой. Удмуртская.
Один раз не сумеешь, во второй – научишься. Татарская.
Одним ударом дерева не срубишь. Татарская.
Свинья не видит неба. Калмыцкая.
Сильный победит одного, знающий – тысячу. Башкирская.

В поликультурном классе, где детей сплачивают общие праздники, несложно содержание учебного материала делать интересным для всех. Например, в 6-м классе при изучении темы «Числительные» ребята записывают предложение.

«Среди 11 тысяч воинов, удостоенных высокого звания Героя Советского Союза, 7627 русских, 1928 украинцев, 244 белоруса, 157 татар, 99 евреев, 97 казахов, 88 армян, 81 грузин, 66 узбеков, 40 азербайджанцев, 37 башкир. 16 туркмен, 15 таджиков, а также воины других национальностей». В год 75-летия

Победы в Великой Отечественной войне вышеизложенная информация становится особенно значимой.

Предлагается как творческое задание найти ответ на вопрос: «Кто из известных писателей – русских, украинцев, белорусов, евреев, азербайджанцев и т. д. – удостоен звания Героя Советского Союза?»

К формам работы, реализующим патриотическую направленность уроков русского языка, можно отнести и «лингвистические экспедиции» по улицам, проспектам родного города. Такие «экспедиции» удобно осуществить при выполнении учебных проектов в рамках изучения и повторения темы «Собственные имена существительные».

Детей разных национальностей объединяет любовь к сказкам. Сказок много не бывает, хотя у каждого народа есть свои самые любимые. При внимательном знакомстве с ними удивляешься схожести этих народных сочинений. Все знают сказку «Царевна-лягушка». После ее изучения в 5-м классе ребятам предлагается прочитать татарскую народную сказку «О Шайтане и его дочери». На вопрос о том, что общего между двумя произведениями, дети без труда отвечают: волшебный сюжет, превращения Василисы Премудрой и дочери Шайтана, выполнение заданий царя и Шайтана, волшебный конец (смерть Кощея и Шайтана), присутствие волшебных помощников, волшебные герои – Баба-Яга, Кощей Бессмертный, Шайтан. Моральные ценности у разных российских народов одинаковые: честность, трудолюбие, доброта, настойчивость, взаимовыручка, верность, преданность.

Вдохновленные знакомством с разными сказками, дети с удовольствием сочиняют свои. Такие сказки не только отражают их внутреннюю реальность, волнующие проблемы, но и активизируют бессознательные процессы, способствующие личностному развитию и разрешению затруднений.

Изучение русского языка невозможно без обращения к русской литературе, являющейся одним из самых важных звеньев культуры российского народа.

Общность судеб народов России делает возможным и часто необходимым проведение уроков литературы, показывающих близость художественных миров русских, татарских, башкирских и т. д. поэтов, прозаиков, драматургов. Школьников не может не заинтересовать тема «Волга в российской поэзии». Наряду с известным произведением Н.А. Некрасова изучается стихотворение Р. Файзуллина, который десять лет назад в одном из своих интервью сказал: «Все мы дети природы и существуем на этой земле». Он, бесспорно, подобно тысячам россиян, дитя Волги: «Только Волга душу вместит, и поймет меня, и простит». Мне, выпускнице Казанского университета, учителю литературы, приходилось читать не одно стихотворение о Волге, но эти строчки о ней оказались самыми трогательными:

Течет Идель. Живет река.
Ее история безбрежна.
С Иделью рядом на века
Мечта людская и надежда.

При преподавании русского языка и литературы отбор дидактического материала, приемы его изучения и интерпретации должны служить тому, чтобы не шли дети «вразброд» и «в невежестве видели корень бед».

**Ә.Г. Төхфәтуллина**
Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте, Арча

## Ф. ГАЛИМУЛЛИН ДӘРЕСЛЕГЕ – СӘНГАТЬЛЕ УКЫРГА ӨЙРӘТҮДӘ ТӨП ЧЫГАНАК

**А.Г. Тухфатуллина**
ГАПОУ «Арский педагогический колледж
имени Габдуллы Тукая»

## УЧЕБНИК Ф. ГАЛИМУЛЛИНА – ОСНОВНОЙ ИСТОЧНИК В ОБУЧЕНИИ ХУДОЖЕСТВЕННОМУ ЧТЕНИЮ

**Аннотация.** Художественное чтение – это своеобразное искусство, предполагающее публичное, чрезмерно эмоциональное артистическое исполнение произведений художественной литературы. Владение техникой художественного слова помогает освоить творческие профессии, передать эмоции, выразить чувства, побудить к действию. Этот навык способен справиться с внутренней скованностью характера и побороть страх публичных выступлений. Методическое пособие Ф.Г. Галимуллина «Выразительное чтение и развитие речи» – основной источник в обучении художественному чтению.

**Ключевые слова:** выразительное чтение, художественное слово, речь педагога, подтекст, интонация, темп.

**Abstract.** Fiction reading is a kind of art that involves public overly emotional artistic performance of works of fiction. Mastery of the technique of the artistic word helps to master creative professions, convey emotions, express feelings, and encourage action. This skill is able to cope with the inner stiffness of the character and overcome the fear of public speaking. The methodological manual of F.G. Galimullin "Expressive reading and speech development" is the main source in teaching artistic reading.

**Keywords:** expressive reading, artistic word, teacher's speech, subtext, intonation, tempo.

Сәнгатьле уку – сәнгатьнең үзенчәлекле бер төре. Сәнгатьле укырга өйрәтү, беренчедән, укучының үзен, икенчедән, тыңлаучыны эстетик яктан нәфис зәвыклы, тормышка, әдәбиятка һәм сәнгатькә матурлык күзлегеннән дөрес карашлы итеп тәрбияләргә ярдәм итә.

Без, Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте укытучылары да, педагог һөнәрен сайлаган студентларыбызны сәнгатьле сөйләргә өйрәтүне үзебезгә максат итеп куябыз. Бу юнәлештә анык эшләргә ярдәм итүче, вакытлар үтсә дә үзенең әһәмиятен, актуальлеген югалтмаган хезмәтләрнең берсе – Ф.Г. Галимуллинның «Укучыларны сәнгатьле сөйләмгә өйрәтү» (1988) дигән методик кулланмасы. Без, галимнең: «Әдәбият дәресләре сәнгать дәресләре булып әверелсен, укучы әсәрне акылы белән түгел, йөрәге белән кабул итә белергә тиеш» [Галимуллин, 1988: 4] дигән сүзләрен методика дәресләрендә еш кабатлыйбыз.

Кызганычка каршы, нәкъ менә шушы өлкәдә – җанлы сөйләмдә телебезнең матур яңгырашын саклауга, аның хисси, тасвирый һәм тәэсирлелек көчен арттыруга җитәрлек игътибар бирелми. Еллар узган саен, сөйләм бары тик нәрсәне дә булса хәбәр итү чарасы булып кына кала бара. Әлбәттә, бу телнең ярлылануына китерә. Мәктәптә балаларны сөйләмнең мәгънәви ягына игътибарлы булырга өйрәтү белән бергә, аларның бер үк вакытта әйтелгәннәргә бәрабәр хис-кичерешләрен, мөнәсәбәтләрен дә җиткерергә күнектерү – әдәбият һәм тел укытучыларының төп бурычларыннан берсе. Булачак укытучы моны эшләүнең ысуллары белән яхшы коралланырга тиеш [2].

Соңгы вакытта укучыларның күбесе татарча матур, аһәңле итеп укуый белми, еш кына йөгерек уку күнекмәләре түбән булган студентлар белән дә эшләргә туры килә. Безнең максат – аларны сәнгатьле сөйләү күнекмәләренә өйрәтү.Бу урында Ф. Галимуллин фикере белән килешми мөмкин түгел, әгәр дә укытучы сөйләм культурасына ия булып, сүз куллануда һәм интонациядә төгәл һәм җыйнак икән, укучы өчен бу бәя биреп бетергесез файдалы үрнәк булачак. Тел-әдәбият укытучысы гомере буе үзенең сөйләмен яхшырту өстендә эшләргә тиеш. Дәрестә сөйлиме ул, ата-аналар белән аралашамы, лекция укыймы, таныш-белеше белән сөйләшәме, әдәбият укытучысы үз сөйләменең тәэсире, төзеклеге турында беркайчан да истән чыгармасын иде. Галим фикеренчә, укытучысәнгатьле укый белергә һәм укучыларның да сүз сәнгате нечкәлекләренә өйрәтүдә теоретик белем, методлар, алымнар һәм күнекмәләр белән коралланган булырга тиеш [Галимуллин, 1988: 7].

Дәрестә укытучының  сәнгатьле укуы әсәрне  анализлауны ачып җибәрә һәм  аның эчтәлеген аңлауга ачкыч булып тора. Ә укучының сәнгатьле укуы

тикшерү процессын йомгаклый, анализлауга нәтиҗә ясый, әсәрне аңлауны һәм шәрехләүне практик гамәлгә ашыра [Галимуллин, 1988: 9]. Ф. Галимуллинның әлеге фикере бүгенге көн өчен дә актуаль, чөнки хәзер дә без студентларыбызга тәрбияче, яисә укытучының сөйләме һәрчак үрнәк булырга тиеш, әсәр аеручa сәнгатьле итеп җиткерелгәндә генә бала әсәрнең мәгънәсенә төшенә, дип өйрәтәбез.

Сәнгатьле укуда һәрвакыт ике якны – мәгънәне һәм кичерешне дөрес җиткерүгә омтылу әһәмиятле. Текстка мөнәсәбәтеңне ачыклау һәм шуны бирүнең иң дөрес юлларын эзләү – уңышка илтүче бердәнбер юл. Иң дөресе – текстта тәкъдим ителгән шартларга үзеңне кую һәм шул шартларда үзең аңлаганча һәм мөмкинлегең биргәнчә хәрәкәт итү. Тик боларга ирешү өчен бер шарт бар – әсәрне бик тирән төшенгән булу. Менә шул урында галим «подтекст» мәгънәсенә белдергән, әсәрнең эчке мәгънәсен билгеләүче төшенчә – «астекст» терминны кертеп җибәрә. Аныңча, сәнгатьле укуда астекстны тирән аңлап эш итү таләбе иң беренче планга куелырга тиеш [Галимуллин, 1988: 22].

Ф.Галимуллин сәнгатьле укуның өстенлекле ягы дип, аның тыңлаучыга юнәлдерелүен атый һәм сәнгатьле уку дәресләрендә укучылар берьюлы ике юнәлештә эшләргә: үзләрен эмоциональ укырга һәм башкалар укыганны кабул итәргә өйрәнәләр, ди. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләп иткән, бер-береңне тыңлый белү күнекмәсен, галим әнә шул вакытта ук нигезле итеп җиткерә. Аныңча, тыңлый белү бик әһәмиятле, тормышның үзендә дә нәкъ менә шушы сыйфат җитенкерәми. Сөйләшүче әңгәмәдәшне аңларга тырышу, гомумән, кеше өчен кирәкле әйбер.

Галим сәнгатьле уку төшенчәсенә бик төгәл һәм гади итеп аңлатма бирә, ягъни ул, китапта язылган әдәби әсәрне җанлы сөйләмгә әверелдерү, яисә мәгънәне һәм кичерешне дөрес җиткерүгә омтылу [Галимуллин, 1988: 79].

Ф. Галимуллин билгеләп үткәнчә, сәнгатьле уку өстендә эшләү астекст, интонация, басым, пауза, сөйләм темпы, тавыш көче, кул хәрәкәтләре, мимикага нигезләнә. Шуларны белү нигезендә генә без укучылар белән сәнгатьле уку өстендә эшләүгә керешә алабыз.Галим урта мәктәпнең һәр сыйныфында куелырга тиешле таләпләр дип гадилек, сүз белән иркен эш итә белүне күрсәтә һәм балаларны сәнгатьчә тәрбияләүне бала үзе укый белә башлаганчы ук башларга куша, чөнки бала сөйләмнең яңгырашына сүзгер, шуңа күрә алар белән эш иткәндә төзек, тулы, хискә бай сөйләм өстенлек итәргә тиеш. Бала белән сәнгатьле уку өстендә эшәүнең максатлары дип Ф. Галимуллин түбәндәгеләрне атый:

1. Сәнгатьле укырга өйрәтүнең методлары һәм алымнарын өйрәнү.

2. Сүз сәнгатенең тарихы һәм теориясеннән булган мәгълүматларны тирәнәйтү.

3. Укучыларны сәнгатьле укудагы төп методик әсбаплар белән таныштыру һәм аларны кулланырга өйрәтү [Галимуллин, 1988: 80].

